Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

1995 елның июленнән башлап чыга

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 2 (1367) 21 гыйнвар 2022 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga
madanizhomga
madanizhomga
madanizhomga

12

Буа районы Килдураз авылында рәссам Шамил Нигъмәтне яңа ачылган музей-галерея белән искә алдылар.

14

Бөек юлбашчы Владимир Ильич Ленинның инде бер гасырга якын мавзолейда яткан җәсәде нинди серләр саклый?

24

Мөгаллим, дин белгече Ридуан Әлморатов шамаилләрне үзенчәлекле филография сызулы – кадаклар ярдәмендә ясый.

Хәким затлар гына ирешәдер Ил агасы дигән мәртәбәгә!

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Казанда рәссам Ильяс Айдаровның «Казан-минем йөрәгемдә» дип исемләнгән күргәзмәсе ачылды.

- Татарстан Язучылар берлеге «Гомер чалымнары» дип исемләнгән әдәби очрашулар циклын башлап җибәрде.

- Рок-музыкантлар Оскар Юнысов белән Рәдиф Кашапов Истанбулның Азия өлешендәге Үскүдар районында беренче тапкыр татар альтернатив музыкасы концерты тәкъдим итәчәк.

- Композитор, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, бернichә көн элек 91 яшен каршылаган Сәйяр Хәбибуллинга Габдулла Тукайның тууына 135 ел тулу уңаеннан әзерләнгән истәлекле билге тапшырылды.

- Мамадыш каласында һәм районның Тулбай авылында Шәйхи Маннурны искә алу кичәсендә шагыйрьләр Рүзәл Мөхәммәтша һәм Владимир Калашниковка әдип исемендәге премия тапшырылды.

- Казан ипподромында беренче тапкыр татар токымлы атлар рингы узды.

- «Кояшлы дала кызы» (Гөлсинә Галимуллина), «Ике йөз елдан соң инкыйраз» (Гаяз Исхакый), «Үлмәс» (Нәбирә Гыйматдинова), «Сыналган мәхәббәт» (Галия Сафиуллина), «Ачык тәрәзәләр» (Рафаил Газизов) китаплары – 2021 елда Татарстан Милли китапханәсеннән иң күп алынган татар басмалары.

- Камилә Вәлиева хатын-кызлар арасында фигуралы шуу буенча Европа чемпионатының алтын медален яулады.

- Татарстан Милли музеенда композитор, Казан дәүләт консерваториясенең беренче ректоры Нәҗип Җиһановның 111 еллыгына багышланган беренче «Музыкаль пәнҗешәмбе» узды.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Шамил САДЫЙКОВ, «Татмедиа» акционерлык җәмгыяте генераль директоры:

«Кызык заманда яшибез, элек акча юк, эшләргә кеше бар иде, хәзер акча да, җиһазлар да бар, ә эшләргә кеше юк. Безнең иң зур проблема – татар телендә эшли белүче белгечләр табу. Кызганычка, олы буын белгечләр китеп бара. Яңа эш алымнары керде: социаль челтәрләр, инфографика, видео. Яңа форматта эшли белүче яшь буын журналистлар кирәк. Яшь журналистларны тапсак та, телне камил белү мәсьәләсе килеп чыга. Төп проблема – кадрлар».

СЫНАМЫШЛАР

24 гыйнварда агачларны бәс сарса, җәй яңгырлы килер ● Гыйнвар җылы булса, яз соң килә ● Гыйнварда аяз һәм суык булса, эссе, коры җәй фаразлана ● Гыйнварда еш буран котырса, җәй яңгырлы була ● Гыйнварның икенче яртысында көннәр кояшлы булса, игеннәр уңа ● Гыйнварда суыграк булган саен, җәен боз яву ихтималы кимрәк ● Гыйнварда суык һәм коры булса, яз көне кар тиз эреп бетә.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **7 сәгать 55 минутта** чыкты, һәм ул **15 сәгать 54 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **7 сәгать 59 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **25 минутка озынаячак** һәм киләсе җомгада, ягъни **28 гыйнварда 8 сәгать 24 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

21 гыйнвар – шагыйрь Зыя Шәйхи улы Насыйровның (Ярмәки) тууына 135 ел (1887–1965);

– Халыкара кочаклау көне.

22 гыйнвар – Эстония театр һәм кино актеры, «Salong» театрына нигез салучы һәм аның баш режиссеры Даян Әхмәтнең тууына 60 ел (1962–2006).

23 гыйнвар – Татарстанның халык шагыйре, прозаик, драматург, публицист, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Ркаил Рафаил улы Зәйдуллинга 60 яшь (1962).

25 гыйнвар – Россиянең атказанган, Башкортстанның халык артисты Илдар Ширкәт улы Сәетовның тууына 65 ел (1957–2020).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Гыйнварның магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Бу атнада андый магнитлы көн юк.**

* * *

Гадәттә, тулы айдан айның соңгы чирегенә кадәр **(18-25 гыйнвар)** организм кысылуга бара. Мондый көннәрдә үз-үзеңә физик йөкләмә бирү файдалы.

Шунысын да онытмагыз: **16 гыйнвардан 17 февральгә кадәр** ашказаны, ашказаны асты бизе, талак актив булучан. Шушы вакыт аралыгында аларны чистарту һәм дәвалау уңай нәтиҗәләргә китерә.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1443 ЕЛ

Бүген җөмәдел ахир аеның 18 нче көне

ҖАН АВАЗЫ

Вахит ИМАМОВ

Аксак Тимер – безгә кирәк түгел!

Яңа ел ялларыннан соң беренче атнада ук Язучылар берлегендә "Әдәбиятта тарихчылык" дигән тема буенча түгәрәк өстәл янында сөйләшү үткәрелде. Берлек бинасына тарих фәннәре докторы Дамир Исхаков, Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтыннан Алтын Урда чоры тарихы буенча бүлек мөдире Илнур Миргалиев, тарих фәннәре кандидаты Илнар Гарифуллин, Татарстан Югары Советы депутаты Рамил Төхфәтуллин, Татарстан кинематографлар берлеге рәисе Илдар Ягъфәров килгән, әдипләребез ягыннан Фәүзия Бәйрәмова, Тәлгат Галиуллин, Нурулла Гариф, Рафис Корбанов, Рөстәм Галиуллин, Фәрит Яхин, Илсөяр Иксанова, Вахит Имамов кебек язучыларны чакырганнар. Сөйләшү башланганчы ук "Татарстан – Яңа гасыр" телеканалыннан, "Татар-информ" агентлыгыннан, "Казанфирст" порталыннан да журналистлар рәхим иткән. Түгәрәк өстәл артындагы сөйләшүне, әлбәттә, берлек рәисе Ркаил Зәйдулла алып барды.

Гаҗәеп сер түгел, язучылар арасында милләт тарихын биш бармагыдай төгәл белгән әдипләр бик аз. Нәкъ шул сәбәптәндер, әдәбиятта тарихи романнар да гаять сирәк туа. Аларны аеруча 40-50 яшьтән узган буын көтеп яши, чөнки әлеге урта буын кешеләре тарих белән беркадәр булса да хәбәрдар, дип күңел юата алабыз. Ләкин инде 2007 елдан бирле Мәскәүдәге Мәгариф министрлыгы татар һәм, гомумән, рус булмаган "вак" милләтләр тарихын укытуга бөтенләй табу салды, шуңа күрә хәзер инде 30 яшькә җиткәннәр дә үз кавеменең үткән юлын белми. Өч ел элек, мәктәпләргә кирза итек белән кереп, татар телен дә таптап чыктылар. Изү бу рәвешчә барса, тагын 15-20 елдан соң татар тарихын үз телендә укып өйрәнердәй буын бөтенләй калмаячак. Мәсьәләнең мондый торышы исә, үз чиратында, татар милләтенең ачы язмышы турында тарихи роман яза алырдай әдипләрнең дә каләмен төшерәчәк. Бөтенләй дә перспективасыз иҗат – баллы мичкә түгел.

Тарихи романнар иҗат итү дигән сфераның икенче ягы да бар. Нурихан Фәттах белән Мөсәгыйт Хәбибуллин язган тарихи романнар хәтта әле 1970-1980 елларда ук икеләтә тираж куеп, 30 ар мең данә итеп басыла, ул вакытта татарча әсәрләрне йөгертеп укырдай әдәбият сөючеләр саны да йөз меңләгән иде. Өстәвенә, шул икеләтә тираж өчен, әдипләрнең үзләренә икеләтә каләм хакы түләнде, ул елларда андый гонорарга "Волга" машиналары да алып була иде. Бүген исә, Ф.Бәйрәмова бәяләгәнчә, "юрган асты романы" язасыңмы, әллә җиде йозак астына яшерелгән милли тарихның гранитташ кыяларын теш-тырнагың белән аралап, йөрәгеңнән тамган канны куша-куша, тарихи әсәр тудырасыңмы, дәүләткә барыбер, ул ике төр язмага да йөз-йөз илле мең чамасы гына сәдакасын суза.

Әле шулай, йөрәк каны аша язылган тарихи әсәрнең дә киләчәге бик юк. Милләтнең газиз ул һәм кызлары турындагы, безнең ачы тарих турындагы әсәрләрне бер генә театр да үз сәхнәсенә мендерми, элек төп каһарманнары Муса Җәлил, Мулланур Вахитов, Габдулла Тукай, Мөхлиса Бубый булган спектакльләрне дә сәхнәләрдән "себереп" төшерделәр. Безнең нәшрият тематикасына, милли театр репертуарларына, Казан киностудиясенең эш планнарына да Мәскәү ягына авышкан кирза итекле, тимер ыргаклы "сакчы агайлар" хуҗа булды сыман.

Тарихи роман яки татарның ачы тарихын иҗат итүче әдипләребез элек тә бик санаулы булган, ә хакимият шуларның да Һади Атласи, Газиз Гобәйдуллин кебекләрен таш төрмә диварларына терәп аткан, Гаяз Исхакый, Муса Бигиев кебекләре чит-ят илгә качып кына гомерләрен саклап кала алган. Ут белән шаяручылар бүген дә бармак белән санарлык. Фәүзия Бәйрәмова үз романнарын Себер һәм Төркия җирләрен аркылыдан-буйга йөреп, архив тузаннары эчендә казынып тудыра, шулар өчен ул әллә ничә суд мәхшәрен узды. Вахит Имамовны нәкъ шул рәвешчә интегеп язган әсәрләренең кайберләре өчен суд юлында йөртеп, йөзәр мең тәңкәле штрафлар салып газаплыйлар. Кирза итекләләр безнең әдипләрне һәм милли әдәбиятны янә агач аран арасына куып кертергә, муеннарга элмәк кидерергә чамалый. Шушындый хокуксыз хәлгә калдырылгач, татарча язылган тарихи романнарны рус, төрек яисә казах теленә тәрҗемә итү турында сүз дә булганы юк. Хөкүмәткә, гомумән, татар тарихын, татар әдәбиятын дөньякүләм аренага чыгару бөтенләй дә кирәкми, ул аларга артык кашык итеп карый сыман.

Милли тарих фәненең торышы турында да күкрәк сугарга иртә әле безгә. Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты татар тарихының җиде томлы, саллы энциклопедиясен тудырды, монысына шөкрәт вә афәрин. Ләкин гомумсаны белән дүрт мең ярымга җиткән татар авылларының тарихы турында бер генә җитди хезмәт тә тудырылмаган әле. Ул арада күрше халыклар һич тә тыныч ятмый, аларның кайберләре безнең тарихка гына түгел, безнең милләт балаларына, безнең телгә тикле дәгъва белдерә. Башкорт мөтәгалимнәре, әнә, үз республикаларының төньяк-көнбатыштагы 20 гә якын районында 6-7 гасыр буена гомер сөргән татарлар теленнән "башкорт диалекты" ясап куя, ул һәм кызларын йөз меңләрләп сәнда башкорт итеп җанисәпкә ала. Чуашлар хәтта Мәккәгә хаҗ кылган шагыйрь Мөхәммәтне дә чуашныкы дип күкрәк суга. Кичә генә кардәш вә дус булып саналган казах галимнәре хәзер Алтын Урданы "татарныкы түгел, казахныкы", дип шәрран яра. Беркадәр чамалыйбыз, Мәскәүдәге карагруһчы сәясәтчеләр "казах халкының элек иле, үз дәүләте дә булмаган, бүгенге республикаларын да большевиклар гына ясап биргән", дигән шигарьләр астында казах җирләренә дәгъва белдерә башлагач, тегеләре, җавап йөзеннән, Алтын Урданы да үзенеке итеп бетермәкче. Ләкин тарихта Урда тәхетенә утырган бер генә ханның да казах вәкиле булуы мәгълүм түгел, ислам динен кабул иткән Бәркәдән башлап, ул динне Урта Азиягә тараткан Үзбәк ханга, аларны алыштырган Туктамыш хан, Олуг Мөхәммәткә кадәр – барчасы да асыл татарлардыр. Алтын Урда җимерелгәч, Амудәрья белән Сырдәрья буйларыннан башлап 1950 елларда "табылган" чирәм җирләргә кадәр җәелгән мәйдандагы Ак Урда ханлыгын да татарлар төзеп биргән. Сыгнак, Сәүрән, Өтрәр калаларын үз эченә алган Ак Урдада ханнар булып Чымтай, Ырыс, алардан соң Алтын Урдадан Аксак Тимер канаты астына качкан һәм шул Аксак биргән гаскәр ярдәмендә тәүге тәхеткә үрмәләгән Туктамыш утырган. Бүген аек чамалыйбыз: урыс карагруһчылары "безнең җирләр" дип дәгъва итмәсен өчен, казахларга ерак гасырларда татарлар нигез салган Сәмәй-Семипалатинск, Кызылъяр-Петропавел калаларын да үзләренеке дип таныту отышлырак. Казахларның гомер-гомергә татарныкы булган Җаек-Уральск каласын һәм бу өлкәне дә кабаттан урыска кайтарасы килми. Шуңа күрә алар бөтен Алтын Урда тарихына да казах тажы кидереп куюдан тартынмый. Әммә без – кайчандыр империя тоткан һәм ярты җиһанны дер селкетеп яшәгән татарлар – бу ялган "империячеләргә" каршы үз сүзебезне әйтергә һәм аларны урыннарына утыртырга тиештер бит!..

Безнең дошмни яшәвебездән файдаланып азынулар һәр тарафта бара. Әнә, инде үзбәкләр дә борынгы татар җире – Самара өлкәсендәге Кондырча елгасы буена, Кызылъяр районының Кече Каменка авылы янәшәсенә китереп, Аксак Тимер әмирләренә һәйкәл куймакчы. Бу хакта Үзбәкстанның премьер-министры А.Арипов кул куйган карар чыгарылган, ул инде Россия хөкүмәте белән дә килештерелгән. Ягъни Чабаксар шәһәрендә Явыз Иван истәлегенә һәйкәл куярга өлгергән һәм шул ук җәллад һәйкәлен Алатырь шәһәренә дә куярга карар кылган Россия хөкүмәте Явыз Иван шикелле үк баскын, талаучы, йөз меңләгән халыкны кырып бетерүче җәллад Аксак Тимер истәлеген мәңгеләштерүне дә яклый, дигән сүз бу. Бу гамәлне нәкъ менә татар милләтенә каршы юнәлтелгән, безне кимсетү һәм юкка чыгару өчен кылынган чираттагы мәкерле бер адым дип кабул итмичә булмый.

Бер үк вакытта иситкеч гаҗәп тә. Мәскәү карагруһчыларының мантыйгы буенча, Аксак Тимер гаскәре Алтын Урданы җимергән, Идел буенда һәм Кырым атавында дистәләгән калаларны юкка чыгарган, берочтан урысларның Елец (Карасу) каласын да җимереп үткән. Иллә мәгәр нинди сәбәптәндер, Аксак Тимернекеләр шуннан ары бер урыс каласына да кул сузмаган, кире борылып кайтып киткән икән.

(Дәвамы 4 нче биттә).

ҖАЙСЫЗ СӨЙЛӘШҮЛӘР АТНАЛЫГЫ

Бәйрәм һәм кышкы ялларбыел, Мәскәү белән Вашингтон өчен генә түгел, ә НАТО һәм ОБСЕ илләре өчен дә җайсыз сөйләшүләр атналыгына алышынды. Моңа исә Россия тышкы эшләр министрлыгында әзерләнгән һәм 17 декабрьдә мәгълүмат чаралары да баян итегән үзенчәлекле ике документ этәрде: 1) Россия һәм АКШ арасында иминлек гарантиясе турында килешү проекты; 2) РФ һәм НАТО илләренең иминлеген тәэмин итү чаралары турында килешү проекты. Киң җәмәгатьчелек игътибарына да таянып кылынган ошбу “дипломатик” авантюра (чөнки мондый килешүләр, гадәттә, тавыш-тынсыз гына, тыныч шартларда хәл ителә) узган атнада инде өч сериядән торган һәм вакыт-вакыт катлаулы борылышлар да алган дәвамлы сөйләшүләргә китерде: 10 гыйнварда Женевада – АКШ һәм РФ арасында, 12 гыйнварда Брюссельдә – Россия-НАТО шурасы кысаларында һәм 13 гыйнварда Венада – ОБСЕ даими шурасы мәйданчыгында узган консультацияләр. Мәскәүнең Көнбатыш өчен билгеләнгән “кызыл сызык”лары исә элеккеге СССР территориясендә НАТОга кермәгән илләрдә хәрби базалар булдырмауны һәм альянсның көнчыгышка киңәюен туктатуны күздә тота һәм, ул гына түгел, Россия әле үзе өчен язма рәвештә һәм юридик нигездә иминлек гарантияләре бирелүен дә таләп итә.

Сөйләшүләр киеренке шартларда барса да, яклар аларны катлаулы, әмма файдалы дип бәяләде. “Дипломатик” авантюра, әлбәттә, уңышсыз тәгәлләнде һәм ул башкача була да алмый иде. Сәбәбе – таләпләрнең чынбарлыкка туры килмәве һәм ультиматив төстә куелуы. Женевадагы сөйләшүләр, әйтик, ябык ишекләр артында, 8 сәгатькә якын дәвам иткән. АКШ дәүләт секретаре урынбасары Уэнди Шерман анда үз иленең Европада ракеталар урнаштырмау турында сөйләшүләргә әзер булуын белдергән, моның өчен вакыт кирәклеген дә искәрткән. Шул ук вакытта ул НАТОның “ачык ишекләр” сәясәтенә каршы төшәргә беркемгә дә юл куелмаячагы турында әйткән, ә Мәскәү Украинага басып кергән очракта, җавап 2014 елдагы кебек кенә булмаячагы хакында да кисәткән. Киеренкелекне киметү өчен, Шерман Украина тирәли тупланган гаскәрләрнең казармаларга кайтарылуын таләп иткән. Җавап исә аңа, үз җиребез, кая телибез – шунда урнаштырабыз, өслүбендә булган. Брюссель һәм Венада үткән консультацияләрдә дә сөйләшү шундый ук рухта узган. Чөнки У.Шерман искәрткәнчә, халыкара һәм Европа иминлек системаларының база принциплары үзгәрешсез кала: иминлеккә үз юлын сайлауда һәр ил суверен хокукка ия.

Мәсьәләнең юридик ягын алсак, ул иң элек Россиянең халыкара мөнәсәбәтләрдә ике катлы стандартлар куллануына бәйле кебек. Чыннан да, бер яктан, Мәскәү Грузия һәм Украинаны НАТОга алмау, ә альянсны 1997 елгы чикләренә кайтару таләбен катгый куя һәм моның юридик гарантияләрен үзе өчен абсолют императив дип тә игълан итә. Шул ук вакытта, Будапешт меморандумы буенча Украина иминлеге гаранты саналса да, ул үзе үк аның территориаль бөтенлеген бозды. Ә Көнбатыш белән ике арадагы хәлләрнең бүгенге кискенләшүе артында, һич икеләнүсез әйтергә була, дөнья тотучылар үткәрә торган мәҗбүри глобальләштерү сәясәте һәм шуңа бәйле геосәяси уеннар ята. Күренә ки, инде шактый вакыт бара торган “гибридлы сугыш” кискен үзгәрешләр этабына якынлаша. Хәлбуки, инсаниятнең бүген яңа революцион үзгәрешләр белән көмәнле булуы да хак. Ахыр чиктә, болар һәммәсе дә җиһанда яңа дөньяви тәртип урнашуына китерергә тиеш. Бу җәһәттән, соңгы елларда “Зур Европа” проекты тирәсендә бара торган үзгәрешләрне (Украинага бәйле хәлләр, “Brexit” һ.б.) дә шул “сикерешле күчеш”кә әзерлек, дип карарга кирәктер. Күрәзәчелек итмәс өчен, бу язманы ишарәле кайбер фактлар китерү белән генә тәгәлләрбез. Менә алар. АКШ һәм НАТО белән үткән сөйләшүләр сериясен Мәскәү уңышсыз, дип таныды. Россия Украинага басып керергә җыенмавын белдерсә дә, үз гаскәрләрен аның чикләреннән алмый. Ак Йорт - Россиянең Украинага гыйнвар-февраль айларында басып керергә җыенуы, Пентагон исә моның өчен аның төрле диверсияләр куллану мөмкинлеге турында да белдерә. Кремль АКШ әзерли торган яңа чикләүләрне ике арада дипломатик мөнәсәбәтләрне өзүгә тиңли. Хәлбуки, зур сәясәттә Көнбатыш һәм Россиянең, капма-каршы яктан, әмма уртак максатларда эш итүен дә онытмыйк.

Фоат УРАЗАЙ.

Мәскәү дә ел бәйрәмен башлады

Ил башкаласында «Россия исламы: Россия мөселманнарының күп гасырлык тәҗрибәсен аңлау» темасына «Шиһабетдин Мәрҗани укулары» VII Бөтенроссия конференциясе пленар утырышы узды. Аның кысаларында Россия мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти шаех Равил Гайнетдин татар мәдәнияте һәм сәнгате эшлеклеләрен Россия мөселманнарының иң югары бүләге – «Әл-Фәхр» ордены белән бүләкләде.

Мөфти Гайнетдин кулыннан «татар халкына лаеклы иҗади хезмәт итүе, милли сәнгатьне үстерүгә, үсеп килүче буынны патриотизм рухында тәрбияләү эшенә зур өлеш кертүе өчен» «Әл-Фәхр» орденын Казан Татар дәүләт яшь тамашачы театрының баш режиссеры Ренат Әюпов алды.

Шулай ук «Әл-Фәхр» ордены белән татар әдәбиятын, тарихын һәм мәдәни мирасны өйрәнү һәм популярлаштыруга зур өлеш кертүе, рухи традицияләргә тугрылыгы өчен, 60 яшь тулу уңаеннан шагыйрь, «Безнең мирас» журналы баш мөхәррире Ләбиб Лерон бүләкләнде.

Конференция кысаларында Мәскәү Җәмигъ мәчетендә «Идел буе Болгары халыклары тарафыннан ислам динен кабул итүгә 1100 ел» күргәзмәсе ачылды.

Күргәзмә ике өлешкә бүленгән. Бер өлешендә – борынгы Болгарның архитектура-тарихи һәйкәлләре, икенче өлешендә – Россия мөселманнары Диния нәзарәте үткәргән чаралар тәкъдим ителгән. Бирегә Түбән Новгородтагы Ярминкә мәчетен реконструкцияләү, Халыкара мөселман форумын һәм XX Мәскәү Коръән укучылар конкурсын үткәрү, Мәскәү ислам институтында реконструкция эшләре күрсәтелгән.

Берләшеп эшләү мөһим

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразиев Башкортстан Республикасына чираттагы эш сәфәрен кылды. Бирегә ул бик күп очрашулар уздырды. В. Шәйхразиев Башкортстан Республикасы Премьер-министры урынбасары Азат Бадрановны Бөтендөнья татар конгрессы тарафыннан 2022 елга планлаштырылган чаралар белән таныштырды: алар арасында федераль округларда татар җәмәгатьчелеге белән очрашулар, Бөтендөнья татар конгрессының 30 еллыгы кысаларында съезд уздыру һ.б. бар.

Вице-премьер күп кенә төбәкләрдә ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуга әзерлек эшләре алып барылуын ассызыклады һәм Башкортстан Республикасында да оештыру комитеты булдыру мәсьәләсен күтәрде. Сүз уңаеннан, 1100 еллык кысаларында Уфада Россия ислам университетының яңа комплексын ачу да каралган.

Татар иҗтимагый оешмалары җитәкчеләре һәм активы белән киңәшмә Уфаның «Нур» татар дәүләт театры бинасында узды. Бирегә иҗтимагый, фәнни, дини берләшмәләр вәкилләре, мәдәни-агарту үзәкләре җитәкчеләре докладлар белән чыгыш ясады.

Башкортстан Республикасы Дәүләт җыелышы – Корылтай депутаты, Башкортстан Республикасы татарлары конгрессы Башкарма комитеты рәисе Заһир Хәкимов быел Башкортстан татарлары съездын үткәрү планнары белән дә уртаклашты. «Ул 9-11 июльгә планлаштырылган. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, Съезд алдыннан республиканың һәр шәһәрендә конференцияләр узачак», – диде Хәкимов.

Сәфәр кысаларында Милли Шура рәисе Бөтендөнья башкорт корылтае Башкарма комитеты җитәкчелеге белән очрашты. Чарада Башкарма комитет җитәкчесе Юлдаш Йосыпов, Башкортстанның мәдәният министры урынбасары Рәнис Алтынбаев һ.б. катнашты. В.Шәйхразиев А.Бадранов белән очрашуда да, Бөтендөнья башкорт корылтае вәкилләре белән күрешкәндә дә, Россиянең кайбер төбәкләрендәге, аеруча чит илләрдәге күп кенә оешмаларның татар-башкорт дигән исем астында берләшеп эшләвенә игътибар юнәлтте.

Булат бәйрәме

Г.Камал театрында иң халыкчан актерларыбызның берсе, Татарстанның халык артисты Әсхәт Хисмәтнең юбилей кичәсе узды. Заманында Камал театрына аны күренекле җырчы, композиторыбыз Мәсгуть ага Имашев ияртеп килгән була. Режиссер Марсель Сәлимҗановның композитор Алмаз Монасыйпов белән иҗат мәсьәләләре чишкән вакытка туры килә. Ә.Хисмәт “Күн авылы җыры”н, “Туган як”ны җырлый, шигырь сөйләп, уйнап күрсәтә. Шуннан соң аңа чыгып торырга кушалар. «Бир син миңа бу егетне, мин аннан икенче Илһам Шакиров ясыйм», – дип ялвара Алмаз Монасыйпов. «Юк инде, чордаш, ул миңа килгән, димәк, театрда уйнаячак», – дип кырт кисә режиссер. Шуннан соң Ә.Хисмәт театр училищесын тәмамлый һәм академия театрына эшкә килә. Татар халык җырларын тыңлап, җырлап үскәнгә, күрәсең, халыкчан артист буларак тамашачы мәхәббәтен яулый. Җырчы булып китмәсә дә, җырлаудан туктаганы юк. «Зәңгәр шәл»дә Булат ролендә, «Диләфрүзгә дүрт кияү» спектаклендә Җәмил ролендә булсын, тамашачыны авызына каратып тотарлык итеп матур җырлый. Шуңа күрә аңа җырлы рольләрне бирергә тырышалар. Рольләре кимеп китсә дә, аптырап тормый, театрда концертын оештырып җибәрә. Әсхәт Хисмәт башкаруында татар халык җырлары һәм композиторларыбыз әсәрләре яздырылган берничә лазер тәлинкә чыкты. Затлы җырлар гына тыңлап, җырлап үскән артист үзенең репертуарына гел матур, сыйфатлы иҗат ителгән җырлар гына сайлый. Уңышының сере дә шулдыр, күрәсең. Иркен агылган күе матур тавышын да телгә алырга кирәк, әлбәттә. «Җырлыйм әнием турында», «Хәтерләү», «Хушлашырга ашыкма», «Кашыңның каралары», «Аh, җаныем Бибисара» һәм башкаларын иҗат кичәсендә дә ишетергә мөмкин иде. Җитмеш яшьтә – өч сәгатьлек концерт! Тамашачы Ә.Хисмәтне рольләренең исемнәре белән ничек кенә атамый. Авыл эте Акбай, дип тә хәтерлиләр, Г.Хугаев әсәре буенча куелган спектакльдән Ишәк сыйфатында да күңелләрендә йөртүчеләр бар. Әмма күбрәк Әсхәт Хисмәтне җырлы рольләре аша беләбез, яратабыз. «Зәңгәр шәл» спектаклендә аны яшьрәк артистлар алмаштырса да, Ә.Хисмәт барыбер күңелебездә Булат буларак яшәячәк. Моннан күп еллар элек тәзелештә эшләп алган 110 сум хезмәт хакын артистларның 60 сумына алмаштырса да, Ә.Хисмәт тормышта күбрәк табышка иреште. Аның концерты саен зал тутырып яратып килә торган үз тамашачысы бар. Әнә алар яше-карты 60 меңлек телефоннарын юбиляр актерга терәп җырлавын яздыра. Ә иртәгә-берсекөнгә ул телефонга яздырылган видеолар бөтен интернет челтәрен әйләнеп чыгачак...

Юбилей кичендә артистны Татарстан мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин, Президент каршындагы мәдәниятә ярдәм фонды җитәкчесе Нурия Хашимова, якташлары – әлкилеләр, театр әһелләре, камаллылар тәбрикләде. Президент Р.Миңнехановның Указы нигезендә Ә.Хисмәткә “Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен” ордены медале тапшырылды.

Әсхәт Хисмәт бер дигән артист кына түгел, үрнәк ир, эти дә. Хатыны Рәшидә ханым шулай ук Камал театрында хезмәт итә, актерларга сакал-мыек ябыштырып, образга керергә булыша. Кызлары Гүзәлия, Гөлшат, төпчеге Илсөяр, әтием, дип өзелеп тора. Улы Булат исә әтисенең балачак хыялын тормышка ашырып баянчы булды. Консерватория тәмамлаганнан соң, бүген ул «Мирас» инструменталь ансамблендә уйный.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

1 нче биттә – Татарстан Дәүләт Киңәшчесе, республиканың беренче Президенты Минтимер Шәрип улы Шәймиев. Фото: shaimiev.tatarstan.ru.

Казанда Коръәннең кульъязма мөсхәфе язылачак

Казанның Кол Шәриф мәчетендә Диния нәзарәтенең яңа проекты тәкъдим ителде – Коръәни Кәримнең кульъязмасын тантаналы рәвештә яза башладылар. Бу Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен рәсми кабул итүгә 1100 ел тулуга багышланган чараларның берсе һәм ул чараны бәйрәм итү буенча республиканың оештыру комитеты утырышына туры китереп үткәрелде.

Проект Изге Коръәннең беренче сүрәсе «Фатиха»ны каллиграфик язудан башланып китте. Бу уңайдан күпсанлы кунаклар – дин әһелләре, матбугат чаралары чакырылган иде. Башта Коръән укып дога кылынды, аннары оста хәттат – Казан каллиграфы Артур Писаренко ак кәгазьгә кара белән бөек сүрә юлларын язды.

Бу проект Коръәнгә, аның асыл кыйммәтен өйрәнүгә омтылыш уятыр дип көтелә. Моннан тыш, ул халкыбызның каллиграфия сәнгате юнәлешендә кайчандыр киң танылган булып та, хәзерге көнгәчә җуелган традицияләрен торгызуга да бер адым булачак. Коръәннең кульъязма мөсхәфен язу – Татарстан мөфтиенең Коръәнне зурлау юлындагы чираттагы зур адымы булып аңлашыла. Бу эшнең нәтиҗәсе булып үзебезнең хәттат тарафыннан кулдан язылган мөсхәф торачак, ул бастырылган тираж белән дә дөнья күрәчәк.

Гыйлмел –Хат – гарәп хәрефләрен язу кагыйдәләрен өйрәнүче фән. Һәрбер хәрефнең үзенең кануни рәвештә билгеләнгән, ләкин шрифтка карап аерылучы төрле язылышлары бар. Шрифт-хатның бер стиле кысаларында бер хәрефнең 100гә кадәр язылыш төрләре кулланыла ала. Хәрефләрнең кагыйдәләр буенча язылмавы хата санала.

Кульъязма мөсхәфләр әзерләү тәҗрибәсе бүген Согыд Гарәбстаны, Төркия, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Бәхрәйн, Күвәйт, Катар, Ливия, Марокко һәм Пакыстанда бар. Хәзер бу эш Казанда да башланды. Теге яки бу сүзләрне төгәл, хатасыз язар өчен белгечләребезгә беренчел чыганакларга, фәнни хезмәтләргә мөрәҗәгать итәргә, һәр хәрефне һәм авазны кат-кат тикшерергә туры киләчәк. Мөсхәфтә сүзләрне һәм хәрефләрне дөрес һәм сәнгати итеп язудан тыш, язуның ачык һәм аңлаешлы булырга тиешлеген дә онытмаска кирәк. Мөсхәфне төзегәндә кануни яктан хаталар китмәсен өчен нәзарәт белгечләре Муса Бигиевнең «Тасхих рәсми хат» һәм Шиһабетдин Мәрҗанинең «Фәваид әл-Мүһиммә» хезмәтләренә дә таяначак. Бу хезмәтләрдә мөсхәфне төзү алымнары бәян ителгән.

Проектның төп башкаручысы итеп Казан хәттаты Артур Писаренко сайлап алынган, ул үзе танылган каллиграф, Россия ислам университеты каршындагы «Ән-Нәмир әл-Мухаттат» гарәп каллиграфиясе һәм ислам сәнгате үзәге директоры Рамил Насыйбулловның шәкерте. Әлеге эшкә киңәшче сыйфатында Дубайдан дөньякүләм танылган мөселман галиме, дин әһеле, Дубайның Коръән әзерләү комиссиясе башлыгы, хафизлыкның югары дәрәҗәсенә ия булган, Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.)нең нәсел дәвамчысы булган шәех Мәэмүн әр-Рави җәлеп ителгән.

«Казандагы Коръән мөсхәфен язу ике еллап дәвам итәр, дип уйлыйбыз», – диде мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин.

Эльмира СИРАҖИ.

Киң кырлы әдип иде

Татар җәмәгатьчелеге зур югалту кичерде. Танылган язучы, журналист Заһид Мәхмүди вафат булды.

Заһид Борис улы Мәхмүдов 1960 елның 4 июлендә Татарстанның Кукмара бистәсендә эшче гаиләсендә туа. Урта мәктәпне тәмамлагач, Казан дәүләт мәдәният институтында белем ала. Студент елларында көндәлек матбугатта актив языша, «Чаян» журналында, «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») һәм «Татарстан яшьләре» газеталарында дистәләгән юмористик һәм фантастик хикәяләрен бастыра. 1984 елда гаскәри хезмәттән кайткач, З.Мәхмүди Кукмара район газетасында әдәби хезмәткәр булып эшли, каләмен драматургиядә дә сынап карый: «Көнче кубәләк» исемле комедиясен яза. 1988 елда Казанга күчеп килә, «Татарстан» радиосында балалар тапшырулары мөхәррире, «Шәһри Казан» газетасында әдәби хезмәткәр булып эшли. 1991 елда аның балалар өчен «Профессор Мияугол» дигән фантастик хикәяләр җыентыгы басылып чыга. 1993–1998 елларда Заһид Мәхмүди «Татарстан» журналы, «Татар иле», «Мәдәни җомга» газеталары редакцияләрендә әдәби хезмәткәр, аннары «Казан» радиосында мөстәкыйль, хосусый татар бүлеге оештырып, аның җитәкчесе һәм дикторы булып эшли. Әдипнең мажаралы кыйссалары һәм хикәяләре тупланган «Ак болыт» исемле китабы басыла. «Әче балан» исемле китабы укучылар һәм әдәби тәнкыйть тарафыннан җылы кабул ителә. Соңгы елларда З. Мәхмүдов "Себерке" газетасын чыгарды, фермерлык белән шөгыльләнде. Улы Фәнис Камал белән бергә киностудия оештырып, фильмнар да төшерде.

Киң эрудицияле, үзенчәлекле карашлы әдипнең якты истәлеге күңелләрдә озак сакланыр.

Тукай дусты – тәүге большевик

Журналист, беренче татар большевигы Хөсәен Ямашевның тууына 140 ел тулды. Шул уңайдан бүген Габдулла Тукай музеенда 12 нче татар гимназиясе укучылары катнашында музей-дәрес уздырылды.

Хөсәен Ямашев 1903 елда РСДРП(б)га керә һәм Казан комитетының татар төркемен җитәкли. Ул беренче татар революцион «Урал» газетасын чыгарган журналист буларак та билгеле.

Чараның Тукай музеенда узуы очраклы түгел. «Милли музей фондларында Хөсәен Ямашевның аерым архивы, коллекциясе бар. Сөт савыты һәм Хәдичә Ямашеваның чәч кыстыргычын куя торган савыт, керамик савыт-саба куелган. Моннан тыш, Милли музей йортында язу өстәлендә торган предметлары саклана», – дип сөйләде Г.Тукай музееның өлкән фәнни хезмәткәре Лена Тябина. – Большевиклар, революционерлар турында татар әдәбиятында иң беренче булып Тукай язып чыга. 1910 елда «Бер мән» дигән шигыре басыла. Ул шигырьне Хөсәен Ямашевка багышлаган, диләр».

Хөсәен Ямашев вафатыннан соң да Тукай «Хөрмәтле Хөсәен ядкяре» шигырен яза. Лена Тябина бу шигырьнең большевик образы чагылган иң беренче әсәр булуын әйтте. Ул шигырьдә Тукай Ямашевның кадерен исән чакта белмәдек, дигән үкенү белдерә.

Зилә МӨБӘРӘКШИНА.

Аксак Тимер – безгә кирәк түгел!

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

Ни галәмәт, алар хәтта чиркәүләрендә дә 1395 елның 26 августын (8 сентябрен) Русьнең Тамерланнан могҗизаи котылу көне дип билгеләп үтә. Алар мантыйгы буенча, изге көндер, шайтан. Болгарга мөселман калаларының җимерелеп бетүе, йөз меңләгән мөселман кырылу – һәммәсе дә бәйрәм. Ләкин нишләп алар Аксак Тимер һәйкәлен Самара җиренә, Татарстан чигенә куюны хуплаган соң? Тарих эзенә кайтсаң, Аксак Тимер 1395 елда әле Кавказдагы Терек елгасы ярында да Туктамыш хан гаскәрен янә бер мәртәбә тар-мар иткән. Шул ук Аксак 1402 елда Анкарадан 180 чакрымда Баязит Елдырым гаскәрен дә пыран-заран китереп бетергән, Баязитның үзен әсирлеккә алган. Шул ук Аксак Тимер бүгенге Әфганстан, Һиндстан, Мисыр өстенә дә зур яу белән барган, аларда да йөзләрчә мең халыкны кырган. Үз аягы баскан бер генә дәүләттә дә нииндидер яңа мәчет, сарай яисә күпер төзетмәгән, фәкать яндырган, җимергән һәм талаган гына. Ул бернинди дә дәүләт эшлеклесе түгел, вандал, юлбасар, кешеләр суючы һәм кансыз җәллад! Үзбәкстан хөкүмәтенең Аксак Тимерне куккә чөясе килсә, ул аның һәйкәлен Әфганстан, Һиндстан, Кавказ республикаларына, ахыр чиктә Төркиягә илтеп куйсын иде. Әһә, үзбәк варварын азат дәүләтләр үз җиренә кертми, борынына сугып, кире боралармы? Тик татарлар гына коллар гавамы шул, алар ел саен 800 миллиард сумлык ясак озатып та ярый алмый, алар йөзенә килеп төкерсәң дә була...

"Алтын Урданы өйрәнүчеләр ассоциациясе", дистәләгән галимнәрдән, шул исәптән фән докторы В.Трепавловтан да кул куйдырып, Россия һәм Үзбәкстан хөкүмәте башлыкларына, Самара өлкәсенең губернаторы Д.Азаровка хат юллаган. Алар, әлбәттә, хакимият иярләрен акылга килергә һәм җәллад сәргаскәргә һәйкәл куюдан тыелырга чакыра. Язучылар берлегендәге түгәрәк өстәл артына җыелучы галим һәм әдипләр дә бу мөрәҗәгатьне бертавыштан хуплый. Безнең мәркәзебездә хәтта Казан ханлыгына нигез салучы Олуг Мөхәммәт хан белән Болгар дәүләтенә ислам динен кабул иттерүче Алмыш хан хөрмәтенә дә һәйкәлләр куелмаган. Әлеге тыюлар һәм "уяу" җитәкчелек – олуг Мәскәү эше. Безгә Явыз Иван яисә җәллад Тимер варварлыгын калкытырга теләгән һәйкәлләрнең кирәге юк! Татар халкы өчен Олуг Мөхәммәт белән Алмыш ханнар хөрмәтенә һәйкәл куйдырыгыз!

● Франциядә берәү лотерейдә 200 миллион евро откан: Le Parisien исәпләп чыгаруынча, бу акчага ул ике Airbus A320 лайнеры, 4 меңнән артык алтын коелмасы сатып алыр, шулай ук дөньяда иң кыйбатлы кунакханәдә 2430 тәүлек яши алыр иде.

● Кит өч ай йокламый түзәргә мөмкин; ә инде йокыга китсә, бик акрын гына аска төшә, аннары койрыгы белән суккалап ала да, кабат өскә күтәрелә, сулыш алгач, черем иткән килеш тагын акрын гына аска төшеп китә.

● Финляндиядә, машина бәрдермәсен өчен, боланнарның мөгезенә яктылыкны чагылдыра торган махсус спрей сиптерәләр.

Татарның Садри Максудигә тиң шәхесләре бармы?

90 нчы елларда милли хәрәкәттә актив катнашкан Азат Сәйфетдинов бер әңгәмәсендә XX йөз башы татар матбугатында чыккан карикатуралар турында һәм гомумән, татар матбугаты турында фикер йөртә.

Аның фикеренчә, ул заман татарлары дөньяга киңрәк караган. Укучылар үз төбәге белән генә түгел, бик күп илләр белән кызыксынган. «XX гасыр башы татар матбугаты бөтендөнья хәлләре, вакыйгалары турында язган. Хәзер татар, бер урынга – Татарстанга ябышып, шул республика белән генә кызыксына. Казан матбугатының чит илләр белән кызыксынуы «Татарлар бәйрәм уздырды» дигән язмалардан артмый, чит ил хакында язганда да, әйтик, «Минзәләгә Германиядән терлек җиһазлары кайтарылды» дип кенә язабыз. Ул заманда Садри Максуди Төркиядә Ататөрекнең киңәшчесе кебек дәрәҗәдә булса, бүген Төркия президенты Эрдоган белән сөйләшә алырлык сәясәтчеләребез күренми, ди ул.

Без татар зыялыларының әлеге фикергә булган карашларын сораштык. Татар матбугаты ни өчен дөньякүләм дәрәҗәгә чыга алмый? Чынлап та, татар милләте вакландымы? Бүгенге көндә дә Йосыф Акчура, Садри Максуди кебек мәшһүр кешеләребез туа аламы икәнен белештек.

● Дания Заһидуллина.

● Лилия Габдрәфикова.

● Раил Фәхретдинов.

● Фәнис Зыялы.

● Дәниз Бәдретдин.

Әдәбият галиме, филология фәннәре докторы, КФУ профессоры Дания Заһидуллина:

– Бу фикер белән өлешчә килешергә дә буладыр. Әмма XX йөз башы һәм XXI йөз башы вәзгыяте бөтенләй башка. Мәсәлән, XX гасыр башында әлеге мәгълүматны татарлар бары татар матбугатыннан гына алганнар. Ә бүген безнең ул мәгълүматны интернет аша, теләсә нинди ачык чыганактан алу мөмкинлегебез бар. Шуңа күрә әлеге мәгълүмат ачык чыганакларда бар икән, аны кабатлап язу бәлки мөһим дә түгелдер.

Бүгенге татар матбугатына аналитик язмалар, ниндидер күзәтүләр, бәлки, шәхси фикер-карашларны, гомумән, Татарстан масштабында гына түгел, ә дөнья масштабындагы татарга караган карашларны бирү җитмидер.

Үз заманының пәйгамбәрләре юк, дип әйтәләр. Үзләре яшәгән вакытта Садри Максуди, Йосыф Акчураларны да татар җәмгыяте җитәрлек дәрәҗәдә белеп бетермәгәндер. Бүген дә зур дәрәҗәләргә ирешкән, дөнья күләмендә танылган галимнәребез бар. Мәсәлән, Юлай Шамил углы, Тәхсин Җәмил. Алар – югары дәрәҗәдә инглиз телендә, Европа илләре телләрендә төрки татарларның тарихы, мәдәнияте хакында өр-яңа мәгълүматларны дөньяга чыгара торган зур галимнәр. Рәшит Сүнәев һәм Юлай Шамил углы Татарстан, аның перспективасы, татар милли үзаңы турында һәрдаим чыгышлар ясап килә.

Бәлки, менә шушы мәсьәләдә татар матбугатына җитми торган шундый бер якны да күрәбездер. Татар матбугаты эстрада артистларының көндәлек тормышын яктырту белән күбрәк шөгыльләнмиме икән? «Җитди кешеләр, фән кешеләренең тормышын яктырту укучыга кызык булмый бит», – дигән фикерне, мәсәлән, шундый материал белән барган очракта үзем дә ишетәм.

Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты фәнни хезмәткәре, тарих фәннәре докторы Лилия Габдрәфикова:

– XX гасыр башындагы татарлар татар теленнән башка телләр белмәгән, рус телен белүчеләр аз булган. Госман империясендә чыккан газеталарны алып укыганнар. Алар өчен ул мәгълүмат, яңалык белүнең бер каналы булып торган. Хәзер Россиядә яшәүче татарлар рус телендә укый.

Йосыф Акчура яшь чагыннан Төркиядә яшәгән, ул шунда формалашкан кеше. Бу күбрәк сәясәткә дә бәйле. Ул вакыттагы һәм хәзерге вәзгыятьне чагыштыру бик үк дөрес түгел. Ататөрек заманында Төрек республикасы формалашкан гына вакыт, яңа дәүләт барлыкка килгән. Татар зыялылары интеллектуаль дәрәҗәләре белән аерылып торган, Европалашкан булулары белән дә. Бүген дә бар андый кешеләребез.

Безнең татарлар бик тә тәнкыйтьләргә ярата. Һәр кешене теге җиргә, бу җиргә җитешсез дип тикшереп, зарланып ятып була. Татарлар менә бу тәнкыйтьләп яту эшеннән баш тартырга тиеш.

Тарих фәннәре докторы, КФУ профессоры Раил Фәхретдинов:

– XX гасыр башында вәзгыять икенче, безнең дәүләтебез юк иде. Бүген нинди булса да, дәүләтебез бар. Ул вакытта икенче проблемалар булган, мәсәлән, шул ук милли хәрәкәтне күтәрү. Проблема шунда: 1552 елдан соң безнең элитаны бетерәләр, мәдәният бетә. Аннары соң әкрен генә аякка баса башлыйбыз. XIX гасыр азагы-XX гасыр башы – мәдәниятебезнең, иҗтимагый фикернең чәчәк ату вакыты. Революциядән соң безнең элитага тагын бер һөҗүм ясала. 90 нчы елларда тагын бер милли хәрәкәт көчәеп, татарның милли аңы үсеп китә.

XX гасыр башында татар шәхесләре дискуссиягә керә. Садри Максуди милли республикаларга каршы чыга. Татар халкы – сибелгән халык инде ул. Аерым бер республика төзесәк, мәсәлән, Себер, Әстерхан татарлары республикадан тыш кала. Ул вакытта берничә вариант булган: Идел-Урал кебек территориаль автономияләр, Татар-башкорт республикасы, соңрак Татар республикасы һәм Милли-мәдәни мохтарият. Аның авторы Садри Максуди. Ул сибелгән татар халкына территориаль автономия кирәкме икән дип сорау куйган. Садри Максудиның үз мантыйгы булган, алга карап фикер йөрткән кеше ул. Татарлар өчен зур бер парламент оештыру идеясе белән дә чыгыш ясаган.

Бүгенге көндә Татарстанга татарның кечкенә генә бер төркеме кергән. Калган татарлар өчен Садри Максудиның милли-мәдәни мохтарият идеясе бик туры килә. Татарларга бер уртак парламент төзергә кирәктер дип уйлыйм. Россия эчендәге татарларны берләштерә торган татар парламенты булырга тиеш. Садри Максуди фикеренчә, бу парламент дин мәсьәләләрен хәл итәргә тиеш, монда мәдәният һәм милли мәгариф системасы да керә.

Дини сорауларны, мәдәният проблемаларын хәл итәргә кирәк бит. Аны бер Татарстан гына эшләп һәм аңа акча табып бетерә алмый. Бу парламент әлеге сорауларны үз өстенә алыр иде.

Төркиядә яшәүче татар шагыйре Фәнис Зыялы:

– Азат әфәндене әйткән бу сүзләрен бизмәнгә салсак, «дөрес» ягы басачак шикелле. Чит илдә генә түгел, үзебездә дә «Татарлар Сабантуй үткәрде», «Гөрләтеп концертлар узды», «Егылганчы биедек», «Түрәләр чәк-чәк белән каршыланды», «Укытучыларга сертификатлар бирелде» сүзләреннән ары китми шул. «Татарлар азатлык өчен көрәшә», «Хәтер көнендә мәйданда урын калмады», «Мәктәпләрдә татар теле дәресләре арттырылды, бөтен укучылар татарча сөйләшә», «Түрәләр милләт белән бергә», «Татарстан халкы татар телендә генә сиптерә», – дигән кебек хәбәрләрне Казаныбызда ишеткәнегез бармы?

Анталиядә Сабантуйлар, концертлар үткәрелеп кенә калмый, ә милләт өчен файдалы очрашулар оештырыла. Мәсәлән, Разил Вәлиев, Фәүзия Бәйрәмова һәм Себер татарлары белән очрашу, фикер алышулар булды. Муса Җәлил истәлегенә шигырь кичәләре уздырылды.

Татар матбугаты дөньякүләм дәрәҗәгә ирешү өчен, беренчедән, илеңнең ирекле булуы, икенчедән, сиңа терәк булырлык ирекле ил җитәкчеләре, хәбәр һәм хәбәрчеләрнең дә ирекле булуы кирәк. Хәбәрченең өсте бөтен, тамагы тук булырга тиеш.

Киң колачлы фикер йөрткән кешегә бездә колач җәелми. Өченчедән, дөньякүләм икътисади кризиста яшибез. Халыкның яшәү кайгысы бар. Бу кыйбат заманда исән калу, тормыш алып бару кайгысы бар. Безне дөнья мәшәкате чорнап алган. Сүз иреге юк, демократия юк.

Газиз телебезгә балта чабылган бу дәвердә милли активистлар, шагыйрьләр, язучылар, әйдаманнарның җаны телгәләнә. Әсәрләре, фикерләре шуңа дәлил. Телне үстерү дәүләт дәрәҗәсендә эшләнергә тиеш. Түрәләрдә бу кайгы булмаса, милләтпәрвәрләр белән генә кылына торган эш түгел. Ирекле булмаган илдә аларның каләмен сындыралар. Элек кылыч белән турасалар, хәзер мәхкәмә карарлары белән интектерәләр. Үзгәреш юк.

Татар таратылды. Татарны һәм аның телен юк итү сәясәте дәүләт дәрәҗәсендә алып барыла. Татарны бүлгәләү, санын кимету өлкәсендә мәкерле эш алып барыла. Безне гасырлар буена бастыралар. Геннарыбызга курку орлыклары салынган. Бу курку нәселдән нәселгә кан белән күчкән. Шуның өчен бердәмлек юк. Әмма да ләкин иманлы яшьләребездә өмет бар. Ишле балалы гаиләләребез бар. Ул гаиләләрдә телебезгә, динебезгә мәхәббәт тәрбияләнгән очракта безне бернинди көч-куәт тә туктата алмый. Без күрмәсәк тә, безнең оныклар заманында телебез дәүләт теле булачак. Байрагыбыз күк йөзендә җилфердәячәк. Өметсезлек шайтанда гына бар. Өмет белән яшик!

Эстониядә яшәүче Финляндия татары Дәниз Бәдретдин:

– Бер яктан Азат Сәйфетдиновның сүзләрендә хаклык бар, шулай да 100 процент ук түгел. 1992 елдан башлап сез безне (Финляндиядәге татарларны) әллә нинди әүлияләр итеп күзаллап яза идегез. «Аһ, Финляндия шулай, болай», – дип. Безне бит май белән мармелад ашап кына яши, дип уйлыйлар иде. Тора-бара кызыксыну кими төште.

Бердәмлегебезне җыю – конгресс эше, минемчә. Ул безне күбрәк бергә тотарга тырышырга тиеш. Татарстаннан читтә яшәгән диаспораларның кирәк булуы, алар белән аралашу өчен күп көч тә, акча да кирәк. Әлеге эш өчен Татарстан дәүләте бюджетыннан акча бүленеп бирүе кирәк. Һәрбер эш акча сорый. Татарстанны Европага күрсәтү өчен дә күп акча һәм иганәчеләр кирәк. Аны кемдер алып барырга тиеш, планлаштырып, әлеге проектларның дәвамлылыгын кайгырту да зарур. Татарлар җыелышып сөйләшә дә, аннары бөтенесе өйләренә тарала. Шуның белән бөтен эш тә бетә.

Без тыштан торып сезгә тыгылып нәрсә эшләргә кирәге турында өйрәтеп утыра алмыйбыз. Моның кирәкле адым икәнен беренче чиратта Татарстан аңларга тиеш. Ул чакта диаспораларның да мөмкинлеге барлыкка киләчәк.

Ләйсән РӘХМӘТУЛЛИНА.
Intertat.tatar

Атнаның сәяси мизгелләре

КАЗАХЧА "ХАКИМИЯТ ТРАНЗИТЫ"

Бер казанга ике тәкә башы сыймый, ди мәкаль. Яңа ел башыннан Казахстанда урын алган вакыйгалар моны тагын бер кат раслады. Рәсми мәгълүматлар, гадәттәгечә, бик коры: 2 гыйнварда Жанаозен һәм Актау калаларында газга бәя 2 тапкыр арту сәбәпле башланып киткән тыныч митинглар, колачлы протест акцияләренә әверелеп, илдә зур тәртипсезлекләргә, елбасы (Н.Назарбаев) һәйкәлен егуга һәм корбаннарга да китергән. Халык таләбен исәпкә алып, Казахстан президенты К-Ж.Токаев 5 гыйнварда хөкүмәтне отставкага җибәргән, ярдәм сорап, ОДКБ илләренә дә мөрәҗәгать иткән. ОДКБ шурасы, тиз арада карар кабул итеп, Казахстанга 5 илдән тынычлык урнаштыручы көчләр керткән, алар исә мөһим объектларны сак астына алган. Токаев әйтүенчә, бу чорда илдә 20 мең чамасы террорчы эш иткән. Кискен чаралар күрелү нәтиҗәсендә, тәртип бозган 5 меңләп кеше кулга алынган, һәлак булучылар саны исә 225 кешегә җиткән.

Токаев Казахстандагы фаҗигане оештыруда чит ил террорчыларын гаепли, әмма бер генә террорчыны да тотып күрсәтә алмады. Кремль исә хәлне, гаепләләр эзләү Россия эше түгел, суверен дәүләтнең үз эше, дип аңлатты. Ә сәбәпләрнең ярылып ятканнары да бар. Беренчесе – халыкның илдәге социаль гаделсезлекләр аша күптәннән җыелып килгән канәгатьсезлеге. Бу хакта Токаев: "Благодаря первому президенту – елбасы, в стране появилась группа очень прибыльных компаний и прослойка богатых людей даже по международным меркам. Считаю, что пришло время отдать должное народу Казахстана и помогать ему на системной основе", - дип белдерде. Ә илдә "хакимият транзиты" ике үзәкле итеп корылган иде: Н.Назарбаев калдырган президент Токаев һәм ул үзе – илнең Иминлек шурасы рәисе. Бу вазифа аңа гомерлек тәгаенләнгән, шуңа хәтта аны алыштыру механизмы да каралмаган. Тик "транзит" аныңча барып чыкмады. Моннан кем отты соң? Бу сорауга җавап күп нәрсәләргә ачыклык кертә ала. Күпләр өчен төп отучы – Токаев, чөнки ул, Иминлек шурасын да җитәкләп, илдә тулысынча үз хакимлеген урнаштырды. Ә Дәүләт Думасы депутаты В.Никонов фикеренчә, ОДКБ буенча союздашлары белән үзенең хәрби егәрен күрсәтеп, геосәяси җиңүгә Казахстанда Мәскәү дә ирешә.

Н.Назарбаевның язмышы әлегәчә билгесез кала. Илдәге фаҗига көннәрендә аның исеменнән матбугат хезмәте генә, Иминлек шурасы рәислегеннән үз теләге белән китүе һәм Токаев тирәсендә тупланырга чакыруы турында белдерү ясады. Үзе исә – ләммим. Дөрес, якыннарының җитәкче вазифалардан китүе хакында да хәбәрләр булды. Назарбаевның соңгы тапкыр халыкка күренүе исә 28 декабрьдә Санкт-Петербургта, БДБ лидерлары саммитында булган. Ул анда В.Путин белән күзгә-күз сөйләшкән. Аның авыру көенчә "падишаһ" катына китерелү сәбәпләре әлегә ачык кала.

Фоат УРАЗАЙ.

P.S. Бу язма әзерләнүгә, Н.Назарбаевның видеомөрәҗәгате чыгуы мәгълүм булды. Ул анда үзенең Казахстанда калуы, Нур-Солтанда лаеклы ялда булуы, беркая да китәргә җыенмавы турында әйтә.

Талант бөеклеге

(Татарстанның халык шагыйре Ркаил Зәйдуллага 60 яшь)



Халык әдипләре Рабит Батулла, Разил Вәлиев, Ркаил Зәйдулла.

Ркаил – сурәтләр (образлар) шагыйре. Безнең шагыйрьләр сурәтле чаралар табуда бер-берсен уздырып ярышалар кебек. Кайвакытларда мондый эзләнү-ярышлар артык төчелеккә, тар даирә генә аңларлык нәтиҗәгә китерә. Хәер, сурәтсезлеккә караганда, артык сурәтлелек яхшырак.

Сурәтлелек мәйданында шагыйрь Ркаил Зәйдулла үз-үзе белән ярыша.

* * *

Җилне бөгәрләп
мин кесәгә салдым.

* * *

Кара урман карынында
Шулай төн яралды.

* * *

Яратамы, яратмыймы, диеп,
Күз яшьләрем йолкый керфегемне.

* * *

Ашыга-ашыга киенделәр кешеләр,
һәм агачлар акрын гына чишенде.

"Көз" исемле шигырьдәге бу ике юл көзге табигатьне күз алдына китерде дә бастырды. Нинди сурәтлелек!

Р.Зәйдулланың иҗатыннан аерып алынган канатлы тәгъбирләр.

* * *

Искән җилдә мин очырдым мескенлекне...

* * *

Толларның мендәре җылырак.

* * *

Әүлия дип саналганнар күптән
басты Азатлыкның күзенә.

* * *

Татар сүзен күккә чөябез без,
ә карасаң аска – беркем юк.

Тагын бер генә шигырьне, искиткеч гүзәл сурәтле шигырьне мисалга китерәм дә сурәтлелек турындагы сүз куертуымны төкәндерәм. "Төнге рәсем" дип атала ул.

* * *

Хуш исле печән җәелгән
Арба теркелди юлдан.
Хуш исле печән өстендә
Малай йокыга талган.
Янәшәсеннән баралар
Абыйсы да әтисе...
Ә дөнья...
Дөнья шундый –
Дөньяда чәчәк исе.
Мәңге онытылмас бу төн.
Сәхра, йолдызлар, ирек.
Нарасый бара арбада,
Әнисен төштә күреп.

"Печән өмәсе" әсәрендә Ркаил гап-гади печән чабуны сурәтләп, мәхәббәтнең тулы бер шигъри кыйссасын хасил иткән.

* * *

Пакуслар, хыяллар кебек,
Офыкларга тоташа,
Болын буйлап йөгерә сылу,
Күңелләр таша, таша...
Чалгыны ташлап калдырам,
Элгәре дәрт тамырда,
Онытыла дөнья гаме,
Утлы караш – яндыра.
Омтылам аның артыннан,
Йөрәгем кага – тоймыйм.
– Сөям! – дип шашып кычкырам,
Кайтаваз килә:
– Сөй-мим!

Беренче мәхәббәтнең шигъри тәмен татып багар өчен бу поэманы тулысы белән укып чыгарга кирәк.

Каһарман "сабый-үсмер-аксакал" метаморфозаларын уза. Каһарманның юлы мәхәббәт маҗаралары, ватанга, тарихи узганга җирсү аша кичә. Ул җиңелә, җиңә, ялгыша, мәхәббәтен, хакыйкатьне эзли.

* * *

Иртән торсам, бөтен дөнья үзгәргән!
Эт тә хәтта бүтәнчә өрә –
аның янындагы мөлдерәмә тазда
кояш су керә.
Иртән торсам, бөтен дөнья үзгәргән.
Иң гаҗәбе: үзгәргән күрше кызы –
Тәнзилә...

* * *

Яна йөрәк, шаша җаным,
Таша дәрман, таша дәртем,
Каян эзлим?
Ник табылмый
Җан ачкычы-мәхәббәтем.

* * *

Кил, сөеклем, ташлан кочагыма, –
Үрсәләнеп минем җан яна!
Син ут өстә аңа, мин бит бары
Янар өчен килдем дөньяга.

* * *

Авылыма мин бик сирәк кайтам,
Урамнары хәзер тар аның.
Карап узам сезнең уйчан йортка,
Тәрәзәндә ут юк – караңгы.
Чыр-чу килеп этәй-әнәй чыга,
Әби килеп житә...
Мин кайттым!
Ни таптым мин туган яктан китеп?
Беләм ләкин: нидер югалттым.
Сезнең уйчан йортка карап узам,
Йоклыйсыңдыр. Китәм күрешми.
Атлап узар идем бусагаңны,
Шәһәр кешесенә килешми.

* * *

Бернәрсә дә кирәк түгел бүтән.
Бер елмаеп бакса чибәр кызый.

* * *

Ләкин
Яткан сәгатьтә бүтәннәр
Җылы куенында –
Муенында минем ирен эзләре
Сулкылдап уятыр сине...

* * *

Тыныч кына карап буламы соң
Тәннең җанга сагыш өюен?!
Юкка чыга, эреп бетә әнә
Ятлар кочагында сөюем.

Р.Зәйдулланың каһарманы гомере буе саф мәхәббәт эзли, үзен яратуларын тели, еш кына ул максатына ирешә алмый: яки аны ташлап китәләр, яки ул үзе гыйшкыннан бизә, яки аның мәхәббәте ерактан гына, соклану, кызыгудан һәм үкенүләрдән генә тора. Сөйгән ярын табалмаган ярның сагышы, җирсүе укучыга тәэсир итә дә. Бөек гашыйкларның язмышы фаҗигале булган.

Яланаяк чакта беренче тапкыр кызга күз төшергән сабый алга таба үлеп гашыйк була, егет булгач, ératудан жаны актарыла, ир булгач та яна-көя, сөя, сөелә, ләкин, әйткәнемчә, аның мәхәббәт көймәсе әле үз ярына сыена алмый.

Азакта каһарман сөйгәне белән кавыша. Алар бергә, алар бер ятакны уртак иткән.

* * *

Күз яшедәй бәллүр дулкын килеп
Ялан аягымнан үбә тагын.
Кагылам да аккош иңнәренә,
Мин сәҗдәгә сине уятамын.

Нинди камиллек, вәссәлам!

Ркаил Зәйдулланың сөю турындагы бөтен шигырьләрен аерып алып, бер җепкә тезсәң яки аерым китап итеп чыгарсаң, гаҗәеп бер "Гыйшыкнамә" пәйда булыр иде.

БАТУЛЛА.

Ерагаер якын дигәнебез, Якынаеп китәр ераклык...

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА, Татарстанның халык шагыйре

КӘРВАН

Кәрван уза бер-бер артлы акрын
Һәм югала дала түрендә.
Аксыл тынлык. Кояшы да хәтта
Өстә аксылланып күренә.
Кәрван-сарай.
Тарих тузанынннан
Диварлары бераз каралган.
Бәйле җанвар сыман кымшана ул,
Иркен дала гүя тар аңа.

Мускус исе, имбир исе монда...
Салмак кына төтен тарала.
Кәрван бара!
Мин ап-ачык күрәм,
Ничә гасыр юкса арада.

Кара атка менгән кәрванбашы
Белә булыр кая барасын.
Мөҗәвиргә* генә юллар ябык,
Салкын ташка терәп аркасын,
Утыра ул һаман алга карап.
Кәрван арты кәрван агыла.
Тик мөҗәвир кала дога кылып,
Тик мөҗәвир – хәтер сагында!

Тук чырайлы сәүдәгәрләр үтә,
Хаким алар мәңге бу юлга.
Колларының аяк тавышыннан
Хәтер күзләренә ком тула.

Кәнизәкләр керфегендә тамчы
Кояш кебек эре һәм төссез...
Текәлсәгез озак, соңгы йолдыз
Шартлаганын анда күрерсез.

Кәрван арты кәрван үтә җирдән,
Ә юллары әле, һай, озын.
Ак күлмәкле нарасыйлар уза, –
Күлмәк якалары кып-кызыл.

Бер үк эзгә басып үткән кәрван
Офыкларга җиткәч сүтелә...
Һәм яңасы пәйда була юлда, –
Алар шуңа хөкем ителгән.

Берөзлексез тоташ хәрәкәт бу.
Һәм иркенлек сыман әсирлек.
Кәрван бара!
Ә мөҗәвир елый,
Учларына йөзен яшереп.

*Мөҗәвир – «дәрвиш», «кабер сакчысы» мәгънәсендә.

* * *

Татар шагыйрьләре китә
Берәм-берәм... ялгызы...
Беркем дә игътибар итми, –
Дөньяда ыгы-зыгы.

Дөньядагы кешеләрнең
Һәр минуты исәптә:
Бәбәкләр бәйгегә чыккан,
Тырпаешкан терсәкләр.

Татар шагыйрьләре китә,
Ком шуышкан шикелле.
Ком астында авазлары
Кала, кала түгелеп...

Нинди моң эзлисең, и Җан,
Аны бит, әгәр баксаң,
Шәһәр гөрелтесе баскан.
Яңа заман! Яңа сан!

Татар шагыйрьләре китә, –
Биштәрләре җип-җиңел.
Соңгы туй гөрли дөньяда,
«Без монда кияү түгел».

Китә шагыйрьләр... Калдырып
Илнең алйот** түрәсен.
Мондый дөнья аларга шул
Кирәк түгел, күрәсең.

**Алйот – «комсыз» мәгънәсендә.

* * *

Марсель Галигә

Ык өстеннән күләгәләр шуа,
Төнне йоткан уйчан әрәмә
Кайсы кошның тавышын соң укшый? –
Хәләл дә ул безгә, хәрәм дә...
Кылыч болгап җайдагатлар үтә,
Тояк тавышлары – дөп тә дөп...
Актарылып керә нинди заман? –
Ай каядыр китә кителеп.

Яулары да шул ук, аулары да...
Без битараф инде... Кем уяу?
Кайсы канатлыны ымсындырып
Чакыра шулай өскә Чатыр тау...

Тонык кына күкрәү ишетелә.
Килер еллар безне бер аклар,
Шыпырт яла сыман яр астына
Егылалар кәрлә куаклар.

Күкрәү килә. Эчендәге кинә
Яшен ташы булып бер чыксын,
Кузгатсын ул гомер көзләрендә
Сүнгән өметләрнең җырчысын.

Бар да узар. Таллар гына һаман
Ык ярына ятып оерлар.
Без әйтергә теләгән сүз кебек
Суырылып чыгар суырлар.

БИТЛЕК

Аны кешеләр яратмыйлар иде:
Сәер уйлар иде зур башында...
Бәргәләнде, үзенә урын табалмады
Бу дөньяда, кеше арасында.

Әллә нинди сәер бер зат иде –
Яшерә алмады бездән уен-хисен...
Аның исеме... истә түгел хәзер,
Аның исеме... Исәр иде төсле.

Бармак төртеп көлдек без аңардан,
Сиздермәде, шундый горур иде.
...Тик беркөнне – Яңа елда бугай –
Ул түзмәде – битлек алып киде.

Этнекеме, әллә маймылныкы,
Мөһим түгел, хәер, андамы эш?
Пышылдаулар китте безнең арабызда:
Кара, ул да кешегә охшаган ич!

Күпме туташ гашыйк булды аңа,
Ә бит элек алмадылар санга...
Һәм ул көлде мыскыл белән бездән,
Һәм битлеген
Салмады беркайчан да.

БӘХӘС

Килеп керде тиз-тиз генә атлап,
Исәнләште,
Әйтте: «Йә, ни дисең? –
Искә төшердем дә яшәвемне,
Килдем сиңа бәхәсләшер өчен».
Һәм тиз генә килеп утырды да
сәгатен салып куйды
китап киштәсенә,
Йөзен салып куйды
Һәм тотынды...
Онытылды вакыт.
Иң мөһиме – Вакыт онытылды.
Ә югыйсә һаман тәкрарлыйм бит,
Төн артыннан көн килә, дим, һәрчак.
Каршы төшә: чыпчык дигән кош, ди,
Бервакытта да бөркет булмаячак.

...Һәм берзаман аңга килсәм,
бер кеше юк,
Иртәнге биш, кием утыра алда...
Шуның белән күпме гомер
бәхәсләшәм, имеш.
Ә мин...
Ә мин тәмам чишенеп беткәнмен бит,
Калганмын ич шыр ялангач килеш.

ИСЕМСЕЗ КЕШЕ

Аның исемен хәзер бер кеше дә белми.
Кулны тыгып актарсаң да,
Юк беркемнең хәтерендә,
Шулай яши ул карт, дәгъвасы юк...

...Ә иртәгә менә ул исемсез килеш
Тыйнак кына иңәр каберенә.
Карт-корыдан сорыйм: «Ул ни атлы?» –
димен.
Чордашлары аның, алар инде белә.
Ник белмәскә, соң, әлбәттә, энекәш!
Хәерниса түти малае ул, диләр.

Егетләрдән сорыйм: «Кем ул, ни атлы?» –
дим,
Карт турында миңа, бәлки, алар сөйләр?
Нишләп сөйләмәскә? Соң, әлбәттә инде,
Чибәр Хәдичәнең әтисе ул, диләр.

Тере кешенең исемен онытканбыз.
Архивлардан эзләп буладыр да, беләм.
Кем эзләсен ләкин?
Беркем кызыксынмый,
Кем йөресен, юләр, буш мәшәкать белән...

ТҮРКЛӘР

Да, скифы мы.
А.Блок

Түркләр без! –
Кысан бу дөньяга
Тудырган да безне Ашина,
Җилдергәнбез җитез тулпарларда
Җилләр, зилзиләләр каршына.

Түркләр без! –
Күзебез дә хәтта
Ук төзәргә диеп уелган.
Офыкларда югалабыз, чыгып
Тормыш дигән затсыз уеннан.

Түркләр без! –
Дөм караңгы төндә
Дала бүресенең юлдашы.
Таш диварлар кыса хәзер җанны,
Ерагая Күлтәгин ташы.

Түркләр без! –
Хәтер корбаннары.
Күзне йомып тып-тын тор гына,
Йөз меңнәрчә кылыч күтәрелә,
Һәм төмәннәр яуга ыргыла.

Түркләр без! –
Аларның да әле
Иң чыдамы икән ләбаса! –
Татар атын авыр аркан белән
Өстерибез гасырлар аша.

Түркләр без! –
Кеше арбасында...
Кулдан төште күптән дилбегә.
Сиздермичә әрнеп күз ташлыйбыз
Дөнья дигән атның биленә.

Түркләр без! –
Урман җәяүлесе
Адымнарын тыеп атласын! –
Арган җайдак камчы сабы белән
Кага яңа гасыр капкасын.

* * *

Халкым минем төнгә кереп китә,
Нефть суыра, иген игә дә...
Вакыт ага чәчем арасыннан,
Һәм төбәлә нидер чигәгә.

Җилгә оча сүзем. Әгәр дә ул
Арттыралса җилнең куәтен,
Көзге яфракларга уранырмын,
Давыл белән ябыныр оятым.

Беткән Хәтер, онытылган Тарих!
Тәрәзәсез-нисез туң йортта
Шат, бәхетле булып яшәү җиңел,
Әверелсәң гамьсез маңкортка.

Эндәшүем сезгә килешәме?
Юк, диярсез
Сез тук килеш, шат?
Горурлык та
эреп
юкка
чыга,
Үз җиреңдә булсаң килмешәк.
Минме синең улың, мокыт кавем?
Кем син?
Кайда?
Кемгә хезмәтең?
Үзеңә тиң дөрес тарихыңны
Кайсы гасырлардан эзләттең?

Башка менми, иңгә оешса кан.
Иңдә камчы эзе, йөк эзе...
Башка телле таш калалар баскан
Бабаларның изге нигезе
Убылса да, кабер булып убар.
Кубарылып чыгар бер халкың:
Ерагаер якын дигәнебез,
Якынаеп китәр ераклык.

РЕДАКЦИЯДӘН. Татарстанның халык шагыйре, прозаик, драматург, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе, Татарстан Язучылар берлеге рәисе, Татарстан Дәүләт Советы депутаты Ркаил Зәйдуллага шушы көннәрдә 60 яшь тула. Без каләмдәшебезне күркәм гомер бәйрәме белән ихластан тәбрик итәбез, аңа исәнлек-саулык һәм яңадан-яңа иҗат куанычлары телләп калабыз.

ЭРДОГАННАН

Төркия президенты Рәҗәп Тайип Эрдоган тарафыннан тәбрик ителгән беренче татар Ильяс Камалов белән әңгәмә.

Алтын Урда дәүләте чорына кагылышлы тарихи гыйльми хезмәтләрнең күплеге белән мактанып булмый. 1826 елда Россия Фәннәр академиясе «Монгол хакимиятенең Россиягә тәэсире» дигән фәнни хезмәтләргә бәйге игълан иткән. Чит ил галимнәренә дә ишеттерелгән әлеге бәйгегә игътибарга лаек бер әсәр дә тәкъдим ителмәгән. Россия Фәннәр академиясе 1832 елда теманы тарайтып, «Алтын Урда тарихы» дигән яңа бәйге уздыра. Әмма тагын уңышсызлыкка очрый, бәйгегә яраклы әсәрләр керми.

Совет чорында исә Алтын Урда тарихын тикшерү тагын да кыенлаша. 1944 елда КПСС Алтын Урда дәүләте чорын тикшерүне бөтенләй тыя. Төркиядә дә Алтын Урда тарихы читтә кала, өйрәнелмәгән тема булып яши.

Сембер якларында туып-үскән Ильяс Камалов Төркиягә килә дә, тарих бүлегенә укырга керә һәм чытырманлы карурманны хәтерләткән Алтын Урда тарихын өйрәнә башлый. Ул рус, төрек, инглиз телле хезмәтләрне дә тикшерә. Фарсы чыганакларыннан файдалану өчен Иран консуллыгы оештырган фарсы теле курсларына йөри, шулай итеп, Алтын Урда тарихын төрле яклап тикшерү мөмкинлегенә ирешә. Әлеге тема буенча бербер артлы фәнни хезмәтләре төрек телендә китап булып чыга: «Алтын Урда һәм Россия: татарларның Россиягә йогынтысы», «Алтын Урда ханлыгының рәсми хатлары» һ.б. Ул Ризаэтдин Фәхретдин, Арам Галстян, Үтәмеш Хаҗиләрнең китапларын төрекчәгә тәрҗемә итә, төрле фәнни җыеннарның докладларын җыеп бастыра. Китаплары Төркиянең төрле күргәзмәләрендә тәкъдим ителә.

«Алтын Урда һәм Россия: татарларның Россиягә йогынтысы» әсәре «Гыйлем тарату» фонды тарафыннан гуманитар фәннәр категориясендә «Мәгърифәт таратучы китап» дигән исемгә лаек була һәм бу премия Төркия илбашы Рәҗәп Тайип Эрдоган катнашындагы тантанада тапшырыла. Төркия президенты тарафыннан атаклы Долмабакча сараеның тарихи, зиннәтле залы сәхнәсеннән тәбрик ителгән беренче татар ул. Эрдоган милләттәшебезне котлаганда: «Бик ераклардан килгәнсең, әмма күркәм эшләр башкаргансың. Шулай дәвам ит. Синең кебек галимнәр безгә бик кирәк», — ди.

Ильяс Камалов - бүген Төркиядә Алтын Урда тарихы буенча төп белгечләрнең берсе. 43 яшьлек галим – 50 гә якын китап авторы.

Шунысы кызык: Ильяс Алтын Урда белгече булып танылган көннәрдә бөтенләй башка тема буенча язылган китабы барча Төркияне шаулата. Аның Россия президенты турындагы «Путин Россиясе: КГБдан – президентлыкка» дигән әсәре зур кызыксыну уята. Китап турында телевидение каналларында хәбәрләр чыга, сәяси тапшыруларда аннан өзекләр китерелә, иң абруйлы газета-журналлар да бу китап хакында яза, радиотапшыруларда да әлеге әсәр яктыртыла. Китап бөтен сәүдә нокталарына чыгарыла һәм сатылып бетә.

Ильясның Путин сәясәтенә кагылышлы икенче китабы да дан казана. 27 яшьлек татар егете зур танылуга ирешә, аңа тарихчы буларак кына түгел, халыкара мөнәсәбәтләр белгече итеп карыйлар. И.Камаловны Путин сәясәте һәм Россия белгече буларак төрле телетапшыруларда еш күрергә мөмкин. Төрек интеллектуаллары: «Путин дигәч, Ильяс Камалов, Ильяс Камалов дигәч, Путин искә төшә», – дип шаярта. Аның әлеге китаплары хәзер халыкара мөнәсәбәтләр бүлегендә дәреслек буларак укытыла.

Ильяс 1978 елда Халисә һәм Хәтҗәт Камалов гаиләсендә җиденче бала булып дөньяга килә. Урта мәктәпне тәмамлагач, Төркиягә укырга китә. Истанбулда Мәрмәрә университетының тарих бүлеген тәмамлый, Төрки дөнья тикшеренүләре институтында магистратурада укый, Мигъмар Синан исемендәге университетта докторантура программасын тәгәлләп, фәннәр кандидаты була. Берара Төркия тарих институтында эшләп ала, аннары Мигъмар Синан университетына күчә. Бүген ул Мәрмәрә дәүләт югары уку йортында укыта, шулай ук Йедитәпә университетында да дәресләр бирә.

- Ильяс, профессор дәрәҗәсенә ирешүеңә 3 ел булды. 2003 елдан бирле фән белән шөгыльләнү дәверендә синең чын мәгънәсендә галим иткән нинди хезмәтләр яздың?

– Мин Алтын Урда дәүләте һәм татар ханлыклары буенча эшлим. «Алтын Урда – Илханлы (Ирандагы монголлар) арасындагы мөнәсәбәтләр», «Алтын Урда – Россия мөнәсәбәтләре», «Татарларның Россиягә тәэсире» кебек фәнни китапларым бар, алар Төркиядә Алтын Урда тарихын яктыртуга зур өлеш кертте. Кайбер әсәрләрем русчага тәрҗемә ителеп, Казандагы тарих институты тарафыннан басылып чыкты. Санап үтелгән хезмәтләрем Россия һәм Европа илләрендә тарихи чыганак буларак күрсәтелә. Төрек тарихы корылышы (тарих институты) 2011 елда «Алтын Урда һәм Россия» исемле китабымны мактаулы бүләккә лаек күрде. Минем өчен бу бик әһәмиятле, чөнки әлеге институтка Йосыф Акчура, Садри Максуди кебек татар галимнәре нигез салган. 2019 елда исә шул ук китабым «Мәгърифәт таратучы китап» премиясенә лаек күрелде, бүләкне Төркия президенты Эрдоган үзе тапшырды. Бу әсәрләрдән тыш күпсанлы тәрҗемә эшләрем, редакторы булган хезмәтләр һәм башка әсәрләрем дә бар.

– Сембер якларыннан ничек Төркиягә килеп чыгарга булдың?

– Мин Ульяновск өлкәсе Мәләкәс районы Филипповка авылында туып-үстем. Мәктәпне тәмамлагач, Ульяновск педагогика институтының әзерлек бүлегендә укый башладым. Шул вакытта Казанга да барып-кайтып йөрдем. Бер баруымда Төркия Мәгариф министрлыгының Татарстан яшьләренә Төркия югары уку йортларында уку мөмкинлеге бирүе турында ишеттем. Кызыксынып, мин дә мөрәҗәгать иттем һәм Мәрмәрә университетының тарих бүлегендә укый башладым.

– Сине Төркиягә Путин турында язган китабың танытты, дисәк дөрес булыр кебек. Төрекләр моны ничек кабул итте? Россиядән да кызыксыну күрсәтелдеме?

– Инде әйтелгәнчә, мин Алтын Урда, татар тарихы кебек темалар буенча фәнни эшчәнлек алып барам. Шул ук вакытта төрки дөнья һәм Россиядәге үзгәрешләрне дә күзәтәм. Хоббидан да хәтәррәк икенче һөнәрем – халыкара мөнәсәбәтләр. Бу исә мине Төркиянең тикшеренүләр үзәгенә – Евразия стратегик тикшеренүләр мәркәзендә эшли башлавыма китерде. Анда Россия-Украина департаментында эшләдем. Әле эшкә кергәнче үк Путин турында китап яза башлаган идем, аны стратегик тикшеренүләр мәркәзендә алган мәгълүматлар белән баеттым. «Путин Россиясе: КГБдан – президентлыкка» 2005 елда басылып чыкты. Ул вакытта Путин Төркиядә билгеле түгел иде. Бөтен кеше «Путин, нинди кеше, хакимият аренасына каян калыкты» кебек сораулар бирә. Икенче яктан, ул еллар – Россия-Төркия арасында тыгыз мөнәсәбәтләр урнаша башлаган чор. Дәүләт хакимиятенә көтелмәгән юл белән килүче буларак, Путин үзем өчен дә кызыклы, аның сәясәтендә һәм тормышында игътибарга лаек моментлар күп иде.

Дөресен әйткәндә, әсәрем бу кадәр игътибар күрер, дип көтмәгән идем. Аңа, беренче булып, Төркия газеталары зур игътибар бирде, шулар танытты. Әсәр эре супермаркетларда сатуга куелды. Төркиядә ай саен 2-3 мең яңа китап чыга һәм аларның 10-20 се генә шундый супермаркетларга эләгә. Минем китап Төркиядә иң популярлар арасына керде.

Авторы мин икәнне белгәч, студентлар гаҗәпләнә, аны өлкән яшьтәге кеше язгандыр, дип уйлый идек, диделәр. Аннары Путин турында икенче китабым да дөнья күрде. «Путин чорында Россиянең тышкы сәясәте» дип аталган бу хезмәтем дә хәзер университетларда укытыла.

– Соңгы 10-15 елда Төркия төрки халыкларның тарихы, әдәбияты, сәнгатенә күбрәк кызыксыну күрсәтә башлады. Төркия дәүләтенең «ТРТ Аваз» каналының ачылуы да шуңа ишарә сыман. Син үзеңне, галим буларак, бу темаларга карата хезмәтләр язганда иркенрәк хис итмисеңме? Әллә элек яхшырак идеме?

– Әйе, соңгы елларда Төркиядә татар тарихы һәм шул исәптән төрки халыклар тарихы белән кызыксыну артты, фәнни нигездә өйрәнгән, тикшергән хезмәтләр дә күбәйде. Сәбәпләре күп. 1991 елдан соң чикләр ачылды. Россия архивларында эшләү мөмкинлекләре артты. Төркия дәүләте Россиягә студентлар җибәрә башлады. Элек белем, фән тармагында русча белүчеләр аз иде, хәзер Россиядә укып кайткан йөзләрчә белгеч бар. Бу Россия-Төркия һәм Төркиянең төрки республикалар арасындагы мөнәсәбәтләрнең үсеше белән бәйле. Төркия шулай ук төрки дөньясы белән мәдәни мөнәсәбәтләрен арттыруга да зур игътибар бирә. Әйтик, Төрки хезмәттәшлек һәм координация агентлыгы идарәсе (TİKA), чит илләрдәге төркиләр һәм тугандаш халыклар идарәсе, Юныс Әмрә институты, ТӨРКСОЙ оешмасы, «TRT Avaz» телеканалы, уртак институтлар һ.б. ике яклы мөнәсәбәтләргә зур өлеш кертә.

Тарих фәне буенча тикшеренүләр күзгә күренеп артты. Элегрәк Идел-Урал, Төркестан буенча фәнни өйрәнүләрне күбрәк Идел-Урал төбәгеннән чыккан галимнәр алып барса, бүгенге көндә Төркиядә туыпүскән төрек галимнәре дә саллы хезмәтләр яза. Фикер алыш-биреше, чыганакларга ирешү мөмкинлекләре, төрки бердәмлеккә омтылыш галимнәр алдындагы төрле киртәләрне киметә, әшебезне җиңеләйтә,

– Төрекләрнең татарларга, Татарстанга карата мөнәсәбәте турындагы фикерләрең белән уртаклашсаң иде.

– Төрекләр һәм татарлар – бер тамырдан чыккан тугандаш халыклар. Алар арасындагы мөнәсәбәтләр бик борынгы. Билгеле булганча, Алтын Урда һәм Казан ханнары Госманлы солтаннары белән язышкан, элемтәдә торган, ике арада сәүдә мөнәсәбәтләре киң җәелгән булган. Ләкин кайбер иске татар интеллектуаллары, бигрәк тә Ризаэтдин Фәхретдин, Әкъдәс Нигъмәт Курат һ.б. госманлыларны рус яуларына каршы торуда татар ханнарына булышлык күрсәтмәүдә гаепли. Бәлки, алар хаклыдыр. Ләкин XVI гасырда Госманлы империясе өчен башка мәсьәләләр алгы планда торган. Әйтик, Европа һәм Иран белән сугышлар. Әмма Госманлы дәүләте Идел-Uралдан һәм дөньяның башка җирләреннән килүчеләргә ишеген һәрвакыт ачык тоткан. XIX-XX гасырларда бик күп татар Госманлы туфрагына килеп урнашкан, татар зыялылары Төркия Республикасының үсешенә бинибһая зур өлеш керткән. Төрек тарих корылышы, Төрек тел корылышы, Төрек учагы иҗтимагый оешмасы, Анкарадагы этнография музее кебек оешмалар Төркиядәге татар зыялыларының тырышлыгы нәтиҗәсендә корылган. Шулай ук татар зыялылары тарафыннан шактый журналлар чыгарылуы, хәтта байтак фән тармагының үсешенә өлеш кертүе билгеле.

– Синең Евразия стратегик тикшеренүләр үзәге һәм Урта Көнчыгыш тикшеренүләре мәркәзе кебек институтларда эшләп алуың фәнни эшчәнлегеңә нинди йогынты ясады, әллә тарих галиме булуың андагы эшчәнлегеңә ныграк ярдәм иттеме?

– Евразия стратегик тикшеренүләр үзәгендә (ASAM)

БҮЛӘК АЛГАН ТАТАР



– биш ел, Урта Көнчыгыш тикшеренүләре үзәгендә (ORSAM) дүрт ел эшләдем. Икесе дә халыкара масштабта эш йөртүче дәрәҗәле институтлар. Иртәдән кичкә кадәр дөньядагы вакыйгаларны күзәтеп бару, бәяләү һәм аңлату күңелле эш иде. Евразия стратегик тикшеренүләр үзәгендә эшләгәндә бик күп дәүләтләрнең башлыклары килде, аларның тәрҗемәчесе булдым, карьера баскычында бу эш миңа зур тәҗрибә казандырды. Тарихчы булуым һәм рус, инглиз, фарсы, төрки диалектлар һәм славян телләре кебек төбәк телләрен белүем шулай ук әлеге институтларда эшемне җиңеләйтте, халыкара мөнәсәбәтләр белгечләреннән аермалы буларак, вакыйгаларны тарихи күзлектән бәяләргә мөмкинлек бирде.

– Төркиядә фәнгә нинди караш яши, син аннан канәгатьме?

– Төркиядә төрле фән тармаклары үсә, университетлар саны 200 дән артты. Моның уңай һәм тискәре яклары бар. Бер югары уку йортында төрле факультетлар, төрле бүлекләрнең булуы яхшы әйбер, әлбәттә. Тик медицина яки педагогика тармагын гына укыта торган университетлар юк.Бу сыйфатны төшерә. Ләкин Истанбул, Анкара һәм Измир кебек эре шәһәрләрдә бик зур һәм бик югары сыйфатлы университетлар бар. Дәүләт яшьләрне югары белем алырга өнди. Моның тискәре ягы бар: югары белемле эшсезләр саны арта.

Соңгы чорда дәүләтнең гуманитар фәннәргә игътибарын арттыруы сизелә. Шул исәптән, пилотсыз очкычлар җитештерү, хәрби технологияне үстерүдәге уңышларын да искә алырга кирәк, болар фән үсешенә керткән инвестицияләренең нәтиҗәсе. Шуны да әйтик: Төркия университетларында бик күп илләрдән меңнәрчә студент укый. Бигрәк тә Урта Азия, Кавказ, Африка илләреннән килгән яшьләргә Төркиядә уку мөмкинлеге бирелү бу илләр белән дустанә мөнәсәбәтләр урнашуга китерә. Бу – алгарыш.

– Фәнни эшчәнлегеңдә Алтын Урда тарихы әһәмиятле урын биләп тора. Төркиядә бу тема буенча ниндидер бушлык бар иде, син шул бушлыкны тутырдың сыман. Бу фикер белән килешәсеңме?

– Алтын Урда – эшчәнлегемнең иң әһәмиятле тармагы. Мин фәнгә кергән чорда ул өлкәдә зур бушлык бар иде. Бу тема буенча Мостафа Кафалы һәм Әкъдәс Нигъмәтнең хезмәтләреннән башка китаплар да юк иде. «Алтын Урда»ны фәнни хезмәтемнең темасы итеп алуымның сәбәбе дә шул: тирәнтен өйрәнелмәгән, рәтләп тикшерелмәгән бер тармак. Алдарак та әйтеп үткән хезмәтләрдән кала башка әсәрләр дә яздым. Иң беренче булып галимә Мәләк Өзйетгин белән Алтын Урда ханнары һәм әмирләренең чит илләрнең дәүләт җитәкчеләренә җибәргән ярлык һәм хатларын бастырып чыгардык. Аннары XVI гасырның мөһим чыганагы булган Үтәмеш Хаҗиның «Чыңгызнамә» әсәрен төрек теленә тәрҗемә иттем. Шулай ук Р.Фәхретдиннең «Алтын Урда һәм Казан ханнары»н да төрекчәгә тәрҗемә кылдым. Галимә Хайруннисa Алан белән ханнар турында «Чыңгыз угыллары» дигән китап бастырдык.

Моннан тыш, мин Алтын Урда тарихына кагылышлы төрле мәсьәләләр буенча дистәләгән мәкаләләр яздым. Төркиядә бу тема белән кызыксынучылар саны да артты. Тора-бара минем укучыларым да Алтын Урда темасына юнәлә башлады. Мәсәлән, хәзер бер студентым Алтын Урда дәүләтенең хәрби эшләрен өйрәнә. Үткән ел Алтын Урдага багышланган халыкара симпозиум оештырдык. Әле башкарасы эшләр күп.

Хәзерге вакытта рус елъязмаларында Алтын Урда белән бәйле мәгълүматлар буенча эшлим. Тиздән алар барысы да төрек телендә дөнья күрәчәк. Моннан тыш Госманлы чыганакларында да Алтын Урда белән бәйле бик әһәмиятле мәгълүмат күп. Аларны да дөнья әдәбиятына, фәненә казандырырга кирәк.

– «Тартарика атласы» китабын төрекчәгә тәрҗемә итеп, Ильяс Төркиягә зур хезмәт кылды, диләр. Бу китапка нинди кайтаваз килде?

– «Тартарика атласы» китабын ике ел тәрҗемә иттем. Ул Төркиядә зур резонанс тудырды. Аны таныту җыены Долмабакча сараенда оештырылды. Анда Төркиянең бик танылган тарихчылары да, Татарстаннан тарих институты мөдире дә, башка галимнәр дә катнашты.

«Тартарика» – татар тарихын төрки дөнья тарихының бер өлеше итеп күреп, төрки халыклар тарихының уртак якларын ачкан һәм аны якынча 200 карта белән баеткан күләмле әсәр. Кызганыч, Төркиядә картография үсеш алмаган. Бу җәһәттән, төрекчә белүчеләр игътибарына төрки тарихка бәйле 200 карта әзерләнгән булып чыга. «Тартарика»ның тәрҗемә ителеп төрек туфракларында танылуы – Төркиядә шундый ук тикшеренүләр үткәрү өчен үрнәк хезмәт. «Тартарика»дан илһамланып, бүген, мәсәлән, Истанбулда төрек мәдәнияте атласы әзерләнә.

– Хәзер син үзең дә яшь галимнәр әзерли торгансыңдыр, Татарстан, татар халкы тарихы белән бәйле фәнни хезмәт язучы магистрантларың, докторантларың бардыр. Аларны нинди юнәлештә әзерлисең?

– Мин университетта татар, Идел-Урал төбәге тарихы белән бәйле лекцияләр укыйм. Мәҗбүри дәресләргә дә, сайланган дәресләргә дә керәм. «Кара диңгезнең төньягындагы төрки дәүләтләр тарихы», «Урта Азия төрки тарих», «Төркестан ханлыклары» кебек дәресләр дә бирәм. 2020 елдан алып Мәрмәрә университетында эшли башладым. Элек Мигъмар Синан югары уку йортында эшләдем, анда дәресләрем күбрәк иде. «Идел-Урал тарихы», «Россия тарихы» кебек дисциплиналарга студентларның кызыксынуы зур. Бу университетларның икесендә дә рус теле дәресләре укыттым. Тел белү әлеге өлкәдә тикшеренү алып баруны җиңеләйтә. Шулай итеп, магистратура һәм докторантура студентларым үзләренең белем нигезләрен ныгыта. Байтагы Россиягә, Белоруссиягә барып, телләрен шомартып кайтты. Кайткач, алда телгә алынган темалар буенча хезмәтләрен яза башладылар. Араларында өметле яшьләр бар, алдагы елларда да алар белем дөньясын җитди фәнни эзләнүләр, фәнни әсәрләр белән баетачак, бу нисбәттән өметем зур.

– Төркиядә мәгълүмат технологияләре, политология, статистика белгечләре, экономист, физик, биоинженер, биомедик, эпидемиолог иң популяр һөнәр булып санала. Яшьләр бу өлкәдә белем бирүче факультетларга керү өчен бер-берләре белән ярыша-ярыша әзерләнә. Төрек яшьләре арасында тарих бүлегендә укырга теләүчеләр бармы?

– Яшьләр тарих белән бик кызыксына. Бигрәк тә соңгы елларда тарих белән кызыксыну нык артты. Без яшьләр гел компьютер каршында утыра, дип зарланабыз, әмма алар файдалы мәгълүматлар да электереп ала. Моның төрле факторлары бар: беренчедән, бөтен дөньядагы кебек, соңгы чорда Төркиядә дә милләтчелек артты. Элеккеге еллар белән чагыштырганда тарих белән бәйле китаплар да күбрәк басыла. Аннары Төркиядә тарих эчтәлекле сериаллар күп төшерелә башлады. Социаль медиада да, телевидение каналларында да тарих белән бәйле бик күп мәгълүмат бар. Монда тарихка кагылышлы китапларның күп басылуын кабатлап әйтергә кирәк. Алар төрки халыкларның барча тармаклары белән бәйле. Элек алай түгел иде. Бервакыт Төркиядә йә Госманлы дәүләте, йә Төркия җөмһүрияте, йә Ислам тарихы белән бәйле китапларны гына табарга мөмкин иде. Мәсәлән, мин студент чакта китап кибете киштәләре гел Госманлы тарихы турындагы китаплар белән тулы иде. Хәзер исә сәлҗүкләр тарихы бик популяр. Исламнан алдагы төрки тарихка игътибар зур. Һуннар, Төрки каһанлыгы (Күк төркиләре), уйгурлар тарихы белән кызыксынучы яшьләр күп.

– Татар тарихын беләләрме?

– Советлар Берлеге таркалуга 30 ел булды. Бу еллар эчендә Төркия шактый үзгәреш кичерде. Нәтиҗәдә Төркиядәге кешеләр төрки дөнья, бәйсез төрки җөмһүриятләр яки бәйсезлеккә ирешмәгән төрки халыклар турында да мәгълүматка иреште. Идел-Уралда, Себердә, Кавказда да төрки милләтләр яшәвеннән хәбәрдарлар. Чөнки Төркиядә төрки дөньяга кагылышлы тикшеренүләр алып барылды, фәнни хезмәтләр дөнья күрде.

Бу мәсьәләдә дә берничә фактор бар. Советлар Берлеге җимерелгәч, Россиягә барып-кайту мөмкинлеге артты, андагы архивлар ачылды. Россия университетларында тарих буенча укыган яки тикшеренүләр алып барган төрек яшьләре Төркиягә әйләнеп кайтты, мондагы югары уку йортларында укыта башлады. Шул ук вакытта, XX гасырның башындагы кебек, Россиядән, Татарстаннан килгән галимнәр дә Төркиядә татарлыкны, төрки халыкларны танытуга зур өлеш кертә.

Хәзер университетларның күбесендә бакалавр студентларына – «Идел-Урал тарихы», «Кара диңгезнең төньягындагы төрки халыклар һәм дәүләтләр тарихы», «Төрки ханлыклар», докторантларга «Алтын Урда», «Илханлылар», «Чагатайлар», «Тимурилләр» кебек дәресләр бирелә. Аларда татар тарихы теге яки бу яктан аңлатыла. Тарих бүлегендә укучы төрек яшьләре Идел буе Болгар дәүләте турында да, Алтын Урда, Казан ханлыгы, татар мәгарифе, җәдитчелек тарихы хакында киң мәгълүматка ия белгечләр булып чыга.

– Гаиләң турында кыскача сөйләп китмәссеңме?

– Хатыным Айшәгөл – минем кебек, тарихчы. Ул мөһаҗир гаиләдә туып-үскән. Бабалары Төркиягә Балкан илләреннән күченгән, балкан төрекләре диләр. Хатыным Балкан төрекләре тарихын өйрәнә. Бер улыбыз бар. Исемен Бәркәхан дип куштык. Алтын Урда дәүләтенең мөһим хөкемдарларының берсенең исеме ул. Әле дүртенче сыйныфта гына укуына карамастан тарихны да, география фәнен дә бик ярата. Чит телләр өйрәнергә хирыс. Әмма хәзерге чор төрек балалары кебек, футболчы булам, ди.

Рушания АЛТАЙ.
Төркия.

Дания ГАЙНЕТДИНОВА

Әллә?!

Завод капкасы төбендә сезне бер карчык көтә дигән хәбәрне ишетүгә, Фәрһаднең йөрәге чәнчеп алды, зиһене чуалды, күз аллары караңгыланды. Беравык шулай әсәрләнеп басып торганнан соң, тиз генә пропускын күкрәк кесәсенә салып чыгу юлына атлады ул. Кем булыр икән? Көтәр кешесе дә юк иде ич? Әллә?! Аның күңеленнән йөз төрле уй-сорау узды.

Каравылчы бүлмәсе ишек төбендә йөзгә-биткә яшен төгәл генә билгеләп булмаслык бер карчык басып торуын күргәч, үзен янә куырып алгандай тәне чымырдап алды. Карчык, Фәрһадне күрүгә, кулындагы төенчеген күкрәгенә кысты, күзләрен аска иеп:

– Нихәл, улым!.. – дип, җайсыз гына исәнләште. Фәрһад ни дип тә җавап кайтара алмый сүзсез калды. Карчык шулкадәр бетеренгән ки, йөзендәге бәрелү-сугылудан калган җөйләр аны тагын да шыксыз итә. Авыр күз кабаклары астыннан төссез күзләре тагын да тоныклана бара кебек иде...

– Әллә танымадың инде, улым?! Бу мин... Карчык сүзен дәвам итә алмады, әле тамагындагы төерне йотып җибәрә алмый азапланды, әле әйтер сүзе тиз генә табылмады. Аннан төенчеген җиргә куеп, үзе дә шунда чүгәләде.

– Мин, мин, зур гөнаһлы синең алда, улым, кичермәссең шул инде... – дип, Фәрһаднең балтырларына чытырдап ябышты.

– Торыгыз, тизрәк, кеше көлдермәгез, – диде Фәрһад.

Карчык мүкәли-мүкәли торды. Иңбашлары авыр йөк күтәргән кебек суырылып төшкән, арка бөкресе дә үткән тормышының бик үк балдан-майдан булмаганын әйтеп тора сыман. Менә алар, бер-берсен утыз елга якын күрмәгән ана белән бала, ниһаять, күзгә-күз очрашты...

Фәрһад, нидер хәтер яңартырга теләп, күтәрелеп күккә карады. Баш очында гына бер кош тавыш биреп алды. Нидер искәртә сыман иде ул. Күк йөзе зәп-зәңгәр. Ләкин аның зәңгәрлеген Фәрһад кына күрде бугай...

Карчык калтыранып, яргаланып беткән куллары белән улының кулына үрелде. Мин... мин... улым килә алмадым шул. Алдакчы булдым. Көткәнеңне дә белдем, соңардым, улым... Карчык үзалдына сөйләнә дә сөйләнә. Фәрһад аның өзек-өзек җөмләләрен ишетә дә кебек, ләкин йөрәк кабул итә алмый.

Әнисе ташлап киткәндә, аңа нибары өч яшь иде. И-и елады да елады ул. Әни, әни дип, көне-төне елады. Шулай да, берникадәр вакыттан соң килеп, «Мин сине өйгә алып кайтырмын, улым, көт, яме» дигән сүзе ничә еллар ымсындырып торды. Күз яшьләренә буыла-буыла, көннәр-төннәр, айлар-еллар елады Фәрһад. Нәфрәт-ачу сакламады, бүген булмаса иртәгә килер дип, тоташ ун ел көтте. Ун ел буе сабый күзен тәрәзәдән алмады, һай, бик күп гомер иде бит ул аның өчен!.. Әлеге уй-кичерешләре Фәрһадне еракта калган үткәннәргә алып кайтты...

Карчык та тагын ни дип сүз башларга да белмичә, дәшми генә үз уйларына бикләнде. Аның җанын, үткәннәренең барысын да сызып ташларга иде, дигән халәт биләп алды.

– Сызып ташларга иде шул вакытны, балам... Тормышны өр-яңадан, чиста биттән башларга иде дә бит... Булмады.

Үткәннәрне кайтарып булмый. Үзем гаепле, үзем... Тәкъдиремә шулай язылгандыр инде, дип мыгырданды карчык.

Фәрһад сабый чакларын кабат күз алдыннан үткәрде. Әнисе белән аерылышкан көннән башлап һәр көнне үзе генә белгән җиргә берәр вак таш куеп бара иде. Әнисеннән аерым яшәлгән көннәрен ташлар саный барды. Ә инде укый-яза башлагач, әнисенә әйтәсе сүзләрен көндәлекләргә теркәп барды ул. Аларны беркемгә дә күрсәтмәде, уйларын берәү белән дә бүлешмәде. Унөч яшен тутырасы көнне авыр төш күреп уянганы әле дә күңелен тырнап тора. Әнисе үлгән, имеш. Аның үле гәүдәсен кочаклый-кочаклый елады да елады Фәрһад. Тәрбияче апалары иртәнге ашка чакырып кергәндә дә, сулык-сулык килеп, күргән төшеннән аерыла алмыйча азаплана иде. Юынып, табын янына иртәнге ашка утыргач, бирегә тәрбияләнүче балалар алдында аны туган көне белән котладылар. Истәлеккә кул сәгате дә бүләк иттеләр әле үзенә. Аннан кайсы кая үз шөгыле белән таралышкач, Фәрһад, тәрбияче апасы янына килеп, күргән төшен сөйләде. Ун ел буе үзе генә кичергән эч серләрен бушатты. Берәмтекләп җыйган вак ташларын, көндәлекләрен иң якын кешесе итеп санаган тәрбияче апасына күрсәтеп, елап алды. Тәрбияче апасы моны күреп хәйран калды.

– Нигә миңа моңарчы сөйләмәдең боларны, – диде дә, Фәрһадне кочаклап, үзе дә аңа кушылып елады. Аннан соң Фәрһад:

– Апа, мин үз әниемне башка көтмәячәкмен, бүгеннән ары аны күңелемнән сызып атам, ул минем өчен үлде инде, – диде. – Ләкин минем дә әни дип дәшәсем килә. Миңа да әни кирәк, дип кабат елап җибәрде.

– Телисеңме, мин синең әниең булам, бездә яшәрсең, мин сине үз улым кебек яратырмын, – диде тәрбияче апасы ул чагында. Чыннан да, хәл ителәсе кәгазьләрне тутырып, эшләрне җайлагач, Фәрһад тәрбияче апасы йортына күченде. Беренче көннән үк аңа әни дип эндәште. Икесенә дә шундый рәхәт иде. Фәрһад тырышып укыды, тәртибе дә чын егетләрчә булды аның. Мәктәпне тәмамлагач, югары уку йортына керде. Менә бүген заводта инженер булып эшли. Әнисе белән шатлык-куанычларын уртаклашып, бер-берсен хөрмәт итеп яшәп яткан көннәре. Фәрһад үткәннәрне онытқан иде инде. Сабый чактагы яраларны яңартасы килми иде.

– Ник килдең син? Ник?.. Минем өчен син юк инде. Минем күңелдә син күптән үлдең, – диде Фәрһад, ачыргаланып.

– Мин исән бит, улым. Син мине исән булганым өчен битәрлисеңме, – диде карчык.

– Әйе, битәрлим!.. Син мине сабыйлыктан мәхрүм иттең. Өч яшьлек сабыеңны ташлап калдырганда, ничекләр күтәрде икән сине җир!.. Әнием, кил, мин сине көтәм бит, дип күпме яшь түктем мин. Шул вакытларда кайларда йөрдең дә, ничекләр кеше күзенә күренергә курыкмадың икән?!

Завод капкасы алдындагы эскәмиядә янәшә утырган карчык Фәрһаденең әлеге сүзләреннән соң улына күтәрелеп карый алмады. Турысын әйткәч аңлады булса кирәк. Шушы вакытта җир ярылса, шунда кереп югалыр иде дә бит, аңлашасы бар. Янәшә утырган ана белән бала арасы шулкадәр ерак булып тоелды ки, әйтерсең лә ике арада чакрымнар ята. Элегрәк, сабый чакта булсамы, муенына сарылыр иде дә килдеңме, әни, дип иркәләнер иде. Ә хәзер... ике арада бозлы тау. Аның каршысында бөтенләй башка – ят карчык.

– Син мине оныт, минем әнием бар, ул мине авыр чакларымда күкрәгенә кысып юатты, мине чын ир-ат итеп тәрбияләде. Минем өчен бары бер генә әни бар – миңа наз биргән, юаткан, авыр чакларымда киңәшчем, бүген дә таянычым булган әнием генә әни миңа. Минем өчен ул гына иң якыннарның берсе, – диде Фәрһад.

Карчык: «Син мине гафу ит, моннан соң борчымам», – дип, авыр адымнар белән китеп югалды...

МӘК тамаша заллары чакыра

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

21 гыйнвар – «Санаулы кичләр» (А.Володин).
22 гыйнвар – «Җанкисәккәем» (Т.Миңнуллин).
23 гыйнвар – «Килә ява, килә ява...» (З.Хәким).
24 гыйнвар – Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Салават Фәтхетдинов концерты.
25 гыйнвар – «Исәнме, улым!» (Б.Абдураззоков).
26 гыйнвар – «Җәйнең бер көнендә» (Й.Фоссе).
27 гыйнвар – «Гөргөри кияүләре» (Т.Миңнуллин).
28 гыйнвар – «Бабайлар чуагы» (И.Зәйниев).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

21 гыйнвар – «Галәм. Әгъләм» (М.Әгъләмов).
22 гыйнвар – «Утка очкан күбәләктәй» (Н.Гыйматдинова әсәре, Т.Хәләф инсценировкасы).
23 гыйнвар – «Өзелгән яфраклар» (Р.Габделхакова).
25 гыйнвар – «Чулпан» (Ш.Хөсәенов).
26 гыйнвар – «Карурман» (Л.Янсуар, Р.Гарипова).
27 гыйнвар – «Күрәсем килгән иде...» (И.Мәхмүтова).
28 гыйнвар – «Ядәч! Исемдә! Бер гаилә трагикомедиясе» (Й.Миңнуллина, М.Гафурова, А.Бикбулатов, Э.Дусаева).

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

21,22 гыйнвар – Премьера. «Арыну» (Т.Кулов, А.Әхмәдиев).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

21 гыйнвар – 10.00, 12.00 – «Идет коза рогатая» (М.Протасова).
18.30 – «Әлдермештән Әлмәндәр» (Т.Миңнуллин).
22 гыйнвар – зур залда – «Волк и семеро козлят» (Э.Гыйлемханова инсценировкасы). Кече залда – «И, кызык Шүрәле!» (Г.Зәйнашева).
23 гыйнвар – 10.00 – «Приключения пингвиненка Пинка» (А.Галиуллина). 11.00 – «Кәҗә белән Сарык» (Г.Тукай, Г.Рәхим). 12.00, 14.00 – «Солнышко и снежные человечки» (А.Веселов).
26 гыйнвар – «Коза и Овца» (Г.Тукай, Г.Рәхим).
27 гыйнвар – «Буре җилләге» (Р.Зәйдулла).
28 гыйнвар – «Адәмнәр» (Г.Ибраһимов).

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

21 гыйнвар – Алиса Мамина концерты.
23 гыйнвар – 15.00 – «Сказочный мир балета» дип исемләнгән театральләштерелгән тамаша. (Җитәкчесе – В.Гордеев). 19.00 – «Лебединое озеро» балеты (П.Чайковский).
26 гыйнвар – Алиса Мамина концерты.
27 гыйнвар – Татарстан дәүләт халык музыка уен кораллары оркестрына Нина Шацкая кушылып җырлый.
28 гыйнвар – Татарстан дәүләт филармония-джаз оркестры һәм Этери Бериашвили концерты.

Сез белмәгән ЗӨЛФӘТ



(Дәвамы. Башы 1 нче санда).

***

Алдарак Зөлфәт Мәскәүгә киткәнче, дигән сүз ычкындырган идем. Ә ул киткәнче безгә партҗыелышта җәза бирергә тиешләр иде. Зур җәза. Максат шул – Зөлфәт белән Мөдәррисне сытарга, алардан нәҗес ясарга, беркайчан үз халкына хезмәт итә алмас хәлгә китерергә.

Ул заманда Мәскәүдә ике ел укып кайту зур эш санала иде. Әнә шул фирка җыелышында Мирсәй ага Әмир бер әйбәт сүз ычкындырды.

– Без – Ленин юлыннан барабыз, дибез, ә бу егетләр безнең ялган юлдан киткәнне сизә. Аларның канәгатьсезлеге шуннан килми микән?

Халык телсез калды.

Әнә шул «телсезлек»не бик җайлы гына «өшкереп»: «Әйдә, егетләр шигырь укысын әле», –диде. Зөлфәт аякка басты:

Тел ачылгач әйтә алсаң:
«Әни!» – дип,
Тел ачылгач әйтә алсаң:
«Әти!» – дип,
Күзләреңә яшьләр тыгылмас,
Туган телең әле бу булмас.
Соң минутта әйтә алсаң:
«Әни!» – дип,
Соң минутта әйтә алсаң:
«Әти!» – дип, –
Күзләреңә яшьләр тыгылыр,
Туган телең әнә шул булыр...

Җыелыш бөтенләй көтелмәгән эздән кереп китте. Сәгатьтән артык шигырь кичәсе барды. Соңыннан җыелышларда бик сирәк сүз ала торган Шәйхи ага Маннур калыкты:

– Анысы дөрес, егетләрдән еш кына «байлар исе» килә. Әмма менә мине дә «таш йөрәкле Маннур» диләр. Мин булып, мин дә Зөлфәтнең «Фатыйма» балладасын укыганда еладым. Әйдә, барсын егет Мәскәүгә, укысын ике ел. Зыянга булмас. Башкалага «буш куыклар» күп очырдык, бу юлы зур шагыйрьне җибәрәбез. Күреп, өйрәнеп кайтсын.

– Культуралырак эчәргә өйрәнеп кайтыр, сукин сын! –дип аваз бирде Хәсән ага Туфан. Яратып әйтте. Бөтен зал шаулап көлде. Моңа кадәр Тукай клубында узган партия җыелышларының шигырь кичәсенә әйләнеп киткәнен иң өлкән коммунистлар да хәтерләми иде.

Кичәне Гариф абый Ахунов төгәлләде, Зөлфәткә хәерле юл теләде. Зөлфәт бу очракта да Зөлфәт булып калды:

– Гариф абый! Мәскәүгә юлыгыз төшкәндә мин фәкыйрегезнең департаментына да рәхим итегез! – диде.

Шагыйрь дустым Мәскәүдә ике ел укыды. Ул анда татар язучыларының рәсми булмаган илчесе булып яшәде. Безнекеләр – Мәскәү аша Казанга кайталармы яки киресенчәме – һәркем аңарда тукталды, аңарда кунды. Әле хәзер дә татар язучылары аның бер кешелек бүлмәсендә бөтен идән тулып йоклаганнарын сагынып сөйли.

Бу да сез белмәгән Зөлфәт.

* * *

Төгәл генә әйтә алмыйм, җиде-сигез еллар элек бугай, шагыйрьгә Татарстан комсомолының М.Җәлил исемендәге бүләген бирделәр. Дөресен генә әйткәндә, «бирергә мәҗбүр булдылар». Зөлфәтнең яшь дуслары бүләкнең язмышы кайсы көнне, кайчан хәл ителәсен белеп алган. Анда эшләүче сәркәтиб кызлар белән телефон аша бәйләнештә торалар. Менә Татарстан комсомолының өлкә комитетыннан кызлар хәбәр сала:

– Егетләр, сез анда нишләп ятасыз, Зөлфәт абыйны премиясез калдырдылар.

Хәбәр яшен тизлеге белән Матбугат йортына таралды. «Яшь ленинчы» газетасының ул вакыттагы партия оешмасы сәркәтибе Госман Садә тирәсенә җыелган яшьләр такси тотарга ташлана. Бер сәгатьтән алар шаулап-гөрләп кайтып керде.

Зөлфәт, күпме генә чакырсалар да, комсомолның бухгалтериясенә премия алырга бармады, акчасын алмады. Ә менә медален ниндидер бер җыелышта күкрәгенә тактылар.

Медаль белән дә Зөлфәтчә бер хикмәт килеп чыкты. Шул кышны «Авылдашларыңа да күрсәт инде» дигәч, ул аны тагып кайтып китте. Мул карлы кыш иде. Югалтып килде. Ишек алдыннан беркая чыкмадым, карны да көрәп карадым, табылмады, диде.

Яз җитте. Матур көннәр. Беркөнне килеп керсәм, сәламемә җавап та бирмичә, дустым шомланып миңа карап тора.

– Нәрсә булды? – дим.

– Мөҗәй (ул миңа шулай эндәшә), миндә андый-мондый нәрсә сизмисеңме?

– Юк сыман. Нәрсә булды?

– Беләсеңме, иртән уянып китсәм, шкафтагы сөлгедә Җәлил медале эленеп тора.

– Кит аннан!?

– Чын менә. Үз-үземне тотып карадым, көзгедән барып карадым. Ә медаль шул ук, минеке. Үзең беләсең, ничә ай инде хәмер дә тотып караганым юк. Әллә шуның хикмәте микән?

Шагыйрь дустым сабыйларча, күзләрен мөлдерәтеп, миңа карап тора. Еламый гына.

– Хәзер, – мин әйтәм, – очына чыгабыз аның. Тиз генә хатыны Фирая янына йөгерәм. Хатыны, үзенә генә хас ләззәт белән, кулларын чәбәкли-чәбәкли көлә. Хикмәт шунда икән, яз җиткәч, кар эрегәч, медаль ишек алдыннан килеп чыккан. Авылга кайткан энесе иртән эшкә барганда шуны кертә килгән. Зөлфәтне уятмаганнар, иртән куллана торган сөлгесенә кадап куйганнар.

Әле хәзер дә, сабыйларча, күзләрен мөлдерәтеп, шомланып торган дустымны күз алдыма китерәм дә, көлемсерәп куям.

Бу да сез белмәгән Зөлфәт.

* * *

Сез белмәгән Зөлфәт хакында сөйләсәм, үзе бер китап булыр иде. Миңа бик кадерле бер өлеш – аның гаиләсе. Инде җәмәгатен тыңлап карыйк.

ФИРАЯ:

– Мин Казан университетының тарих-филология факультетында кичке бүлектә укыдым. Ә гарәп телен татар филологиясе бүлеге студентлары белән өйрәнә идем. Яраткан укытучыбыз Лена апа Таҗиеваның дәресенә килеп кергәндә, Зөлфәт янындагы буш урын мине көтә иде инде. Группадаш кызларына: «Сезнең иң чибәр егетегез», дип, Зөлфәтне гел мактый идем. Мактамаслыкмыни: янып торган зәңгәр күзләр, бөдрә чәч, үзе гел тай кебек уйнаклап тора. Бер гарәп теле дәресеннән соң баскычтан төшеп бара идем, карасам, өстәрәк Зөлфәт басып тора. Шул вакыт дөнья ярып: «Фирая, мин сине яратам!» – дип кычкырмасынмы егетем! Сер бирмәдем тагын: «Мин дә!» – дип җавап бирдем. Бераздан ул читтән торып укый башлады. «Яшь ленинчы» газетасына әдәбият бүлегенә эшкә керде. Ә мин, хатлар исәпләүче буларак, укучылардан килгән хатларны Зөлфәткә тапшырып торам. Ул хатларны ни арада эшкәрткәндер, озакламый күтәреп тә керә. Шул бер кочак хат арасында миңа да бер мәхәббәт хаты була иде. Шулай берничә ай хат аша аңлашып йөрдек тә өйләнештек.

Аның торыр урыны юк иде. Шулай ук Мөдәррис Әгъләмовның да. Шунлыктан, аларга редакциядә кунып калырга туры килгәләде. Зөлфәт мине озата алмый, чөнки вахтадан кире үткәрмиләр, урамда кунып булмый бит. Шушы михнәтләре, «Казанны яулавы» турында чын сәнгать әсәре дә бар Зөлфәтнең. Ул «Казан» журналында 1994 елның маенда басылды.

Хәзерге заман өчен үтә дә гадел, үтә дә намуслы, үз-үзен аямыйча, кулына сөял чыкканчы язучы, әмма үзенең шәхси тормышы турында беркайчан да кайгыртмаучы шагыйрь Зөлфәт белән яшәү бик тә авыр. Шул ук вакытта, Зөлфәт ул – дөнья тоткасы кеше. Аның кулыннан килмәгән эш юк. Кирәк икән – балта остасы, кирәк икән – бакчачы, өйдәге ремонт эшләрен дә үзе башкара. Гомумән, җитмеш төрле һөнәр иясе ул. Менә шундый ышанычлы терәк барын тою минем өчен олы бәхет!

Мөдәррис ӘГЪЛӘМ.
1997 ел.

Буа районында Килдураз исемле хикмәтле авыл бар. Казан ханлыгы чорында ук билгеле булган бу авылның тарихы 500 елдан да артып китә. Янәшәсеннән Зөя елгасы ага. Иделгә капма-каршы якка агучы гаҗәп елга ул. Әллә Зөя елгасында су кереп үскәнгә, Килдураз кешеләренә аерата үҗәтлек, максатчанлык хас, диләр. Рәссам, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Шамил Нигъмәт тә шундый үҗәт, тырыш, теләсә нинди эшне булдыра торган кеше иде. Ни кызганыч, нибары 52 яшендә бакыйлыкка күчте. Аннан соң егерме ел үтсә дә, сәнгать сөючеләр һәм бигрәк тә авылдашлары рәссамны онытмаган. 4 гыйнварда, нәкъ туган көнендә, Килдуразда рәсем остасы Шамил Нигъмәтнең картиналар галереясы ачылды.

● Рәссам Шамил Нигъмәт.

ЯШЬНӘП ЯШӘГӘН

Галерея ачылу – тарихта калырлык вакыйга. Республикабызда андый музейлар бармак белән генә санарлык. Казанда Илдар Зарипов галереясы күз алдыбызда таралып ята. Константин Васильев һәм Түбән Камада Әхсән Фәтхетдинов галереялары бар һәм вәссәлам. Үз байлыгыбызны үзебез үк әрәмшәрәм итеп бетерәбез. Һәр районда күренекле рәссамнарның бер-ике галереясын ачып, аны туристик маршрутка кертсәң һәм шуның тирәсендә балалар сәнгать мәктәбе оештырсаң, матур да, файдалы да булыр иде.

Килдуразда галерея ачу матур бәйрәмгә әверелде. Галерея үзе авыл мәдәният йортының икенче катында урнашкан. Кунакларны клуб бусагасыннан ук җыр-бию белән каршы алдылар. Аннары Люция Әхмәтҗанова рәссамның иҗаты белән таныштырды. Шамил Нигъмәтнең хезмәт кешесенә дан җырлаган картиналары, бигрәк тә «Чөгендер игүчеләр»е, Сабан туена багышланган сурәте, солдатны Бөек Ватан сугышына озату мизгелен тасвирлаган картинасы күпләргә таныш, алар Татарстан рәсем сәнгатенең классикасына әверелде. Бу сурәтләрдә – тормыш дөреслеге. Авторның хезмәт кешесенә тирән ихирамы ярылып ята. Әлмәт, Лениногорск нефтьчеләре, Лаеш, Тәтеш балыкчылары, Буа чөгендер игүчеләрен сурәтләсә дә, рәссам композицияләрне оста корган. Хезмәт турында байтак картиналары күп фигуралы. Бу шулай ук рәссамнан осталык сорый. Шул ук вакытта эшчеләрнең портретлары да байтак. Галереяда хезмәт батыры портреты янында озаклап уйланып торган бер абзый игътибарны җәлеп итте. Сурәттә тасвирланган батыр Җәүдәт Гыйматов үзе икән. Картина 1984 елда иҗат ителгән. Җәүдәт ага монннан кырык ел булган хатирәләрне күңелендә яңарта булса кирәк. Бүген сурәт бар, рәссам үзе исә арабызда юк. Икәүләп, бер парта артында утырып мәктәптә сабак укыган вакытлар кичә генә булган кебек. Җәүдәт Гыйматов уңыш җыюда гына батыр түгел, бер дигән балалар үстерә. Бүген аның улы Ринат районның мәдәният идарәсен җитәкли һәм ошбу галереяны ачу өчен күп көч куйды.

Җәмәгать тормышында кайнап яшәгән рәссам Шамил Нигъмәтне әйбәт беләбез кебек иде, әмма белеп бетермәгән яклары да байтак икән. Мәсәлән, аның иҗат юлын сәхнә рәссамы буларак башлавы һәм атаклы «Зәңгәр шәл» спектакленә декорация эскизлары иҗат итүе турында кайсыбыз белә? Бу хәл болай була. Сигезенче сыйныфны тәмамлагач, рәсемгә гашыйк Шамил Казан сәнгать училищесына укырга килә. Әмма рәсем сәнгате мәктәбендә укымаган, дип егетне кире борып җибәрәләр. Икенче елга үҗәт Килдураз баласы кабат училище бусагасын таптый. Өченче елга да шул ук хәл кабатлана. Казанга дүртенче килүендә Ш.Нигъмәт университетка укырга керә һәм училищеда калган эшләрен алырга юнәлә. Горький урамыннан узганда күзе бер игъланга төшә. Ул вакытта Камал театры Горький урамында урнашкан була һәм анда сәхнә рәссамнары кирәк икән. Шамил Нигъмәт университет турында бөтенләй онытып, ике дә уйламыйча, театрга эшкә килә. Ә сәхнә рәссамы буларак бераз тәҗрибә туплагач, дүртенче тапкыр сәнгать училищесына бара һәм театр рәссамнары бүлегенә укырга керә.

Рәссам Шамил Нигъмәтнең Рәссамнар берлеге эшендә актив катнашып, кылкаләм осталарын берләштерү өчен хәттин күп эшләр башкаруыннан аның киң колачлы шәхес буларак тормышны бербөтен итеп күрә белүен чамаларга була. Күп фигуралы композицияләре дә талантының колачлылыгын раслап тора. Җыеп кына әйткәндә, Шамил Нигъмәт – бөтен холкы, таланты белән койган да куйган монументальчы рәссам. Һәм дөрестән дә, Мәскәүдә Суриков институтында театр декорациясе бүлегендә укый башлаган рәссам, озак та тормыйча, монументаль сәнгать бүлегенә күчә һәм Третьяков галереясының генераль директоры Ю.Королев җитәкчелегендә аны уңышлы тәмамлап чыга. 1980 еллар башы була бу. Ш.Нигъмәткә үз белгечлеге буенча иҗат итү бәхете бик аз элгә, чөнки берничә елдан илдә үзгәреш җилләре исеп, завод, предприятиеләрдән заказлар туктатыла, монументаль сәнгать кирәксез булып кала. Шуңа күрә Ш.Нигъмәтнең Казан авиация институтының өченче уку бинасында темпера буяу белән төшерелгән «Беренче очучылар» һәм «Профессор Одинцов мәктәбе» рәсемнәрен, Казандагы спорт сараенда, Чаллыдагы кунакханә өчен витраж эскизларын кем күрде, кем юк. Дөньялар бертөрле торса, Ш.Нигъмәтнең колачлы монументаль әсәрләре, һичшиксез, республикабыз шәһәрләренең иң матур бизәкләренә әвереләчәк иде. 1990 елларда рәссам күбесенчә картиналар иҗат итә һәм тормышны бөтенләе белән күрү сәләтен һәм колачлы талантын җәмәгать эшләрендә эшкә җигә.

● Рәссамның хатыны Рәфидә ханым уллары Бәхтияр һәм Булат белән.

Килдураз галереясының кыйммәте шунда – анда күпләребез белгән картиналар янәшәсендә рәссамның сирәкләргә генә мәгълүм булган театр эшләре һәм монументаль сәнгать әсәрләренең эскизлары урын алган. Бу җәһәттән Ш.Нигъмәтнең гаиләсенә бик зур рәхмәт белдерергә кирәк. Хатыны Рәфидә ханым, уллары Бәхтияр һәм Булат Ш.Нигъмәтнең һәр эшен кадерләп саклаган, бериш кылкаләм осталарының, үзләре үлгәннән соң, зур затлы картиналары әрәм-шәрәм булып йөргән заманда, эскизларга кадәр җыя барган. Бүген рәссамның галереясын ачабыз икән, бу гаиләсенең егерме ел буе мираска сакчыл карашын күрсәтә, чөнки галереядагы кырык иҗат әсәре дә – Нигъмәтләр гаиләсенең милке.

Рәссам Ш.Нигъмәтнең сәнгать сөючеләр белеп бетермәгән якларын Килдураз галереясы ачык күрсәтте. Әмма эш моның белән генә тукталырга тиеш түгел, рәссамның иҗатына багышлап затлы альбомнар чыгару кирәк, мондый колачлы, чын мәгънәдә милли иҗат онытылырга тиеш түгел.

Галереяда рәссамның картиналары һәм шәхси әйберләре

● «Бирнә сандыгы өстендә утырган кәләш».



● «Балыкчылар».

ШАМИЛ НИГЪМӘТ

● «Килдураз чөгендер игүчеләре».

белән танышкач, тантанага җыелган халык клубның тамаша залына күченде. Анда Буа районы хакимиятенең Башкарма комитеты җитәкчесе Ленар Шакирҗанов сәламләп, Буа районы башлыгы Ранис Камартдиновка һәм мәдәният идарәсе башлыгы Ринат Гыймрановка рәхмәтен белдерде. Казандагы Буа якташлыгы җәмгыяте рәисе Ирек Закиров, Буа дәүләт драма театрының сәнгать җитәкчесе Раил Садриев сүз тотты. Казаннан сәнгать фәннәре докторы Рауза Солтанова, пләнерлар үткәрү остасы Мөдәррис Минһаҗев җитәкчелегендә Буа районында туган, укыган, үскән бер төркем рәссамнарның кайтуы ямь өстенә ямь булды. Россия Рәссамнар берлегенең Татарстан бүлегендә яңа гына рәис итеп сайланган Анатолий Крылов та бирелә иде. Рәссамнар барысы да Ш.Нигъмәтнең берлек идарәсендә катнашкан кеше буларак эшләгән эшләрен, рәис урынбасары булып торган елларда кылган хезмәтләрен зур итеп сөйләде. Шундый талантлы, абруйлы, милли җанлы шәхесләребез аз булуына уфтанды. Кылкаләм осталарының бишкә-алтыга бүленеп дошманлашып яшәүләреннән үзләре үк туйганы күренеп тора. Тел төпләрендә берләшү, ярдәмләшү теләге шәйләнә. Галерея ачу яңа елның беренче чараларыннан иде. Ш.Нигъмәт галереясы рәссамнарны үзенә җыеп, берләшү турында уйландырган кебек, якын киләчәктә биш-алты рәссамнар берлеге дә бергә кушылып куймасмы әле...

Килдуразда галерея ачу Илшат Хәлиуллин һәм Рәшит Фәсхетдинов чыгарган «Килдураз: заман һәм кеше» китабының презентациясенә туры килде. Килдураз авылы турында өченче бу китапта тарихка һәм шәхесләргә зуррак урын бирелгән. Киләсе елга мәшһүр рәссамыбыз Бакый Урманченың 125 еллыгы уңаеннан әлегә кадәр берәүгә дә мәгълүм булмаган шигырьләрен һәм тормышына вә иҗатына багышланган китап бастырып чыгарга җыенулары турында әйтеп сөендерделәр. Аннан да куанычлысы – Урманчега багышлап Буада музей ачуны һәм һәйкәл куюны сорап Президент Р.Миңнехановка хат язулары һәм хуплау табулары. Килдураз турындагы китапны исә республикабыз китапханәләренә таратканнар, тантаналы кичәдә алдынгы мәктәп укучыларына бүләк итеп бирделәр. Тантаналы очрашу җыр-музыка белән үрелеп барды. Композитор Илһам Байтирәк туып-үскән авылда җыр-моңсыз буламыни?!

Ахырдан рәссам Ш.Нигъмәт турында кыска гына фильм да күрсәтелде. Тамашачы рәссамның һәр сүзен йотлыгып тыңлады, үзен күргәндәй, тын калып карады. Бу җәһәттән тагын рәссамның гаиләсен рәхмәт сүзләре белән искә алмыйча мөмкин түгел. Ошбу фильмны да уллары төрле елларда төшерелгән видеолардан җыеп, цифрлаштырып үзләре ясаган икән! Шамил абый безгә бай картиналар галереясын гына түгел, акыллы, инсафлы балалар калдырды. Олысы Бәхтияр – табиб, кечесе Булат – архитектор. Алар ике батыр кебек икесе ике яктан әниләре Рәфидә апага ярдәм итеп тора, яшәргә көч бирә. Мондый акыллы, инсафлы балаларга сокланмыйча мөмкин түгел.

Фильмны караганда, мәшһүр шәхесләребез турында кыска гына булса да документаль фильмнар төшерү кирәк, дигән уй тынгы бирмәде. Язучы, шагыйрь, рәссам, композитор, җырчыларыбыз турында мөмкин кадәр күбрәк төшерәсе иде. Һәркайсының да Бәхтияр һәм Булат кебек төннәрен утырып видеолардан кадрлар җыячак нәсел дәвамчылары булмаска да мөмкин...

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Буа районының матбугат хезмәте фотолары. файдаланылды.

«МАХАТМА

2024 елда большевиклар юлбашчысы вафат булганга 100 ел тула. Әмма бер гасырдан соң булса да аның мәете Мавзолейдан чыгарылып, җиргә күмелер дип әйтә алмыйбыз.

Владимир Ильич Ленин үзе, күпләрнең хатирәләре буенча, әнисе янына җирләүләрен үтенгән. Аның җәсәде Петроградның Волковское зиратында җирләнергә тиеш булган.

1922-1924 елларда юлбашчының сәламәтлеге начарайгач һәм ике тапкыр инсульт та кичергәч, аеруча 1923 елның көзендә аның бөеклеген мәңгеләштерү мәсьәләсе алгы планга чыга. Политбюро утырышында Сталин: «Ленинның тәнен җирләмәскә, ә бәлзәмләп, киләчәк буын өчен сакларга кирәк, чөнки провинцияләрдәге кайбер иптәшләр шулай тели... Бу борынгы рус гореф-гадәтләренә дә каршы килми», – дигән. Аның бу идеясенә кискен каршы чыгучылар да табылган: Бухарин, Каменев һәм аеруча Троцкий. Алар мумиягә табыну, аңа баш ию – дин культы туу белән бер, дип тәкрарлаган. Алар тиздән илне канга батырачак Сталинның идеясен «ахмаклык», «җәсәд иясен күккә чөю» дип бәяләгән. Сталин, сүзләренә колак салынмагач, бу идеягә башка әйләнеп кайтмыйча торган. Әмма 1923 елны ук юлбашчыны даһигә әйләндереп, аны иң яхшы сыйфатларга гына төреп күрсәтү башланып киткән инде. Хәтта ки Ленинизм институты да ачылган. «Правда» газетасы да Ленинга кагылышлы барча кәгазьләрне тупларга кирәк, дип өндәгән. Ленинны ул исән чакта ук изгеләштерә башлагач, аның җәсәде урыны да үзгә булырга тиеш дип уйлаучылар арткан... Башкаларның фикере кирәк тә булмаган. М.Булгаков әйтмешли: «Тиздән толерантлык шуңа барып җитәчәк, акыллыларга уйларга рөхсәт итмәячәкләр, чөнки бу наданнарның хисләрен кимсетәчәк». Ильич үлеп, икенче көн китүгә үк, профессор А.Абрикосов җитәкләгән табибләр төркеме, Ленин белән хушлашу вакыты өчен генә дип, аның тәнен вакытлыча гына бәлзәмләп тә куйган: бары да яхшы, янәсе, алты көн торырлык.

27 гыйнварда юлбашчы җәсәден агач мавзолейга урнаштырганнар. Йөзен ачык калдырып, мәетне халыкка күрсәткәннәр. Юлбашчы белән бер миллион кеше хушлашкан. Һәр өч көн саен җәсәднең торышын күзәтеп, аны күмүне 1924 елның мартына кадәр сузганнар! Көннәр җылынуга күчкәч, бәлзәм булышлык итмичә, тән таркала башлаган. Шулчак РКП(б) ҮК генераль секретаре Сталин һәм Тышкы сәүдә наркомы Л.Красин җәсәдне озак еллар буе сакларга кирәк дигән тәкъдим белән чыккан. Ахмак Л.Красин мистика белән кызыксынган һәм шулай иткәндә, кайчан да булса, мумияне җанландырып та булачак дип уйлаган. Ул табиб һәм шул ук вакытта фантаст-язучы Александр Богданов белән дуслашкан. Ә Богданов исә канны алып, яңадан күчереп агызу – кешенең сәламәтлеген яхшырта, дип сөйләнүчеләрнең берсе. Тормышны кешеләргә Аллаһы Тәгалә бүләк итүенә төшенмәгән ике ахмак Ленин тәненә җан кертү киләчәктә бик тә мөмкин, дип фикерләгән. Православие дине училищесын тәмамлаган, берничә ел буе дини семинариядә белем алган Сталин Ленинның җәсәденә миллионлаган кеше табынасына шикләнмәгән. «Ленинизм» динен формалаштыру – үзе үк зур бөеклек ләбаса! Тагын махсус комиссия төзелгән, аңа шул ук Л.Красин, ҮК секретаре В.Молотов һәм Ленинның дусты В.Бонч-Бруевич кергән. Бер галим-биохимик, тагын бер патологоанатом белән берлектә Л.Красин җәсәдне бик түбән температуралы корылма эченә туңдырып куярга кирәк, дип ышандырган. Имеш, шулай итсәләр, берничә гасырдан соң Ленинны терелтеп булачак. Баштарак бу фикергә аздан гына иярмәгән Ф.Дзержинский бик тиз аңлап алган: әлеге корылма электр тогын күп ашаячак. Юк инде, электр тогы илдә болай да тотрыксыз... Шуннан соң галимнәр дә мәетне бәлзәмләү яхшырак дип тапкан. 1924 елның март ахырында төп хезмәт башланган. Мәет инде ярылган булганга күрә, башка ысул кулланылган. Табибләр Ленинның тәнен андагы бушлыкларга, сеңерләргә бәлзәм үтсен өчен егерме җирдән кискәннәр. Тәнендә барлыкка килгән үлем тапларын уксус кислоталы уколлар кадап, юкка чыгарганнар. Махсус эремә белән тотыру өчен башын тишкәннәр. Күзләрен алып, алар урынына пыяла шарлар куйганнар. Авызын пөхтә итеп теккәннәр.

1924 елның июнендә Коминтерн делегатларына һәм В.Ленинның туганнарына шушындый җәсәдне күрсәткәннәр. Надежда Крупская тын гына мышкылдап елаган, ә Ленинның ир туганы Дмитрий: «Бары да бик яхшы

килеп чыккан, Владимир нәкъ җанлы кеше кебек ята!» – дип сөенгән. Ул көннәрдә Л.Красин: «Бу урын әле баш ию, табыну буенча Мәккәне дә, Иерусалимны да узачак», – дип шапырынган. Әмма ул үзенең дә тиздән вафат булачагын күзалламаган. 1925 елда аны Атланта илләре белән сәүдә килешүләре төзү, чит ил капиталын кулланып, совет трестларын булдыру өчен Бөекбританиягә полпред вазифаларын үтәргә юллаганнар. 1926 ел көзендә Красин йөрәк өянәгеннән үлгән. Аның тәнен яндырып, көлен Мәскәү Кремле янына урнаштырганнар... Икенче бәндә, патологоанатом В.Воробьев, Ленин тәнен бәлзәмләгән, кеше тәнен консервацияләү буенча үзенчәлекле методика уйлап тапкан табиб – 1918 елны, Харьковта яшәгәндә, анда табылган мәетләрнең большевиклар үтергән кешеләр икәнен әйткән булган, хәзер исә үзен берәр мөһим эштә күрсәтеп, акланырга теләгән. 1934 елны хөкүмәт аны, Ленин мумиясен яхшы сыйфатта тотканы өчен, Ленин ордены белән бүләкләгән. Әмма өч ел узуга, ул бөерләренә операция ясаткан мәлдә үлгән. Аның тәнен утта яндырганнар. Үз органнарын Харьков медицина институтына тапшыруны васыять иткәнгә күрә, бу да үтәлгән. Көле Харьков зиратына күмелгән... Психоаналитик Арон Залкинд исә Ленинның баш миен өйрәнүдә катнашкан. Моның өчен юлбашчының баш миен дә саклап торачак махсус Баш мие институтын ачканнар. Большевиклар партиясе Ленинны идеаллаштыруны дәвам итеп, башка дәүләтләр алдында аның искиткеч даһи юлбашчы булуын расларга теләгәч, Ленинның баш мие, имеш, башка бар кешеләрнекеннән аермалы дип табылыр, дип фикерләгәннәр. Әмма бу расланмаган, Ленин үзе исән чакта ук аның баш мие инде зәгыйфьләнеп җыерылган һәм сул як өлеше кечерәйгән. 1930 еллар башында ук А.Залкиндны Психология, педология һәм психотехника институты директорлыгыннан алганнар, ул шушы институтта берничә ел рәттән бары тик гади хезмәткәр булып кына эшли алган. 1936 елда, чираттагы җыелышта сүккәннән соң, бичара галим, урамда барганда йөрәге тотып, вафат та булган.

МӘЕТКӘ ҺӨҖҮМНӘР

Ленинның мәетен данлауга юнәлдерелгән пропаганда тискәре нәтиҗәләрсез калмаган. Җирләнмәгән мәеткә карата нәфрәт белдерүчеләр совет елларында ук табылган. Мәсәлән, Бөек Ватан сугышына кадәр үк, 1934 елда, Мәскәү янындагы «Прогресс» совхозы крестьяны Митрофан Никитинның Ленинга илдә коточкыч ачлык тууы аркасында дәгъвасы булган һәм ул аннан үч алырга ният корган. Мавзолейга кергәч, наган чыгарып, юлбашчының гәүдәсенә ата башлаган. Ике тапкыр гына атарга җитешкән, ләкин тидерә алмаган. Сакчыларның аңа таба йөгерүен күргәч, өмете өзелеп, үз-үзенә аткан... Ленинга һөҗүм итү тарихы 1959 елда да дәвам иткән. Бу юлы бер бәндә Мавзолейда экскурсия барганда, чүкеч тартып чыгарган һәм саркофаг пыяласына suga башлаган. Тик чәрдәкли генә алган, аны акылдан язган дип тапканнар... Бер елдан соң Фрунзе каласында яшәүче Минибаев, Мавзолейга кергәч барьер аша сикереп чыккан да, аягы белән җәсәдне саклап торучы пыялага типкән, пыяла кисәкләре Ильичның гәүдәсенә коелган. Мавзолейны ашыгыч рәвештә ремонтка япканнар. Минибаевтан сорау алганда, ул соңгы елларда шушы хакта гына хыяллануы хакында белдергән. Шул ук вакытта янәшәдәге Сталин җәсәденә ул игътибар да итмәгән...

Киләсе елда Смирнова фамилияле бер хатын саркофагка төкергән һәм пыяланы таш белән ваткан. Аның язмышы билгеле түгел, ул елларда мондый гамәлләр өчен гадәттә психик авырулар сырхауханәсенә сала торган булганнар. Ленин гәүдәсенә чираттагы һөҗүм 1962 елда кабатланган. Бу юлы Павлов Посадта яшәүче пенсионер Лютиков саркофагка таш белән томырган. Әмма аны психик авырулар сырхауханәсенә япмаганнар. Ул моңа кадәр дә газеталарга совет властена каршы эчтәлекле язмалар җибәргән булган, ләкин аны юаш кешегә санап, тынычлыкта калдырганнар. Ә менә 1967 елның сентябрендә Литваның Каунас шәһәрендә яшәүче Крысанов Мавзолейга кергән җирдә үк үзе ясаган бомбаны шартлаткан. Үзе дә һәлак булган, берничә кешенең дә гомерен өзгән, әмма Мавзолейга зарар китермәгән. Мондый гамәлләрдән соң Мавзолей сагы куәтләндерелгән, ә Ленин җәсәден сыйфатлырак пыяла астына урнаштырганнар. Һич көтмәгән вакыйга 1973 елның 1 сентябрендә килеп чыккан. Урам тулы кеше, балалар... Гадәттә, аларның күбесен Кызыл мәйданга да алып килә һәм Ленин мавзолеен да күрсәтә торган көн... Туристлар белән тулы шау-шулы төркемгә кушылып, Мавзолейга бер ир-ат та үткән. Бәлкем, аны укытучы дип тә уйлаганнардыр. Ашыкмыйча гына саркофаг янына атлаган. Балалар булуы да, сак торуы да аны борчымаган. Бик тә тыныч булган, ләкин Ленин җәсәде янына җитүгә үк, үзе ясаган шартлаткычның чыбыкларын тоташтырган. Шартлау куәтен чамалау өчен, шуны да искә алу җитә: почет каравылы

ЛЕНИНГА»

солдатлары читкә очып барып төшкән, алар контузияләнгән, имгәнгәннәр. Мавзолей эче канга баткан, террористның гәүдәсе кисәкләргә таркалган. Җинаятьче артыннан ук барган, Әстерханнан килгән гаилә дә һәлак булган. Дүрт бала авыр җәрәхәт алган, тагын 12 мәктәп укучысы җиңел җәрәхәтләнгән. Саркофагка берни булмаган, чөнки аны моннан начаррак тәэсирләргә дә бирешмәслек, броняланган пыяла саклап торган. Бу кайгылы вакыйганы хөкүмәт халыкка җиткермәгән. Әмма хөкүмәт җитәкчеләре борын төбендә үк килеп чыккан теракт аларны уйланырга мәҗбүр иткән. Бирегә Ю.Андропов үзе дә килеп киткән. Шартлау халыкта шау-шу тудырса да, аны бит йөзләрчә кеше ишеткән, кайберәүләр яралылардан аккан канны да күргән, башкаланың иминлек саклау системасы бу юлы бик тиз гамәл кылып, һөҗүм урынын сак белән уратып алган. Бу гамәлне кылучының кем икәнен дә белә алмаганнар. Озак вакыт үткәч кенә, аның Горловка каласыннан булуы ачыкланган. Бу бәндә өч тапкыр төрмәгә кергән, үзенең дус хатын-кызын үтергән явыз булып чыккан.

САРКОФАГЛАР ҖИР ТУЛЫ

Россиядә җәсәдләре бәлзәмләнгән шәхесләр бар. Әйтик, рус хирургы, мәшһүр галим-анатом Н.Пирогов 1881 елны 71 яшендә вафат булгач, аның тәнен чиркәү әһелләренең ризалыгын алып, нибары дүрт сәгать эчендә бәлзәмләп куйганнар. Өч елдан соң янәшәдә чиркәү дә төзелгән. Әмма 1920 еллар ахырында җәсәд сакланган җиргә бурлар кереп, пыяла саркофаг капкачын җимереп, Пироговның шпагасын алган. 1927 елда галимнәр җәсәдне саклап булмаячак дигән нәтиҗәләргә килгән. 1941 елда фашистлар һөҗүме сәбәпле чигенгәндә, саркофагны җиргә күмгәннәр һәм бозганнар. Мәетнең саклану дәрәҗәсе начарланган, соңрак күп тапкырлар бәлзәмләнгән.

1925 елда революционер, хәрби эшлекле Г.Котовский 44 яшендә һәлак булгач, аның мәете дә профессор Воробьев төркеме тарафыннан бәлзәмләнә. Җәсәд җир астындагы корылмага урнаштырылган. Саркофаг кырына орденнарын, янәшәгә зиннәтле кавалерия шашкасын беркеткәннәр. Бу тантана урынына әйләнгән. Монда пионерга кабул иткәннәр, армиягә алынучылар Ватанны сакларга вәгъдә иткән. Әмма 16 елдан соң, 1941 елның августында кала фашистлар кулына, ә соңрак румын хәрбиләре кулына күчкән. Котовский җәсәден яшереп куюны оештыра алмаганнар. Румын солдатлары саркофагны ватып, җәсәдне бозганнан соң, аны җирле коммунистлар яткан траншеяга тотып атканнар. Мавзолейны юкка чыгарганнар, ә өч Хәрби Кызыл Байрак орденын һәм шашкасын урлаганнар. Икенче көнне тимер юл депосы башлыгы И.Скорубский җитәкчелегендә траншеяны яңадан казып, Котовский гәүдәсе калдыкларын бер капчыкка җыеп алганнар, 1944 елга кадәр саклаганнар. Сугыштан соң Румыния урланган әйберләрне киредән СССРга кайтарып биргән, алар Совет Армиясе музеенда саклана. Котовскийның гәүдәсен табутка салып, эретеп ябыштыралар һәм мавзолееның сакланып калган өлешенә куялар. Һәйкәл-склеп өстенә үзешчән рәссам ясаган сурәтен беркетәләр. Молдавия ССР хөкүмәте аны үз территориясенә алырга теләү белән, украиннар 1965 елны тиз арада мемориаль комплекс төзеп куя, һәйкәл урнаштыра, табут өстенә бәрхет ябa. Ә 2016 елны Подольск хакимияте Г.Котовский гәүдәсен шәһәр зиратында җирләргә кирәк дигән карарга килә...

Узган гасырда ук тәннәре бәлзәмләнгән, башка милләт, башка дәүләт лидерлары да байтак. Әйтик, Төньяк Кореядагы Кимнар династиясе вәкилләре йөз елдан артык яшәргә теләп, хәтта кан алыштырып та караган, әмма Кодрәт Иясе билгеләгән вакыттан уза алмаган. Ким Ир Сен 1994 елда, 82 яшендә вафат булгач, аның бәлзәмләнгән җәсәде мавзолейга, Кымсусан мемориалына, ягъни Кояш сараена урнаштырыла. 2011 елны улы Ким Чен Ир 70 яшендә бакыйлыкка күчә, аның мәете дә – шул сарайда. Аларга шул дәүләт хакимиятенә бил бөгеп, ачлыкта туып, ачлыкта үлүче меңнәрчә халык баш ора. Сарайга килүчеләргә аларның җәсәдләре яныннан үткәндә фотога төшерү тыела, килгән халык пышылдап кына сөйләшергә тиеш, җете кием киючеләр кертелми...

Янәшәдәге Кытайда 1977 елда, Пекинның Тяньаньмэнь мәйданында мавзолей корылды. Аның залында, бәллүр табутта КХР юлбашчысы Мао Цзэдун гәүдәсе саклана. Инкыйлаб уңышлары залы да бар, икенче катта – кинозал, анда юлбашчы хакындагы «Сагыш» фильмы күрсәтелә. 1938 елда җан тәслим кылган Мостафа Кәмал Ататөрекнең гәүдәсе Анкараның этнография музее территориясендә җирләнә. Әмма 1953 елның 10 ноябрендә аның җәсәде махсус төзелгән «Аныткабир» мавзолеена күчереп саклана... 1952 елны «Монголия Сталины», маршал Хорлогийн Чойбалсан үлеп китә. Монголиядә Сталин дәрәҗәсенә ия булган, үз халкын кырган әлеге явызның гәүдәсе бәлзәмләнеп, шулай ук мавзолейга куела, исеме биек тауга бирелә. 1956 елда Советлар Союзындагы сәяси үзгәрешләр тәэсирендә аның эшчәнлеге тәнкыйтьләнсә дә, мумиясе кала бирә, һәйкәлләрен дә җимермиләр. Бары тик 2005 елны Сухэ-Батор җәсәде белән берлектә аның мумиясен дә мавзолейдан чыгарып, буддистлар традициясе нигезендә яндыралар. Көлләрен Алтан-Улгийда, башкаладагы «Алтын бишек» зиратында күмәләр. Мавзолейны сүтәләр... 30 яшендә, салкын тидереп вафат булган Сухэ-Батор инде 1923 елда ук шушы зиратка җирләнгән була. Ләкин 1954 елда аның мәетен тагын казып чыгаралар һәм аны Сухэ-Батор мавзолеена урнаштыралар...

1969 елны Төньяк Вьетнамның беренче Президенты Хо Ши Мин вафат булгач, аның үз гәүдәсен яндырырга дип әйтеп калдырган сүзләренә колак салмыйлар. Сәясәт эшлеклесенең җәсәден бәлзәмләп, яшереп саклыйлар. АКШ бомбардировкалары барган вакыт була бу. 1976 елдан башлап аның гәүдәсе Ханой мавзолеенда, халыкка күрсәтелә. Ә менә 1979 елны үлеп киткән Ангола лидеры Антонио Агостиньо Нетоның гәүдәсе сакланган Луандадагы мавзолее халык өчен бары тик бер көнгә – 17 сентябрьдә, аның туган көнендә ачылган. Халык шул көнне аңа баш игән. 1992 елны аның гәүдәсен, гаиләсе үтенече буенча, җир куенына иңдергәннәр. Болгария җитәкчесе Г.Дмитров, «Болгария Ленины», 1949 елда Мәскәү яны территориясендә дәваланганда үлә. Аның Софиягә кайтарып бәлзәмләнгән җәсәде дә мавзолейдагы саркофагта саклана башлый. 1990 елда коммунистлар режимы бетерелгәч, аның гәүдәсе, туганнары үтенече буенча, яндырыла һәм Софиядәге үзәк зиратта, әнисе кабере янына күмелә. Мавзолее сүтелә. 1985 елны Гайана юлбашчысы Линдон Форбс Сампсон Бёрнхемның совет галимнәре тарафыннан бәлзәмләнгән мумиясен мавзолейга урнаштыру нияте барып чыкмый. АКШ моңа каршы төшә, илгә икътисади булышлык итмәү белән яный, шул сәбәпле аның гәүдәсен герметик капсулага гына урнаштыралар.

«МӘЕТ МАВЗОЛЕЙДАН ТУЙГАН»

В.Ленин культын халыкның олуг ихтирамына таянып төзегән Сталин сукыр ышанычның халык белән идарә итү өчен бер дигән сәяси инструмент булуын да, акрынлап үз культын төзергә нигез тудырачагын да бик яхшы аңлаган. Зомбига әйләндерү генераторы булып торачак мавзолей тиз арада калыккан. Әмма бер хакимият тә мәңгелек булмавына төшенгән большевиклар башкалада, ГПУ белән берлектә, халык аңын контрольдә тотуны өйрәнәчәк илле институт та ачкан. Әйе, әле телевидение дигән нәрсә халыкка бик ерак булган вакытлар бу. Д.Рокфеллер фикере соңрак туачак: «XXI гасырда йөзләрчә гражданнарны үтерү кирәк булмаячак, массалар өстеннән хакимлек итү өчен бары тик телеканаллар сатып алу һәм алар булышлыгында идарә ителгән коллар буынын тәрбияләү дә җитәчәк». Ә 1924 елны мавзолей төзүчеләрне, әлбәттә, ашыктырганнар. Бина өчен иң яхшы наратлар җәл булмаган. Архитектор А.Щусевтан 1924 елның маена яхшырак агач бина төзеткәннәр. Ә 1930 елны ул инде таштан ук корылган. Бөек Ватан сугышы елларында Ленин җәсәден махсус состав белән Себергә алып киткәннәр. Сугыш елларында Төмән авыл хуҗалыгы техникумында сакланган ул. 1945 елда гына киредән Мәскәүгә кайтарылган. Халык арасында Мавзолей белән Кремль үзара тоташкан икән дә, Сталин төннәрен Ленин саркофагына кадәр килеп куана икән, диючеләр дә очраган. Бүген мавзолей – РФ халыклары мәдәни мирасы объекты. Ленин мәетен... ваннада юалар, агарталар, костюмын алмаштыралар. Мәетне саклауга ничә дистә хезмәткәр беркетелгән һәм аны саклау өчен ничә миллион сум тотыла... Лаеклы ялдагы кешеләрнең чүплектә азык эзләүләрен күреп торган хакимият өчен бу шулкадәр мөһимме икән?!

ТИБЕТ ЫШАНЫЧЫ: КҮМЕЛЕР...

Махатма - һинд риваятьләрендә илаһи зат. Дөнья цивилизациясенең иң атаклы эшлеклесе, дигәнне аңлата. Бу нисбәттән рәссам-философ Н.Рерих эшчәнлеген да искә алу мәслихәт: 1926 елда Николай Рерих үз экспедициясен бүлеп, гаиләсе белән Россиягә әйләнеп кайта. Н.Рерих Совет республикасына, А.Луначарскийга һәм нарком Г.Чичеринга туфрак салынган сандыкчык тапшырган. Ерактан алып кайтылган туфраклы сандыкчыкка тибет һәм рус телләрендә шундый сүзләр дә язылган булган: «На могилу брата нашего Махатмы Ленина».

Билгеле ки, Һиндстанда кремация, мәетне яндыру – яхшы күренеш... Хәер, Күккә ашкан җан тәнен яндырылуын күргәч, бик өзгәләнә, диләр. Һиндстандагы мондый күмү кануны ул вакыттагы Россиядә кабул ителмәгән чак, әмма Ленинның гәүдәсен яндырырга гына кирәк, дип киңәш итүчеләр дә булмаган түгел. Хәтта аның Россиядә крематорийлар төзи башлау мөһим, дигән сүзләрен дә искә төшергәннәр. Ләкин хөкүмәт менә 100 елга якын вакыт эчендә бу, инде тәмам арган, имеш, саркофагыннан да торырга омтылган җәсәдне җирләмичә саклый. Югыйсә, Н.Рерих 1926 елның язындагы рәсми очрашуда совет хөкүмәте җитәкчеләренә Гималай акыл ияләренең мөрәҗәгатен, киңәшен дә тапшырган...

Ул чакта алда – мәҗбүри коллективизация, кара ачлык, ГУЛАГ, сугышка әзерсезлек һәм миллион корбаннар бәрабәренә киләчәк Җиңү, төзелешләр, коммунизм офыгына юнәлү, Космосны күрү, чиксез кораллану, аексызлык еллары... Ил, әйтерсең караңгылык белән дә, яктылык белән дә капланып бара. Әйе, В.Ленинга кешеләр төрле караштa. Кемдер аның дин әһелләрен атып үтерүгә һәм Себергә сөргә риза булуын, чиркәү-мәчетләрне юкка чыгарырга рөхсәт бирүен искә ала, кайберәүләр – аның Кышкы сарайны кан коймыйча яулавын... Әмма ничек кенә булмасын, Ленинны чыннан да махатма, ягъни олуг лидер дип әйтергә мөмкин. Мондый каһарманнар тик Россия җирлегендә генә туа ала. Моңа инану өчен 1910 елдагы бурлак хатын-кызларның фотосурәтенә күз төшерү дә җитә. Коллык бетерелергә тиешле заманга берничә ел кала төшерелгән сурәт өнсез калдырырлык... Гәрчә 1870-1873 елларда ук И.Репин «Иделдәге бурлаклар» картинасын яза. Танылган рәссамны бу әсәре өчен яратмыйлар. Россиянең артта калганлыгын, кешеләрне җанварга әйләндереп эксплуатацияләүне күрсәткән бит. Ә 1917 ел халыкка белем нуры китергән, миллионнарның хакыйкатькә күзен ачкан. Әмма хәзер халык янә мохтаҗлыкта, янә коллыкта...

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА
әзерләде.

Фикер

Әрнүле тормыш

Һәр Яңа елны каршылаганда, сәламәтлек, тормыш иминлек, сугыш афәтләре булмыйча, коронавирус чиренең бетүен теләсәк тә, без дигәнчә генә бармый шул. Кеше үзе барлыкка китергән явызлыклар да җитәрлек. 2014 елда Кырым Россиягә кушылганнан соң башланып киткән тынычсыз тормыш, хәзергә кадәр дәвам итеп, тагын да хәвефлерәк хәлдә яши башладык. Илнең алга китеше туктадлы, хәерчелек артты, тынычлык бетте. Шул еллардан башлап, телевизор тапшыруларында Украинага яла ягылып, аларны гаепләп торулар башланып китте. Югыйсә, ул беркемнең җирен дә, байлыгын да талап алмаган лабаса. Үз иленең бөтенлеген, иминлеген яклап көрәшү, һәр илнең изге бурычы бит ул.

Украинаны һәм кайбер элеккеге союздаш республикаларны асат кына Россиягә кушып кую турында Жириновскийның нәфрәтләнеп сөйләүләрен тыңлаганда, куркыныч булып куя. Кушылып куеп, 70 ел яшәп карадылар бит инде. Алай яшәүнең перспективасызлыгын аңлагач, илнең куып таратылганы онытылып та бетмәде бит әле. Россиягә кушып кую куркынычы булу сәбәпле, Украина белән Грузия генә түгел, Финляндия белән Швеция дә НАТОга керү теләген белдерә башладылар.

Сугыштан соңгы елларда, сугыш афәтенең нәрсә икәнен аңлаган кешеләр заманында тынычлыкка багышланган, зур хәрефләр белән язылган “Мы за мир”, “Миру – мир”, “Мир победит войну”, “Нет войне” дигән һәм башка шундый язуларны еш очратырга була иде. Хәзер андыйлар юк. Хәзер Россия үзе кайсыдыр илдә рус телен кысалар дигән сылтау белән сугыш чыгармагае дип шикләндерә башлады. Россия үзенең илендә яшәүче бер генә халыкны дәүләт төзүче дип атап, милли республикаларда яшәүче халыкларның хокукларын чикләп, балаларга мәктәпләрдә үз ана телендә укулар тыелганда, чит илләрдә рус телен кысалар дигән сылтау белән, сугышлар чыгарып йөрү, акыл белән аңлап булмаслык гамәл түгелмени?

Гади халыкка чит илләрнең җире дә, байлыгы да кирәк түгел, аңа тыныч, хәвефсез имин тормыш яшәү кирәк.

Иң көчле корал бездә дип масаеп, халыкның котын алып, ул көчле коралларны телевизорда күрсәтеп торудан, халыкның тормыш шартлары яхшырмый.

Рәфкать ИБРАҺИМОВ.

Кырык ел

● Н. Хәбибуллин (1980 ел).

Аның кебек халык җанлы җитәкчеләр хәзер инде бөтенләй дә юктыр. 1942-1952 елларда – “Кызыл арык”, 1953-1982 еллар дәвамында «Тырыш» колхозы рәисе булып эшләгән Насыйбулла ага Хәбибуллинның тууына 100 ел була.

Авылда яшьләр, район үзәгендәге зур гына җитәкчеләр дә, атаклы колхоз рәисен зурлап, Насыйбулла абзый дип дәшә иде. Ул аз сүзле, баһадир гәүдәле, җайтак таләпләрен гипнозчылар кебек күз карашы белән генә җиткерә белүче, теләсә нинди ситуациядә дә югалып калмаучы бик тәвәккәл җитәкче булды. Гадел кеше буларак, аның усаллыгы, кирәк чакта кырыс та була белүе – бер дә үпкә-сапкасыз, табигый кабул ителә иде. Авыл хуҗалыгы - көн саен төрле проблемалар хәл итеп, җиң сызганып, физик көч белән башкарыла торган тармак. Эшне оештырганда җитәкченең ачуы чыккан чаклар да күп булгандыр. Насыйбулла абзыйның соңгы чиккә җиткәндә генә әйтә торган сүзләре бар иде: «Агу эчәрсең әле, сезнең белән!» Колхозчылар мондый түбән бәягә калмаска тырыша иде, әлбәттә.

«Тырыш» колхозы игенчелектә һәм терлекчелектә күп еллар дәвамында район буенча беренчелекне кулдан ычкындырмады, республикада танылды. Аның тәҗрибәсен күрше Мөслим, Бакалы, Әлмәт һ.б. районнардан да килеп өйрәнделәр. Авыл хуҗалыгын яхшы белүе, Тәтештә агроном белгечлеге буенча техникум тәмамлавы, оста оештыру сәләте Н. Хәбибуллинга зур уңышларга ирешергә ярдәм итте. 1970 елның җәендә Сукаешның иген кырларын колхоз рәисе Насыйбулла абзый республика җитәкчесе Фикрәт Табиев белән район җитәкчесе Әнвәр Баһаветдиновларга күрсәтеп йөрде һәм, әлбәттә, хезмәтенә югары бәя сүзләре ишетте. 1971 елда СССР Югары Советы президиумы указы нигезендә 50 яшьлек колхоз рәисенең тырышлыгын Ленин ордены белән зурладылар. Хуҗалыкның алдынгы игенчесе Алмас Булатов Социалистик Хезмәт Герое исеменә лаек булды, соңрак ул партоешманы җитәкли. Дәүләтнең гади кешене данлый, кадерле торган чаклары иде бу!

Насыйбулла Хәбибуллинның хезмәт тәҗрибәсен үзенә өлге итеп алган, аның кул астында эшләгән бик күпләр район халкына игелекле хезмәт итте. Әйтик, Ык буена таба ызандаш булган туган авылым Урсайда (композитор Әнвәр Шәрәфиев, шагыйрь Илдус Гыйләҗевләр шунда туган) – Тельман исемендәге колхозда озак еллар партоешманы һәм хуҗалыкны җитәкләгән, тумышы белән дә Зур Сукаештан булган Әнис Латыйпов, таугa таба ызандаш күрше Сәпәй авылындагы «Кызыл Байрак» колхозын күп еллар буе җитәкләгән һәм бүген дә бу авыл халкы белән элемтәне өзмәүче хезмәт ветераны Ирек Әхмәтов, Азнакай май заводында байтак гомер директор булган Мөдәррис Гаязов та башта «Тырыш» колхозында баш белгечләр булып хезмәт чыныгуы үтте.

● Җәйләүдә савымчылар янында (1974 ел).

Бу исемлекне дәвам итеп, Татарстанның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре – Башкортстаннан Азнакай районына күчеп, күп авылларда җитәкче вазифалар башкарган Термус Рахманкулов, Түбән Сукаешта туып, җирләре Азнакайга терәлеп торучы Әгерҗе авылында күп еллар хуҗалык рәисе булып эшләп, лаеклы ялга чыккан Мөнир Вәлиев һ.б.ларны санарга мөмкин. Насыйбулла абзыйның авылдашы, район авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе җитәкчесе Сәгадәт Төхбәтуллин да (ул соңрак Ютазы районы башлыгы булып эшләде, хәзер дә шунда яши) өлкән җитәкченең эш алымнарын еш кузәтә һәм аның энергиясенә бәя биреп: «Ул безнең ярдәмгә мохтаҗ түгел, үзе дә булдыра!» – дия торган булган...

Ул елларны искә алып сөйләүчеләр хәзер дә күп әле. Шушы көннәрдә Зур Сукаеш авылы ветераннар советы рәисе, «Тырыш» колхозының соңгы баш хисапчысы Нәҗибә Шәйхуллова белән әңгәмә корырга насыйп булды. Ире – күрше Чалпы авылы егете инженер-механик Мисхәт Шәйхуллов белән Сарман кызы Нәҗибәне, Казан авыл хуҗалыгы институтын тәмамлаган ике яшь белгечне, Насыйбулла ага үзе сөйләшеп, колхозга чакыра. Алар 40 ел инде шушы авылда төпләнеп, бәхетле гомер кичерә.

– Насыйбулла ага беренче карашка бик кырыс кеше шикелле тоелса да, тиз арада аның гаделлек яклы булуына төшенәсең. Кешенең нинди кайгы-хәсрәте, мохтаҗлыгы барлыгын сораша белә һәм, кирәк икән, утынын-печәнен, транспорт чарасын елның теләсә кайсы вакытында бирә. Ул вакытларда еллык, бишьеллык планнар белән эшләдек бит. Өстән җиткерелгән планны үтәү – аның башыннан бер минутка да чыкмагандыр. Саннарга анализ ясау сәләте көчле иде аның, мин баш хисапчы булсам да, кайчагында каушап калам, – дип дәвам итте сүзен Нәҗибә Шәйхуллова. – Иртәнге сәгать 3тә үк аның эш көне башлана иде, җәен басу-кырларны, кышын терлекчелек фермаларын көн саен үзе карап чыга иде.

Без авылга килгәнче, район авыллары арасында беренче булып, 1963 елда ук таштан 2 катлы 400 урынлык мәдәният йорты ачыла. 1973 елның 7 ноябрендә кирпечтән төзелгән мәктәп, соңрак 16 фатирлы 2 катлы йорт һәм административ бина, медпункт файдаланугa тапшырыла. Бүген дә алар авыл үзәген бизәп, Насыйбулла агага үзе куйган һәйкәл шикелле тора. Безнең авыл җирлеге территориясенә районның иң зур терлекчелек комплексын төзеп, быел эшләтә башлаулары да сукаешлыларның Насыйбулла ага чорыннан калган җиргә, авыл хуҗалыгы мәхәббәте көчле булуны искә алып эшләнмәде микән?! Әлеге комплекс Түбән Сукаешка бик якын һәм аңа бару юлында ике тапкыр Ленин ордены белән бүләкләнгән генерал Ф. Булатов исемен мәңгеләштерү максатыннан мемориаль такта куелса, бик урынлы булыр иде.

Татарстанның атказанган сәүдә хезмәткәре, лаеклы ялга чыкканчы «Азнакайнефть» идарәсенең ОРС (эшчеләрне тәэмин итү бүлеге) җитәкчесе булып эшләгән хезмәт ветераны Илгиз Насыйбулла улы Хәбибуллин да әтисе турында якты истәлекләре белән уртаклашты.

– Әти 1921 елгы ачлык чорында, сентябрь аенда Хәбибулла һәм Сабира гаиләсендә өченче бала булып дөньяга килә. Крестьянның азмы-күпме өметләнеп үстергән ипилек ашлыгы, бәрәңгесе, авылның балыкка бай Стәрле елгасы Ыкка

буе колхоз җитәкли

● И.Хәбибуллин (сулда), Н.Шәйхуллова һәм Х.Гыйләҗев (2021 ел).

кушылган җирдә урнашкан булу аны ачлыктан, үлемнән саклап кала. Физик яктан нык, таза булып үсә ул. Авыл мәктәбендә алган башлангыч белем белән әле ныклап аякка да басып өлгермәгән колхозда эшли башлый: сабан сөрү, язгы чәчү, печән чабу – бер эштән дә калмый. 1937 елдан хуҗалыкның хисапчысы була, аннан комсомол секретаре итеп тә сайлыйлар. 1940 елда Украинага армия хезмәтенә озатыла, танк частенда хезмәт итә башлый.

1941 елның 22 июнендә башланган сугыш афәте башта Белоруссияне һәм Украинаны айкап чыга. Бөтен Европаны буйсындырырга теләгән фашистлар Германиясе зур тизлек белән безнең сугышчыларны илнең йөрәге булган Мәскәүгә таба чигендерә. Украинаның Полтава шәһәре юнәлешендә зур югалтулар белән чигенә барган безнең армия сугышчылары арасында 20 яше дә тулмаган Насыйбулла да була. Август ахыры якынлашканда Днепрның уң ярына килеп җиткәч, дошман әзәрлекләвеннән һәм чолганыштан котылу өчен елганы аркылы чыгарга туры килә. Бу операциядә бик күпләрнең гомере өзелә, елга өсте каннан кып-кызыл була. Бүрәнәләрдән әзерләнгән саллар да, эреле-ваклы көймәләр дә киңлеге берничә чакрымнан артып киткән елгада озакка чыдамый, фашистларның һава һөҗүме нәтиҗәсендә алар таркалып бетә. Ык елгасында бала чактан ук йөзәргә өйрәнгән булу Насыйбулланы бу юлы да үлемнән коткара – Днепрны үзе йөзеп чыгу аркасында исән кала ул.

1941 елның 24 октябрендә дошман гаскәрләре Мәскәүгә бару юлында Калинин (хәзерге Тверь) өлкәсе Ржев шәһәрен басып ала. Ватан сугышы тарихында иң кан коешлы бәрелешләрнең берсе булып санала ул. Декабрьдә Мәскәү янында фашистларны тар-мар итү һәм аларны Ржев юнәлешендә чигендерү сугышларында 20 яшьлек пулеметчы Насыйбулла да үлем белән күзгә-күз очраша. 1942 елның 15 февралендә каты яралана. Икенче көнне үзебезнең сугышчылар кар астында күмелеп калган үле солдатларны җыеп йөргәндә, татар егетенең сулыш алуын абайлый. Гомере бетмәгән була, аны госпитальгә озаталар. Җәйгә чаклы Мәскәү, Владимир, ерак Чита шәһәрләрендә дәвалана, кабат фронтка юллаудан файда юклыгын күреп, егетне өенә кайтарып җибәрәләр. Ржевны азат итү 1943 елның март башында гына мөмкин була һәм ил башлыгы И.В. Сталинга шул хөрмәткә 6 мартта Советлар Союзы маршалы исеме бирелә.

1942 елның июль аенда, сугыштан яраланып кайткан егетне, туган авылы Түбән Стәрлегә бер атна эчендә колхоз рәисе итеп куялар. 11 ел эшли ул анда. Сугыш елларында колхозлар бик авыр хәлдә була. Эшче көчләрне карт-коры, бала-чага һәм илнең сугыш барган көнбатыш өлкәләреннән эвакуацияләнүчеләр тәшкил итә. Атларны да фронтка җибәреп бетерәләр. Шунысы гаҗәп, исән калган атларны кайсы колхоздан алып киткән булсалар, кире шунда кайтарып куюны оештыра алганнар. Менә тәртип!

Авыр еллар булуга карамастан, фронтовик егет барысына да өлгерә. Эвакуацияләнеп вакытлыча авылга килгән украиннар белән дә уртак тел таба. Стәрле елгасын буып, су тегермәне коралар. Өстән җиткерелгән планнарны үтәп кенә калмыйлар, һәр хезмәт көненә колхозчыларга 2-2,5 кг икмәк тә өләшәләр. Ул вакыттагы Тымытык районы җитәкчеләре Насыйбулланың мөмкинлекләрен чамалап, сугыштан соң, ул җитәкләгән «Кызыл арык» колхозын күрше Югары Стәрле авылындагы «Мелиорация» колхозына (1965 елдан Мичурин исемен йөртә) кушалар да, эреләндерелгән хуҗалыкны җитәкләүне аңа тапшыралар. 1946-47 елларда тирә-як авыллардан барысы да Стәрле елгасы буендагы тегермәнгә җыела торган була. Шул кечкенә елганы буып, электр станциясе дә эшләтеп җибәрәләр, авыл өйләрендә районда беренче булып даими рәвештә электр лампалары яна башлый. Ә район үзәгенең үзендә дә учреждениеләргә 2-3 сәгатькә генә кичке якларда электр уты бирелгән була. Ирешкән уңышларны республика җитәкчеләре дә күреп ала. Алдынгы колхозны ТАССР Министрлар Советы 1,5 тонна йөк күтәрешле ГАЗ «полуторка» автомашинасы белән бүләкли. Игенчелектә ирешкән уңышлар терлекчелекне үстерергә һәм аны күптармаклы итәргә юллар ача. Балыкчылык бригадасы да тирә-якта булмаган керем китерә. Күрше Ютазы кымыз санаторие белән элемтәләр ныгый. Ютазының атларын кыш чыгарга Стәрлегә китерәләр, үзләрендә терлек азыгы җитәрлек булмый. Аның өчен бер елны рәхмәт әйтеп, 78 яшь тайны колхозга калдырып китәләр.

Әмма эш гел шома гына бармый, югарыга шикаять юллаучылар да табыла. Имеш, ул колхоз байлыгын үз белдеге белән теләсә кая тарата, Ютазыга да, Туймазыга да җибәрә, аңлашылмаган идарә итү белән шөгыльләнә. Җитәкченең колхоз байлыгын тәэү материаллары, авыл хуҗалыгы техникасы кайтартуга тотуын күрмәмешкә салыналар. Бик аз кеше генә дөреслекне аңлый: яшь рәиснең абруе район җитәкчеләрен шөбһәгә сала, алар урынына килеп утырмагае... Партиянең район һәм өлкә комитетларына чакырып шелтәләүләр дә була. Әмма Н.Хәбибуллин ясаган һәр адым колхоз өчен икәне раслана.

Урындагы партия түрәләре икенче елны үзсүзле, буйсынмас, өстәгеләр белән бәхәскә керүдән курыкмаучы Н.Хәбибуллинны таралу хәленә килгән «Тырыш» колхозына рәис итеп күчерәләр. Менә шулай 30 еллап Сукаеш авылларын (алар өчәү) күтәрә ул. Колхозлар таралгач та, авыллар бетмәслек итеп күтәрә. Дошман явын тар-мар итеп кайткан, утлар-сулар кичкән 1925 елгылар Харис Сәитов, Әхәт Хәсәншиннар, алардан яшьрәкләр Алмас Булатов, Рәфәт Газизуллин, Фоат Шәйхетдиновлар белән авыллардагы салам түбәләр, аякта юкә чабаталар чорын артта калдырып, матур тормыш төзиләр. Соңрак Әләм Миргалимов, Әлфия Ситдыйкова, Ясир Галиевләр кебек эшчән, белемле кешеләр белән колхоз тагын да ныгый. Колхоз рәисе гомер буе аларга рәхмәтле булып яши.

– Әти көчле кеше иде, әнием Тәкыя Шәрипова да төшеп калганнардан булмады, укытучы, халык мәгарифе отличнигы иде, – дип искә ала Илгиз Хәбибуллин. – Республика, район газеталарының штаттан тыш хәбәрчесе булды, хәтта язучы Мәхмүт Хәсәнов исемендәге премиясе лауреаты исемен дә яулады. 1998 елда «Сөембикә» журналы үткәргән: «Гасыр чаңы ни хакында?» дигән бәйгедә ул I урынны алды.

Хәким ГЫЙЛӘҖЕВ.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

22 гыйнвар (шимбә). ***Җөмәдел ахир аеның 19 нчы көне. 21 нче Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында,21.05 сәгатьтә калка,10.07 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 8.02 сәгать.***

Сәяхәткә чыгу, теләсә нинди эш башлау өчен айның иң кулай көне. Кеше хәлиткеч карарлар кабул итәргә сәләтле. Физик эш белән шөгыльләнү, җәяү йөрү, чыныгу файдалы. Саф һавада күбрәк булу, табигать белән хозурлану кәефне күтәрә. Умырткалыкның аскы өлеше, әвернә сөяк, аяк зәгыйфь.

Йөрәккә дәва

Калий тозларына бай булганга, бәрәңге бик файдалы. Аның согы организмнан шлакларны чыгара, матдәләр алмашын җайга сала, йөрәк мускулын ныгыта. Бәрәңге согы белән июньнән февральгә кадәр арада дәвалану хуплана, аннан соң исә бүлбеләрдә агулы соланин микъдары арта. Бүлбеләрне щетка белән яхшылап юалар, кабыгын әрчемичә, угычтан уалар, чиста марля аша согын сыгалар. Көненә 2-3 тапкыр, ашарга 20-30 минут кала, яртышар стакан эчәләр. Ашказаны согының кислоталылыгы түбән кешеләргә, диабеттан интегүчеләргә болай дәвалану тыела.

23 гыйнвар (якшәмбе). ***Җөмәдел ахир аеның 20 нче көне. 22 нче Ай тәүлеге. Ай Үлчәү йолдызлыгында,22.28 сәгатьтә калка, 10.16 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 8.06 сәгать.***

Акыл җыю, белем алу, фәннәр өйрәнү көне. Юмарт булырга, ашау-эчүдә үзеңне чикләмәскә кирәк. Күбрәк аралашкан саен, яхшы тәэсирләр дә арта бара. Кан әйләнеше системасы, буыннар, умырткалык зәгыйфь.

Помидор сихәте

Помидорда аксым, аминокислоталар, фруктоза, сахароза күп, калий, кальций, фосфор, хром, цинк, магний бар. С витамины анда әфлисун һәм лимондагы кадәр. Әлеге яшелчәдә тимер тозлары тавык итендәгедән 2 тапкырга, балыктагыдан 3 тапкырга күбрәк, шуңа ул азканлылык булганда файдалы. Помидор аппетитны яхшырта, кандагы холестерин микъдарын киметә, яман шеш барлыкка килүне кисәтә. Томат согы симергәндә һәм диабет булганда, матдәләр алмашы бозылганда, үт кудыргыч һәм бөвел кудыргыч чара буларак кулланыла. Үт куыгында таш булса, томат согына шулкадәр үк тозлы кәбестә суы кушалар да, көненә 3 тапкыр ашаганнан соң эчәләр. Эренле җәрәхәтләргә изелгән помидор сылап, өстеннән бинт белән урыйлар, көненә 2-3 тапкыр алыштыралар.

24 гыйнвар (дүшәмбе). ***Җөмәдел ахир аеның 21 нче көне. 22 нче Ай тәүлегенең дәвамы. Ай Үлчәү йолдызлыгында, 23.52 сәгатьтә калка, 10.16 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 8.09 сәгать.***

Акыл җыю, белем алу, фәннәр өйрәнү көне. Юмарт булырга, ашау-эчүдә үзеңне чикләмәскә кирәк. Күбрәк аралашкан саен, яхшы тәэсирләр дә арта бара. Кан әйләнеше системасы, буыннар, умырткалык зәгыйфь.

25 гыйнвар (сишәмбе). ***Җөмәдел ахир аеның 22 нче көне. 23 нче Ай тәүлеге. Ай Чаян йолдызлыгында,1.20 сәгатьтә калка, 10.28 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 8.13 сәгать.***

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга карап карама

25 гыйнвар (сишәмбе). ***Җомәдел ахир аеның 22 нче көне. 23 нче Ай тәүлеге. Ай Чаян йолдызлыгында,1.20 сәгатьтә калка, 10.28 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 8.13 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Тәвәккәл адымнар ясау хупланмый. Арып-талганчы эшләргә киңәш ителми. Дару үләннәре белән дәвалану уңай нәтиҗә бирә. Иҗат белән шөгыльләнү өчен яхшы вакыт.

Суган һәм сарымсак (1)

Авитаминоз һәм иммунитетка бәйле шактый проблеманы суган һәм сарымсак хәл итә ала. Томау төшкәндә, изелгән суганны марляга төреп, 10-15 минутка борынга куялар, яки 1 өлеш сарымсак согын 2 өлеш үсемлек маена кушып, борынга тамызалар. Пешкән суганны эренле шеш өстенә ябалар. Ютәлләгәндә, бронхит һәм коклюш булганда, ярты кило туралган суган белән 400 грамм шикәрне 1 литр суда 2 сәгать пешерәләр дә, суынгач 50 грамм бал өстәп болгаталар, көненә 3-4 тапкыр 2шәр аш кашыгы кабалар.

26 гыйнвар (чәршәмбе). ***Җомәдел ахир аеның 23 нче көне. 24 нче Ай тәүлеге. Ай Чаян йолдызлыгында,2.20 сәгатьтә калка, 10.39 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 8.16 сәгать.***

Артык активлык күрсәтү хупланмый. Ялгыз калып уйлану өчен уңай вакыт. Эчке тавышка колак салу файдалы. Бизләр системасы, кан тамырлары, тире, эчәклек зәгыйфь. Күзне арытмаска кирәк.

Суган һәм сарымсак (2)

Чи суган суы белән сөял бетерәләр, җәрәхәт төзәтәләр, чәч нығыталар. Суган һәм сарымсакта фитонцидлар күп, берничә минут сарымсак чәйнәгәндә, авызда бернинди бактерия дә калмый. Әмма грипп белән авырганда күп итеп сарымсак ашарга ярамый, чөнки аның актив матдәләре кан басымын күтәрә, бөерләргә авырлык китерә. Суган белән сарымсакны салкын тиюне кисәтү өчен кулланырга кирәк.

27 гыйнвар (пәнҗешәмбе). ***Җомәдел ахир аеның 24 нче көне. 25 нче Ай тәүлеге. Ай Укчы йолдызлыгында,2.52 сәгатьтә калка, 10.56 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 8.20 сәгать.***

Акыл җыю көне. Интуициягә таянырга була. Күргән төшләр рас килә. Сизү әгъзалары, баш, колак, кан тамырлары зәгыйфь. Энергияне юк-барга сарыф итәргә ярамый. Ач тору файдалы.

28 гыйнвар (җомга). ***Җөмәдел ахир аеның 25 нче көне. 26 нчы Ай тәүлеге. Ай Укчы йолдызлыгында,4.26 сәгатьтә калка, 11.22 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 8.24 сәгать.***

Һәртөрле вәсвәсәләргә бай көн. Әйләнә-тирә дөньяны кабул итү кискенләшә, тәэсирләнүчәнлек арта, чит кеше йогынтысына бирешүчәнлек көчәя. Килешүләр төзү уңышлы. Нерв системасы, аяк зәгыйфь. Балык, мүк җиләге, сөт ризыклары ашау файдалы.

Кабак пиццасы

250 г кабак, 2 йомырка, 100 г сыр, яшел петрушка кирәк. Кабакны чистартып, юка телемнәргә турыйлар. Майлы табага тезеп, капкачын каплап, сүрән утта 10 минут кыздыралар, әледән-әле болгаткалап алалар. Йомыркаларны туглыйлар, сырны уалар, петрушканы турыйлар. Кабак өстенә йомырканы агызып, сыр һәм петрушка сибәләр, табаның капкачын ябып, 5 минут пешерәләр.

Әниемнең җылы кочагы

2021 ел йөрәгемдә мәңге төзәлмәс яра, җанымда җуелмас югалту ачысы калдырды, газиз әнием бакыйлыкка күчте. Ничә яшьтә булса да, адәм баласы күңеле белән әти-әни үлеменә риза түгел икән...

Газизләрем 65 ел парлы гомер кичереп, икесе дә 91 яшьләренә җитеп дөнья куйды. Мин бик сирәк кешеләргә генә эләгә торган бәхетне татыдым: 62 яшемә кадәр алар янәшәсендә бала булып яшәдем. Кирәк тә булдым, терәк тә булдым кебек. Балалык бурычым да үтәлгәндер сыман. Тик, әнине сагындырган йокысыз төннәр уйландыра...

● Рәшидә Шәйхетдинова (1975 ел).

Әнием Шәйхетдинова (Зарипова) Рәшидә Сәләхетдин кызы 1930 елда Исәнбай авылында дөньяга килә. Күп балалы гаиләдә дүрт кыз, бер малай үсә. Башка яшьтәшләре кебек үк кечкенәдән үк тормышның ачысын да, төчесен дә татый әнием. Җиделлык мәктәпне уңышлы тәмамлап, Минзәлә көллиятендә, ул чорның иң абруйлы саналган, укытучы һөнәрен үзләштерә. Дипломлы яшь белгеч башта районыбызның Үтәгән авылында, соңрак, Исәнбайдан ерак булмаган Алга авылында башлангыч сыйныф укучыларына белем бирә, шунда ук мөдир вазифасын да башкара.

Сугыштан соңгы авыр еллар... Тик, яшьлеккә алар киртә була аламы соң?! Ул чордагы аулак өйләр, су буе уеннары, чишмә буйлары халык теленнән бүген дә төшми. Әнием дә үз мәхәббәтен таба. Данлыклы Исәнбай МТСында шофер булып Девятерня авылыннан килеп эшләүче Нургаян Шәйхетдинов белән гаилә кора. Балачакларын сугыш урлаган, бер үк кичерешләр, бер үк хисләр белән янган бу ике җан бер-берсен яратып, хөрмәт итеп яши. Зур тырышлык белән үз дөньяларын коралар. 1955 елда тормышларына ямь өстәп апам Ләлә, ике елдан соң мин туганбыз.

Әнием 1958 елдан хезмәт биографиясен Девятерня җиделлык мәктәбендә дәвам итә. Бөтен тырышлыгын куеп балалар йөрәгенә юл сала. Белем бирә, туган телгә, туган җиргә мәхәббәт тәрбияли, хезмәтне яратырга өйрәтә. Авыл халкы әйтүенчә, ул чор укытучылары балаларга искиткеч игътибарлы, кешелекле, ярдәмчел булулары белән аерылып торган. Аларга һәр берсендә 25әр бала булган сыйныфларны бергә кушкалап та, икешәр смена укытырга да туры килгән, ләкин алар бервакытта да зарланмаган, сыкранмаган. Миңа, аларның эшкә бирелгәнлеге, укучыларга ихтирамы, үз фәннәрен тирәнтен белүе, дәрес бирү осталыклары күп кенә хәзерге укытучыларга эталон хезмәтен үтәр иде кебек тоела.

Мәктәп дирекциясе, өлкән сыйныфларга татар теле һәм әдәбияты укытучысы кирәк булгач та, нәкъ менә яшь, энергияле, укыту өлкәсендә тәҗрибә туплаган Рәшидә Сәләхетдин кызына туктала. Мин инде, гомерем буе мәктәп тормышы белән яшәгән кеше буларак, әниемнең ул чактагы халәтен аңлыйм. Яңа фән буенча белемнәрне нигезле итеп бирү җиңел бирелмәгәндер, ләкин ул барлык кыенлыкларны җиңеп, озакламый мәктәптә иң абруйлы укытучыларның берсенә әверелә. Татар теле һәм әдәбияты кабинетын тиешенчә җиһазлый, дәрестән тыш балалар белән күп эшли, кичке мәктәптә укыта, җәмәгать эшләре буенча күптөрле эш башкара. Озак еллар мәктәпнең профсоюз оешмасын җитәкли.

...Әнием миңа тормышта һәрвакытта үрнәк булды, ул бервакытта да уфтануны белмәде, соңгы елларында күп тапкыр инсульт кичереп ятканда да, оча сөяген сындырып озак вакыт гипста булганда да зарлану ишетмәдем, сабыр кеше иде ул. Аның кем турындадыр начар сүз сөйләгәнен хәтерләмим. Безне дә шулай өйрәтеп, тормышка яраклы кешеләр итеп тәрбияләде. Әниемнең хезмәт юлы минем өчен маяк, өлге булды.

...Әти дә, әни дә китеп барды. Берни алмадылар. Ә безгә гомеребез буена җитәрлек сабак, үгет-нәсихәт, хәер-дога калдырып киттеләр. Без дә – балалары, кадерле кешеләребез өчен барысын да эшләдек кебек. Хәер, бу шулай булырга тиеш тә! Әти-әни турында кайгырту балаларның төп бурычы. Әнием дә риза-бәхилләгән калдырып киткәндер.

Язмам ахырында әниемә хөрмәт белән караучы авыл халкына, җитәкчеләренә, күп санлы укучыларына, авылыбызның шәфкать туташы Гөлчәчәк Мифтаховага, күршеләр Рамил, Камил Закировларга, тумышы белән Исәнбай кызы Зөлфия Фәйзуллинага, кызым Алисәмә, бабасының, әбисенең төп таянычы булган улым Булатка рәхмәтләремне җиткерәм.

Илдус ШӘЙХЕТДИНОВ,
хезмәт ветераны.
Әгерҗе районы,
Девятерня авылы.

Кроссворд



Сулдан уңга:

1. Әре чәчәкле, эченә вак орлык тулган түгәрәк тартмачык формасында җимеш бирүче үсемлек. 3. Күрми торган. 6.Зур металл савыт. 8. Йорт хайваны. 9. Тыгыз итеп тукылган калын келәм. 10. Булачак кино, концерт турында алдан ясалган белдерү. 11. Гаскәри берәмлек. 14. Алпавыт җире. 16. Тәмәкедә була торган наркотик матдә. 19. Якын иптәш. 20. Җәфа, газап. 21. Ат җигү дирбиясе. 23. Кыйммәтле йонлы кечкенә ерткыч җәнлек. 25. Билгеле бер бәягә бөтенләйгә бирү. 28. Термин. 30. Башаклы игеннәрне сукканда барлыкка килә торган калдыклар. 31. Эченә варенье, повидло салып пешерелгән озынча катламасыман татлы ризык. 32. Яктылык сызыгы. 33. Агач ләгән. 34. Җиләк-җимеш изеп, киптереп ясалган әчкелтем чәй ашамлыгы.

Өстән аска:

1. Африкадагы дәүләт. 2. Асылташларны үлчәү берәмлеге. 3. Җир сөрү коралы. 4. Японнарның милли өс киеме. 5. Әверна чәчәклеләр семьялыгыннан берьеллык үләнчел үсемлек. 6. Югары сыйфатлы корыч. 7. Җимеш бирми торган. 12. Хөкүмәт тарафыннан бирелә торган мактаулы махсус билге. 13. Киеренкелек таләп итми торган. 14.Казан баскетбол командасы. 15. Бик нык мавыгучанлык. 17.Корабта аш пешерүче. 18. Ире яисә хатыны үлеп, ялгыз калган... 22. Ике нәрсә арасындагы буш урын. 23. Мәктәп балаларының айлык әдәби-нәфис журналы. 24. Микъдар саны. 26. Үсеп утырган иген. 27. Гомуми. 28. Фикер йөртү сәләте. 29. Җылы ат абзары.

Нияз БИШБАЛТА төзеде.

ЖАВАПЛАР

Сулдан уңга:

1. Мәк 3. Сукыр 6. Бак 8. Сарык 9. Палас 10. Анонс 11. Рота 14.Утар 16. Никотин 19. Дус 20. Иза 21. Аркалык 23. Янут 25. Сату 28. Атама 30. Кибәк 31. Рулет 32. Нур 33. Лакан 34. Как.

Өстән аска:

1. Мисыр 2. Карат 3. Сука 4. Кимоно 5. Рапс 6. Булат 7. Кысыр 12. Орден 13. Ансат 14. УНИКС 15. Азарт 17. Кок 18. Тол 22. Аралык 23. “Ялкын” 24. Унбер 26. Ашлык 27. Уртак 28. Акыл 29. Аран.

Актаныш биючесе Фаяз

Актанышның сәнгать мәктәбендә хореограф, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Фаяз Әмирхан улы Әминев белән гәпләшеп утырабыз. Ул – Актанышның Яңа Җияш авылында туып-үскән, чирек гасырга якын шушы мәктәптә балаларны бию сәнгатенә өйрәткән, районның күп сәнгать коллективларын оештырып, аларны конкурслар җиңүчесе итеп тәрбияләгән шәхес.

Чәчләре чаларган, инде 65 яшенә якынлашып килүче, әмма әле дә җыйнак гәүдәле ир-ат 1970-1980 елларда Актанышның данын еракларга тараткан «Агыйдел» дәүләт ансамбленең иң оста биючеләренең берсе булган. Фаяз Әминевнең бию хәрәкәтләренең сыгылмалылыгы һәм образга керә белүе белән дә аерылып торуы турында сөйлиләр. Мәскәүдә Октябрь революциясенең 70 еллык юбилей концертында Татарстаннан чыгыш ясаган өч биюченең берсе Фаяз була. Шул ук вакытта хореограф «Агыйдел» дәүләт ансамбле тарихына биюләр куючы остасы буларак та кереп калган. Ул елларда «Сабантуй», «Уңыш бәйрәме», «Туй» хореографик композицияләре коллективның йөзек кашына әверелә. Ф.Әминев җитәкчелегендә 60-70 бала белән куелган күмәк биюләр районда үтә торган Сабан туе, Яңа ел кебек бәйрәмнәрне ямьләндерә, алдынгылар слетлары да Ф.Әминев әзерләгән сценарийлар, аның укучылары башкаруында коллектив биюләр белән ачыла. Ул эшләгән чорда район күләмендә уздырыла торган бер генә бәйрәм һәм тантана да Фаяз әфәнде һәм аның укучылары катнашыннан башка узмый. 1985 елда Актаныш сәнгать мәктәбендә хореография классы укытучысы Ләйсән Әхәтова-Шәязданова, тормышка чыгып, декрет ялына киткәндә, үз урынына «Агыйдел» дәүләт ансамбленең солисты, тирә-юньдә оста биюче булып танылган Фаяз Әминевне тәкъдим итүе дә гаҗәп түгел. Ул елларда Актаныш балалар сәнгать мәктәбендә җыр-биюдә осталыкларын чарларга теләүчеләр күп була. Аларны мәктәпкә конкурс белән генә кабул итәләр. Коридор буйлап тезелеп чиратка баскан балаларның һәрберсен, берәмләп чакырып, сәләтен тикшерәләр. Хәзерге вакытта Актаныш сәнгать мәктәбендә сольфеджио укытучысы Резеда Хаҗиеванының да олы кызы Фаяз Әминевтә укыган. «Кызымны кабул итү конкурсына алып килдем. Фаяз абый Ләйсән апа белән балаларның биюгә сәләтен тикшерә. Биючеләр нечкә билле булырга тиеш. Миңа Ләйсән апа Шәязданова, кызың тазарак, күрсәтеп тә торма, ди. Әмма Фаяз абый үзе кызымны «бака»га яткырып, шпагатка да төшереп карады, бала барысын да булдырды, алга таба аңарда биш ел биюдә укыды. Безнең Фаяз абыйга рәхмәтебез, ихтирамыбыз чиксез», - ди ул.

Фаяз әфәнде сәнгать мәктәбендә балаларга халык биюләрен дә, бал биюләрен дә, заманчаларын да өйрәтә. Хәрәкәтләрне шомартуда исә хореографның үзенең сыналган алымнары бар. Әйтик, гади генә алмаш атлап йөрү элементы. Фаяз аганың аны кыз-малайлардан үзе булдырган күнегүләр аша чарлата. Хореограф балаларның бию дәресенә йөртә торган көндәлекләрен идәнгә, зур түгәрәк ясап, тезеп куя да, балаларны, берәр метр ара калдырып бастыра, аннары биючеләргә шул дәфтәрләрне агып торган су итеп күз алдына китерергә куша. Балалар шушы «инеш»не уң аяк белән сикереп чыгарга тиеш була. Аннары 2-3 дип аякны алыштыралар да икенче яктан сул аяк белән сикереп чыгалар. Сынны төз тотуга, сыгылмалылыкка, музыкальлелеккә, адымнар атлауга һ.б. һәркайсына аерым игътибар бирелеп, таләпләр куела.

Дәрескә балаларның ап-ак оекбашлардан килүе, кызларның чәчләрен үстерүе таләп ителә. Алар аны, юешләп маңгайны ачып тарап, лакка катыралар, толымнарын җыйнап, прическалар ясап киләләр.

Күнегүләр сәгать тә 20 минут дәвам итә. Бер төркем чыгып китә, икенчесе керә. Һәркайсында 16-20 бала. Җылыту системасы дөрес эшләмиме, тәрәзәләргә парланып бозлар ката торган була. Балалар сулышыннан көзгеләр тирләп бетә, аларны тиз генә сөртәләр дә, дәрес янадан дәвам итә. Кызлар-малайлар исә күнегүләр тәмамланганда манма суга төшә. Төркем алмашынганда,тәрәзәне әз генә ачып алалар да кире ябалар. Шушы рәвешле көн саен 3-4әр төркем дәрес ала.

Актаныштa Ф.Әминевнең бик төгәл кеше булуы да телләргә кергән. Кайвакыт аккомпаниатор Сәвия Таһирова, хореограф күрмәгәндә, будильникны биш минутка алгарак күчереп куя, янәсе балаларны иртәрәк чыгарсын. Сәгатькә күрсәтеп, «Дәрес тәмамланды», – ди. Әмма Ф.Әминев шушы биш минутны сизә. «Юк әле, вакыт бар», – дип, дәресне барыбер үз вакытында тәмамлый. Кечкенә балаларны алып килүчеләр кием алыштыру бүлмәсендә көтеп утыра. «Ул елларда шулай эшләдек, хәзер генә мәктәптә заманча шартлар тудырылды», – ди Сәвия Таһирова.

Ул елларда мәктәпнең Фаяз ага Әминев җитәкчелегендәге «Бәхетле балачак» бию ансамбле аеруча зур уңышларга ирешә, рус, украин, казах, белорус, үзбәк, мордва, мари, башкорт, чуаш биюләре белән бик күп конкурсларда җиңү яулый, зона ярышында беренче урынны алып, «Созвездие»гә кадәр барып җитә. Гомумән, «Бәхетле балачак» бию ансамбле 27 ел дәвамында республиканың иң көчле коллективлары арасында көндәшлекне тота. Ул елларда ансамбль итальяннарның «Тарантелла», казахларның «Җайдаклар», испаннарның «Арагонская хота», рус халкының «Балалайка», үзбәкләрнең «Андижанская кадриль» кебек биюләр белән дә төрле бәйгеләрдә дәрәҗәле урыннар яулый. Әмма хореографның таланты аеруча татар биюләрен куйганда ачык тоемлана. Ф.Әминев куйган татар биюләре оста башкарылуы, хәрәкәтләренең матурлыгы белән хәйран итә.

Конкурсларга бик кечкенә балалар белән дә йөриләр. Кызлар-малайлар арасында беренче сыйныфта укучылары да хәтсез. Казанга, элекке тәбәнәк арткычлы автобусларга утырып, (җиде сәгатьлек юл узарга кирәк) иртәнге дүртләр тирәсендә кузгалалар. Барып җиткәч, балаларның чәчләрен тарап үрәләр. Чыгыш ясаганда «биюче нәни артистлар» алҗып беткән була, әмма хореографның өйрәткәннәре төгәл үтәлә. Казанга чыгып киткәндә әниләре кесәләренә салган акчага төрле әйбер алып ашаулары, суны күп эчүләре дә юлда йөргән балаларга җайсызлык тудыра. Аккомпаниатор белән хореограф, алар, автобуста йоклап киткәч, авып китмәсеннәр дип, кырыйларына утыра. Шушы кыенлыклар белән катнашкан «Шома бас», «Ватан», «Балачак ритмнары» республика смотр-конкурсларында, Татнефтьнең «Рухият»-фонды тарафыннан үткәрелгән «Сандугач сайрар илем» балалар һәм яшьләр иҗаты фестивалендә дә Ф.Әминев җитәкчелегендәге коллективлар гел беренче яки икенче урынны алып кайта торган була. Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленең баш балетмейстеры, Татарстанның халык артисткасы Раилә Гарипованың «Республикада Фаяз кебек халык биюләрен куя алучы хореографлар берничә генә», – дигән сүзләре Ф.Әминевкә бирелгән зур бәя.

Әлбәттә, һәр мәдәният йортының үз сәнгате осталыгын арттырасы килә. Ә Актаныштa моны Ф.Әминевтән дә яхшырак итеп башкарып чыга алырдай хореограф юк. Күп кенә оешма һәм авылларның мәдәният йортлары җитәкчеләрен дә үзешчән коллективлар белән биюләр куюын сорап нәкъ менә аңа мөрәҗәгать итә. 1986 елдан Иске Кормаш мәдәният йорты каршындагы «Чишмә» бию ансамбленә халык исеме бирелү турыдан-туры Ф.Әминевнең хезмәте нәтиҗәсе, коллектив елдан-ел матур җиңүләр белән сөендерә, район сәнгать конкурсларында алар еш кына Гран-прига ия булса, «Балкыш» республика фестивалендә дә һәр елны лауреат исемен үз кулларында тоталар. Шулай ук Сәфәр, Богады, Татар Суксуы, Зөбәер, Уразай авылы, үзәк хастаханә бию коллективлары да Фаяз әфәнде куйган «Чабата», «Яулык белән шаяру», «Кечкенә уен», «Аулак өйдә», «Килен төшкәндә» кебек фольклорга нигезләнгән биюләр белән уңышка ирешә. Шул ук вакытта талантлы хореограф ул елларда районның Пионерлар йортында бию түгәрәген алып бара, Сәфәр, Богады, Актаныш урта мәктәпләрендә, техникумда, хастаханәдә бию ансамбльләре оештыра, алар республика үзешчән сәнгать коллективлары конкурсларында, смотрларда җиңүләр яулый. Ф.Әминевнең төгәллеге балалар белән эшләү тәҗрибәсе башка укытучылар өчен дә өлге була. Мәктәптә пианино укытучысы, аккомпаниатор Лилия Мостафина бу хакта турыдан-туры әйтә. «Укучылар белән ничек эшләргә, төгәллеккә без аңардан өйрәндек», – ди. Хореографның элекке укучылары бүген дә очрашкач, аңа рәхмәтләрен әйтеп китәләр. Әйтик, Гөлнәмия Солтанова дигән ханымның ике кызы да Ф.Әминевтә бию сәнгатенә өйрәнгән. «Институтта укыганда кызларыма Фаяз биргән дәресләр бик нык ярдәм итте», – дип искә төшереп ала.

Алай гына да түгел, Ф.Әминев гаиләсендә дә акыллы ир-егет, әйбәт әти буларак кадерле. Аның төгәллеге, чисталык-пөхтәлекне яратуы, эшне җиренә җиткереп башкаруы, шул ук вакытта гайбәт сөйләмәве, сабырлыгы, тыйнаклыгы, тынгысызлыгы – уллары өчен дә үрнәк. Ул балаларын олыларны зурларга, кечеләрне кече итәргә, кешелекле, мәрхәмәтле булырга өйрәткән. Инде үзләре әти булырга өлгергән Нияз белән Илназның Фаяз әфәндегә ихтирамы зур. Фаяз әфәнде еш кына уллары, киленнәре, оныклары белән бергәләп Каратавда – Яңа Җияштә концерт куйгалый икән.

Бүген остазларының эшен укучылары дәвам итә. Алар арасында Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблендә эшләүчеләр, музыка мәктәпләрендә укытучылар хәтсез.

Сөембикә КАШАПОВА.

Иң акыллы кош

Пингвин – иң акыллы кош икән. Австралия милли университеты Тарих мәктәбе гыйльми хезмәткәре Джой МакКанн әлеге кошларны өйрәнеп китап язган. “Кыргый диңгез: Көньяк океан тарихы” дигән китапта кызыклы фактлар шактый. Мәсәлән, пингвин бик түбән температурада үрчи алучы бердәнбер кош булып тора. Алар гаилә булып яши. Бер генә йомырка сала, аны ата кош утырып чыгара. Ул, ач килеш, йомырка өстендә ике ай буе басып тора, әнкә кош исә балык ашап май тупларга еракка китеп бара. Антарктидадагы үзәккә үтәрлек җил һәм суыктан котылыр өчен, ата кошлар тыгыз төркем булып баса һәм әледән-әле урыннарын алмаша – уртада җылынганнары тышкы якка чыга, алары исә җылынырга дип эчкә керә. Йомырка өстендә утырганда, ата кош ябыга, авырлыгының яртысын югалта. Әмма еш кына мондый азаплану бушка булып чыга. Бик каты суыкта яңа туган кошларның 70 проценты һәлак була. XIX гасырда тикшеренүчеләр пингвинны иң примитив кошка санаса, хәзер ул иң акыллысы санала. XXI гасырда Антарктидага экспедициягә баручылар кешегә бик ышанучан дустанә кошларны инде тотып ашамаса да, аларга барыбер юкка чыгу куркынычы яный. Пингвиннарны яклау фонды хәбәр итүенчә, колонияләрнең берсендә быел кыш көне 18 мең бәбкә чыккан, тик алардан икесе генә исән калган, калганнары ачтан үлгән. Әлеге фаҗигагә балыкны сәнәгать масштабларында тоту һәм, климат җылынып, биредәге кош-хайваннарның азык базасы кинәт кимү китергән. Галимнәр Антарктикада диңгез тыюлыклары челтәре булдырырга өнди, алайса пингвиннар якындагы илле ел эчендә бөтенләй юкка чыгарга мөмкин.

(“Die Presse”).

Алдакчы “филантроп”

Кытайның Хэбэй провинциясендә Ли Яньсы исемле хатынны 20 елга ирегеннән мәхрүм иткәннәр. 1996 елдан бирле тимер чыгару компаниясе хуҗасы булган Ли 2006 елда үзен филантроп итеп таныткан. Берничә дистә ятим баланы опекага алып, “Мәхәббәт авылы” приютын ачкан. 2017 елда инде анда 118 ятим яшәгән. Нәкъ менә шул елны хакимияткә хатынның законсыз эшчәнлеген фаш иткән шикаятьләр ява башлаган. Полиция аның банкта 20 миллион юань һәм 20 мең доллар акчасы булуын ачыклаган. Шулай ук Land Rover һәм Mercedes Benz кебек затлы автомобильләрен тапкан. Яньсы 2011 елдан бирле хәрәмләшү һәм урлашу, ялган документлар ясау, ришвәт алу белән шөгыльләнгән икән. Аны төрмәгә утыртып кына калмаганнар, 2,7 миллион юань штраф та салганнар.

(“BBC News”).

Шпионнар арта

Бай эшкуарлар, танылган сәясәтчеләр һәм башка күренекле кешеләр йортына эшкә әләгеп, хуҗалар турында мәгълүмат туплау белән шөгыльләнүче хезмәтчеләр саны арта бара. Әлеге шәхесләрнең бизнес һәм сәясәттәге көндәшләре мондый мәгълүмат өчен зур акча түләргә әзер. Мәсәлән, атаклы миллиардер-уйлап табучы Джеймс Дайсон шундый шпион кармагына эләккән. Дайсонның тузан суырткычлар җитештерү компаниясе бер елда якынча 1 миллиард фунт табыш ала. Ул иң бай британияле санала, мөлкәте 10,5 миллиард фунт тәшкил итә. Хезмәткәрләр яллауда тәҗрибәсе гаять бай булуга карамастан, Дайсон үзенең 20 миллион фунтлык зур йортына Линетт Фландерс кебек шикле шәхесне җыештыручы итеп алган. Тора-бара ул йортның менеджерына ук әйләнгән, 100 кешелек персонал белән идарә иткән. Әмма елына 35 мең фунт хезмәт хакы хатынга аз тоелган, ул, хуҗасының ышанычын яулап, аның сөйләшүләрен язып барган һәм 5 мең электрон хатын кулга төшергән. Миллиардер хатынының медицина күрсәткечләрен язып алган, йортның эчен фотога төшергән, хуҗасының кайбер технологик эшләнмәләрен дә көндәшләренә сатарга өлгергән. Дайсон Фландерсны Лондон Югары судына биргән һәм 50 мең фунт штраф түләтүгә ирешкән.

(“Мир новостей”).

Минут саен бер китап

1990 елның гыйнварында Украинада рекорд теркәлә: 16 яшьлек Ира Иванченко минутына 163333 сүз укый, укыган бөтен нәрсәсен тулысынча үзләштерә. Тиз укырга Ира Киев Баш миен үстерү үзәгендә махсус программа буенча өйрәнә. Аңа кадәр тагын бер кыз – 16 яшьлек Евгения Алексеенко да шаккатырган була – 1989 елның сентябрендә ул минутына 416250 сүз укый, тик бу рекорд теркәлмичә кала, чөнки аңа курсларда укучы 20 кеше генә шаһит була. “Новое время” кебек зур журналны тулысынча укып чыгу өчен Женяга нибары 30-40 секунд вакыт таләп ителә, бер китапны укуга бер минут вакыт китә... Ә менә укыган китапларының эчтәлеген Женя сәгатьләр буе тәфсилләп сөйли ала.

(“Bibliotekar.ru”).

● Әнисе Мэй белән.

● Hyperloop поезды моделе.

Кем соң ул данлыклы Илон Маск?

Былтыр ноябрьдә Илон Маскның мөлкәте 288 миллиард доллардан арткан һәм ул дөньядагы иң бай кешегә әйләнгән. “Тимер кеше”, инноватор, киләчәк эшкуары, дип йөртелүче, Tesla һәм SpaceX компанияләрен оештыручы 50 яшьлек уйлап табучының исеме нигә телдән төшми соң? Ул 1971 елның 28 июнендә инженер Эррол Маск белән диетолог, модель Мэй Маск гаиләсендә Көньяк Африка Республикасының Претория шәһәрендә туган, энесе һәм сеңлесе бар. Беренче 500 долларын Илон 12 яшендә Blastar видеоуенын уйлап табып һәм сатып эшләгән, шул акчасын фармкомпания акцияләренә керткән. Аларны сатып, Канадага киткән, бераз укыгач, Пенсильвания университетына күчкән дә, физика һәм икътисад буенча бакалавр дәрәҗәсен алган. Аннары Стэнфордка кергән, тик, бер атна да укымыйча, ташлаган да, энесе Кимбал белән Zip2 Corporation компаниясен ачкан, аны шәхси компьютерлар җитештерә торган Compaq компаниясенә саткач, эшкуарның инде 22 миллион доллар акчасы тупланган. 2002 елда eBay аларның PayPal компаниясен 1,5 миллиард долларга сатып алган, шуның 180 миллион доллары Илон өлешенә тигән. 2004 елда Tesla электромобильләрен җитештерү командасына кушылган һәм аны гасырның иң яхшы автомобиле дәрәҗәсенә җиткергән. Кояш панельләре һәм аккумулятор батареяләре җитештерә торган SolarCity предприятиесе дә әлеге фирма составына керә. Маскның космик техника җитештерә торган SpaceX компаниясендә Falcon1, Falcon9, Falcon Heavy ракеталары һәм Dragon космик корабле җыелган, былтыр 30 майда тарихта беренче шәхси кораб космоска да очкан инде. 2050 елга Маск 1 миллион кешене Марска җибәрергә ниятли – моның өчен күп тапкыр кулланыла торган мең кораб җыюны планлаштыра. Хәзергә компаниянең төп кәсәбәсе исә – Җир орбитасына йөк ташу. Шунда ук Starlink иярченнәрен җибәреп, Маск планетаның теләсә кайсы ноктасында югары тизлекле интернет челтәре булдырырга ниятли. 2020 елның апрелендә орбитага 418, тагын бер елдан исә 1,3 мең иярчен җибәрелгән инде. Маск самолеттан – ике тапкыр, экспресстан өч-дүрт тапкыр тизйөрешлерәк Hyperloop вакуумлы поездын төзү, кешелеккә файда китерәчәк ясалма интеллект булдыру, җир астында машиналар өчен тоннельләр төзү белән дә шөгыльләнә. Миллиардерның Neuralink компаниясе исә паралич суккан яки акылга зәгыйфь кешеләрнең баш миенә куелачак чиплар ясый. 2020 елда Маск үзенең бөтен матди мөлкәтен саткан һәм “Минем өем булмаячак”, – дип белдергән. Өч тапкыр өйләнгән. Канада җырчысы Граймс тудырган улына X Æ A-12 дигән исем кушканнар, әбисе Мэй оныгын Икс дип йөртә.

(“РБК”).

● “Тесла” электромобильләре.

Газета өчен
Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

24 гыйнвар

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «СӨЮЛӘРЕМ СИНЕ ХАК МИНЕМ». 12+
10.00, 23.00 «КОРОЛЕВА ИГРЫ». 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
13.00 «Семь дней». 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 12+
14.45 «Аулак өй». 6+
15.15 «Акыл баттл» һәм «Сәйлән».
16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Мин». 12+
19.00, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру». 12+
22.00 «Вызов 112». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

6.00, 13.00 «Манзара». 6+
7.15, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
8.40, 23.05 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
14.00 «Ком сәгате». 12+
15.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
19.10 «Халык җырлары». Зөһрә Сәхәбиева җырлый. 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ГУРЗУФ». 12+
10.30, 21.00 «ВОЛЬНАЯ ГРАМОТА». 16+
11.30, 17.10 «ФАМИЛЬНЫЕ ЦЕННОСТИ». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «НЕВЕРОЯТНОЕ ПУТЕШЕСТВИЕ МИСТЕРА СПИВЕТА». 6+
15.00 «Это лечится». 12+
15.30 «Страшно. Интересно». 12+
16.20 «Кошечки-собачки».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00, 9.25 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор». 6+
12.15, 17.00 «Время покажет». 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
18.40 «На самом деле». 16+
19.45 «Пусть говорят». 16+
21.00 «Время».
21.30 «ИЩЕЙКА». 16+
23.35 «Познер». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым». 12+
12.40, 18.40 «60 Минут». 12+
14.55 «ТАЙНЫ ГОСПОЖИ КИРСАНОВОЙ». 12+
17.15 «Андрей Малахов. Прямой эфир». 16+
21.20 «СКЛИФОСОВСКИЙ». 16+
23.35 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.40 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Невский ковчег. Теория невозможного. Лев Гумилев.
7.35, 19.00 «Русь».
8.00 Легенды мирового кино.
8.40 «КАЖДЫЙ ВЕЧЕР В ОДИННАДЦАТЬ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «С песней по жизни. Леонид Утёсов».
12.15 «Владикавказ. Дом для Сонечки».
12.45, 22.10 «РОССИЯ МОЛОДАЯ».
14.05 Линия жизни. Станислав Попов.
15.05 Новости. Подробно. АРТ.
15.20 «Агора». с Михаилом Швыдким.
16.25 «БЕГ».
17.55 Цвет времени. Клод Моне.
18.05 Московская филармония представляет. Сергей Догадин, Юрий Симонов и АСО МГФ. Я.Сибелиус и М.Глинка.
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 «Повелитель времени. Николай Козырев».
21.30 «Сати. Нескучная классика...»
23.25 Цвет времени. Уильям Тёрнер.

«НТВ»

4.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 12+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня.
8.25, 10.25 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «НЕВСКИЙ. ТЕНЬ АРХИТЕКТОРА». 16+
23.35 «ЗОЛОТОЙ ЗАПАС». 16+

Сишәмбе

25 гыйнвар

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «СӨЮЛӘРЕМ СИНЕ ХАК МИНЕМ». 12+
10.00, 23.00 «КОРОЛЕВА ИГРЫ». 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
11.15 «Память сердца». 12+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
13.00 «Оныта алмыйм...»
13.30 «Юлчы». 6+
14.00 «Путь». 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
14.45 «Аулак өй». 6+
15.15 «Уймак» һәм «Сәйлән».
16.00 «Ватандашлар». 12+
18.00 «Казаннан - казанга». 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00 «Чёрное озеро». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
7.15, 19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
8.40, 23.05 «Җырлыйк әле!» 6+
9.40, 16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
14.00 «Ком сәгате». 12+
15.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
16.30 «Тамчы-шоу». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ГУРЗУФ». 12+
10.30, 21.00 «ВОЛЬНАЯ ГРАМОТА». 16+
11.30, 17.10 «ФАМИЛЬНЫЕ ЦЕННОСТИ». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «СЛОМАННЫЕ ЦВЕТЫ». 16+
15.00 «Клинический случай». 12+
15.30 «Погоня за вкусом». 16+
16.30 «Кошечки-собачки».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00, 9.25 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор». 6+
12.15, 17.00 «Время покажет». 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
18.40 «На самом деле». 16+
19.45 «Пусть говорят». 16+
21.00 «Время».
21.30 «ИЩЕЙКА». 16+
22.35 «Док-ток». 16+
23.30 «Вечерний Ургант». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым». 12+
12.40, 18.40 «60 Минут». 12+
14.55 «ТАЙНЫ ГОСПОЖИ КИРСАНОВОЙ». 12+
17.15 «Андрей Малахов. Прямой эфир». 16+
21.20 «СКЛИФОСОВСКИЙ». 16+
23.35 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.40 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05, 20.05 «Правила жизни».
7.35, 19.00 «Русь».
8.00 Легенды мирового кино.
8.30 «ДЫМ ОТЕЧЕСТВА».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 XX век. «Четыре встречи с Владимиром Высоцким». Встреча четвертая «Поэт, исполнитель, музыкант».
12.20 «Португалия. Замок слёз».
12.45, 22.10 «РОССИЯ МОЛОДАЯ».
14.15 «Игра в бисер» «Льюис Кэрролл. «Алиса в Стране Чудес».
15.05 Новости. Подробно. Книги.
15.20 «Передвижники. Иван Шишкин».
15.45 «Сати. Нескучная классика...»
16.25 «БЕГ».
18.05 Московская филармония представляет. Даниэле Гатти и АСО МГФ. Д. Шостакович. Симфония №5.
19.45 Главная роль.
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 Искусственный отбор.
21.25 «Белая студия».

«НТВ»

4.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 12+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня.
8.25, 10.25 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «НЕВСКИЙ. ТЕНЬ АРХИТЕКТОРА». 16+
23.35 «ЗОЛОТОЙ ЗАПАС». 16+

Чәршәмбе

26 гыйнвар

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «СӨЮЛӘРЕМ СИНЕ ХАК МИНЕМ». 12+
10.00, 23.00 «КОРОЛЕВА ИГРЫ». 16+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
13.00, 0.50 «Җырлыйк әле!» 6+
14.00 «Азбука долголетия». 6+
14.15 «Если хочешь быть здоровым...» 12+
14.45 «Аулак өй». 6+
15.15 «Шома бас» һәм «Калеб».
16.00 «Переведи!» 6+
18.00 «Халкым минем...» 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00, 0.00 «Соотечественники». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 8.40, 23.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
7.15, 19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
9.40 «Ачыктан-ачык». 12+
10.30, 20.30 «Юлчы». 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
14.00 «Ком сәгате». 12+
15.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Яшьләр тукталышы». 12+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ГУРЗУФ». 12+
10.30, 21.00 «ВОЛЬНАЯ ГРАМОТА». 16+
11.30, 17.10 «ФАМИЛЬНЫЕ ЦЕННОСТИ». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «ЭЙФОРИЯ». 16+
14.40 «Наукограды». 12+
15.10 «Эпидемия». 12+
15.40 «Зов крови». 16+
16.30 «Кошечки-собачки».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00, 9.25 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор». 6+
12.15, 17.00 «Время покажет». 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
18.40 «На самом деле». 16+
19.45 «Пусть говорят». 16+
21.00 «Время».
21.30 «ИЩЕЙКА». 16+
22.35 «Док-ток». 16+
23.30 «Вечерний Ургант». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым». 12+
12.40, 18.40 «60 Минут». 12+
14.55 «ТАЙНЫ ГОСПОЖИ КИРСАНОВОЙ». 12+
17.15 «Андрей Малахов. Прямой эфир». 16+
21.20 «СКЛИФОСОВСКИЙ». 16+
23.35 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.40 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05, 20.05 «Правила жизни».
7.35, 19.00 «Русь».
8.00 Легенды мирового кино.
8.35 «Первые в мире».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «Дай лапу, друг!»
12.00 «Глеб Котельников. Стропа жизни».
12.45 «ЗАЛИВ СЧАСТЬЯ».
14.05 Дороги старых мастеров. «Древо жизни».
14.20 Искусственный отбор.
15.05 Новости. Подробно. Кино.
15.20 «Библейский сюжет».
15.50 «Белая студия».
16.35 «БЕРЕГ ЕГО ЖИЗНИ».
17.40 Цвет времени. Ван Дейк.
17.55 Московская филармония представляет. Юрий Симонов и АСО МГФ. С. Рахманинов. Симфонические танцы.
19.45 Главная роль.
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 Абсолютный слух.
21.30 Власть факта. «Конфуцианская цивилизация».
22.10 «ДЫМ ОТЕЧЕСТВА».

«НТВ»

4.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 12+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня.
8.25, 10.25 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «НЕВСКИЙ. ТЕНЬ АРХИТЕКТОРА». 16+
23.35 «Поздняков». 16+
23.50 Концерт «Русская душа». 12+

Пәнҗешәмбе

27 гыйнвар

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 "ЯҢА ЕЛДА БЕРГӘ БУЛЫЙК». 12+
10.00, 23.00 «КОРОЛЕВА ИГРЫ». 16+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Здоровая семья: мама, папа и я». 6+
14.15 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
14.45 «Аулак өй». 6+
15.15 «Бергәләп өйрәник» һәм «Сәйлән».
16.00 «Казаннан - казанга». 12+
18.00 «Юлчы». 6+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00 «Ватандашлар». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
7.15, 19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
8.40, 23.05 «Кәмит Җәвит». 16+
9.40 «Кунак БИТ Шоу». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
14.00 «Ком сәгате». 12+
15.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Халкым минем». 12+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.30 «Калеб». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «ГУРЗУФ». 12+
10.30, 21.00 «ВОЛЬНАЯ ГРАМОТА». 16+
11.30, 17.10 «ФАМИЛЬНЫЕ ЦЕННОСТИ». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «ЧЕЛОВЕК, КОТОРЫЙ СМЕЕТСЯ». 16+
14.35 «Наукограды». 12+
15.00 «Это лечится». 12+
15.30 «Вокруг света. Места силы». 16+
16.30 «Кошечки-собачки».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
20.00 «НАУЧИ МЕНЯ ЖИТЬ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00, 9.25 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор». 6+
12.15, 17.00 «Время покажет». 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
18.40 «На самом деле». 16+
19.45 «Пусть говорят». 16+

21.00 «Время».
21.30 «ИЩЕЙКА». 16+
22.35 «Большая игра». 16+
23.30 «Вечерний Ургант». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым». 12+
12.40, 18.40 «60 Минут». 12+
14.55 «ТАЙНЫ ГОСПОЖИ КИРСАНОВОЙ». 12+
17.15 «Андрей Малахов. Прямой эфир». 16+
21.20 «СКЛИФОСОВСКИЙ». 16+
23.35 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.40 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05, 20.05 «Правила жизни».
7.35, 19.00 «Русь».
8.00 Легенды мирового кино.
8.35 «Первые в мире».
8.55, 16.30 «БЕРЕГ ЕГО ЖИЗНИ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «Столица фонтанов».
12.15 «Гость из будущего. Исайя Берлин».
12.40 Цвет времени. Клод Моне.
12.50 «ЗВЕРОБОЙ».
14.05 90 лет со дня рождения Риммы Казаковой. Линия жизни.
15.05 Новости. Подробно. Театр.
15.20 Пряничный домик. «Якутский балаган».
15.50 «2 Верник 2».
17.35 Московская филармония представляет. Борис Березовский. Сольный концерт. Л.Бетховен и А.Скрябин.
19.45 Главная роль.
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 «Блокада. Искупление».
21.30 «Энигма. Андреа Бочелли».
22.15 «Мотивы Моисея Береговского».

«НТВ»
4.50 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 12+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня.
8.25, 10.25 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «НЕВСКИЙ. ТЕНЬ АРХИТЕКТОРА». 16+
23.35 «ЧП. Расследование». 16+

Җомга

28 гыйнвар

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «ЯҢА ЕЛДА БЕРГӘ БУЛЫЙК». 12+
11.00 «Нәсыйхәт». 6+
11.30, 16.30, 21.00 «Татарлар». 12+
12.00, 23.10 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 6+
14.15 «Рыцари вечности». 12+
14.45 «Аулак өй». 6+
15.15 «Төймә» һәм «Сәйлән».
16.00 «Мин». 12+
19.00, 20.00 «Точка опоры». 16+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «КВН РТ-2022». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
7.15, 19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
8.40, 14.00, 23.05 «Ком сәгате». 12+
9.40, 16.30 «Нәсыйхәт». 6+
10.30 «Казаннан казанга». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
15.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
20.00 «Аулак өйгә дәшкән егет». Айдар Фәйзрахманов турында телеочерк. 6+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «НАУЧИ МЕНЯ ЖИТЬ». 16+
10.30, 21.00 «ВОЛЬНАЯ ГРАМОТА». 16+
11.30, 17.10 «ФАМИЛЬНЫЕ ЦЕННОСТИ». 16+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.50 «ТАЙНОЕ ОКНО». 12+
15.00 «Клинический случай». 12+
15.30 «Это реальная история». 16+
16.30 «Кошечки-собачки».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.30 «Fam TV». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00, 9.25 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор». 6+
12.15, 17.00 «Время покажет». 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
18.40 «Человек и закон». 16+
19.45 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.30 Ко дню рождения Владимира Высоцкого. «Своя колея». 16+
23.20 «Вечерний Ургант». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым». 12+
12.40, 18.40 «60 Минут». 12+
14.55 «ТАЙНЫ ГОСПОЖИ КИРСАНОВОЙ». 12+
17.15 «Андрей Малахов. Прямой эфир». 16+
21.20 «СКЛИФОСОВСКИЙ». 16+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.40 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 «Правила жизни».
7.35, 19.00 «Русь».
8.00 Легенды мирового кино.
8.35 «Первые в мире».
8.55, 16.25 «БЕРЕГ ЕГО ЖИЗНИ».
10.15 «ГАРМОНЬ».
11.10 ХХ век. «Встреча в Концертной студии «Останкино» с народным артистом РСФСР Василием Лановым».
12.30 «Казань. Дом Зинаиды Ушковой».
13.00 «ЗВЕРОБОЙ».
14.15 Власть факта. «Конфуцианская цивилизация».
15.05 Письма из провинции.
15.35 «Энигма. Андреа Бочелли».
16.15 Цвет времени. Уильям Тёрнер.
17.30 Московская филармония представляет. Борис Андрианов и Андрей Гугнин. С.Рахманинов.
18.20 «Билет в Большой».
19.45 «Смехоностальгия».
20.15 Линия жизни. Евгений Киндинов.
21.10 «СТАРОМОДНАЯ КОМЕДИЯ».
22.45 «2 Верник 2».

«НТВ»
4.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 12+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 Сегодня.
8.25, 10.25 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «ДНК». 16+
17.55 «Жди меня». 12+
20.00 «НЕВСКИЙ. ТЕНЬ АРХИТЕКТОРА». 16+
23.20 «Своя правда». 16+

Шимбә

29 гыйнвар

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
7.00 «Sиңа Миннән Sәлам». 6+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00 «Мин». 12+
11.30 «Казаннан - казанга». 12+
12.00, 0.45 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 12+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
13.30 «Когда поёт душа». 6+
14.45 Презентация книг, изданных программой «Рухият» благотворительного фонда «Татнефть» в 2021 году. 12+
16.30 «Юлчы». 6+
17.00 «Әдәби хәзинә». 6+
17.30 «Татарлар». 12+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Халкым минем...» 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Җырлыйк әле!» 6+
22.00 «КунакБиТ- шоу». 12+
23.00 «ХОЛОСТЯКИ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». Мансур Гыйләҗев турында телеочерк. 6+
7.00, 15.00 «Sиңа Миннән Sәлам». 6+
9.00 «Кәмит Җәвит». 16+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 6+
13.00 «КӨТЕГЕЗ, БЕЗ КИЛӘБЕЗ». 12+
17.10 «Казаннан казанга». 12+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 Әлфия Авзалова исемендәге II халыкара фестиваль-бәйге гала-концерты. 12+
22.40 Спектакль «Бурлак». 12+

«ЭФИР»
5.00, 0.05 «Наукограды». 12+
5.30 «Опыты дилетанта». 12+
6.00 «Мировой рынок». 12+
7.00 «Лео и Тиг».
8.00 «Непростые вещи». 12+
8.40 «ЦЕНА ПРОШЛОГО». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ВОЗДУШНЫЙ МАРШАЛ». 12+
15.00 «Все, кроме обычного». 16+
16.15 «СЕМЕЙНЫЙ БИЗНЕС». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ВОСПОМИНАНИЯ О БУДУЩЕМ». 16+
23.10 «ЧЕЛОВЕК - НЕВИДИМКА». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.00 «Умницы и умники». 12+
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00 Новости.
10.15 Ко дню рождения Владимира Высоцкого. «Письмо Уоррену Битти». 16+
11.15, 12.15 «Видели видео?» 6+
13.25 «СТРЯПУХА».
14.45 «Владимир Высоцкий. «И, улыбаясь, мне ломали крылья». 16+
16.40 «Кто хочет стать миллионером?»
18.15 «Точь-в-точь». 16+
21.00 «Время».
21.20 «Сегодня вечером». 16+
23.05 «НЕБЕСА ПОДОЖДУТ». 16+

«РОССИЯ»
5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00 Вести.
11.35 «Юмор! Юмор! Юмор!!!» 16+
12.50 «Доктор Мясников». 12+
14.00 «ПОДАРИ МНЕ ВОСКРЕСЕНЬЕ». 16+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
20.00 Вести в субботу.
21.00 «МОЙ ЛЮБИМЫЙ ДРУГ». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Библейский сюжет».
7.05 «Приключения капитана Врунгеля».
8.10 «СТАРОМОДНАЯ КОМЕДИЯ».
9.40 «Передвижники. Василий Верещагин».
10.15 «НАЧАЛЬНИК ЧУКОТКИ».
11.45 «Алексей Грибов. Великолепная простота».
12.25 «Дом ученых». Владимир Спокойный.
12.55 «Португалия. Дикая природа на краю земли».
13.50 «Эффект бабочки».
14.20 95 лет со дня рождения Михаила Калика. Острова.
15.00 «ДО СВИДАНИЯ, МАЛЬЧИКИ».
16.20 «Отцы и дети».
16.50 «Энциклопедия загадок».
17.20 «Неоконченная пьеса для механического пианино». Пропала жизнь!»
18.05 100 лет Московской государственной академической филармонии. Историческая программа торжественного открытия филармонии. Денис Мацуев, Хибла Герзмава, Сергей Романовский, Юрий Симонов, Геннадий Дмитряк.
21.05 «Зачем нам музыка играет?»
22.00 «Агора».
23.00 «БАБОЧКИ СВОБОДНЫ».

«НТВ»
4.55 «ЧП. Расследование». 16+
5.20 «ЧУЖОЙ ДЕД». 16+
7.20 Смотр.
8.00, 10.00, 16.00 Сегодня.
8.20 «Готовим с Алексеем Зиминым».
8.45 «Поедем, поедим!»
9.25 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда с Сергеем Малозёмовым». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
14.05 «Однажды...» 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «Следствие вели...» 16+
19.00 «Центральное телевидение».
20.20 «Ты не поверишь!» 16+
21.20 «Секрет на миллион». 16+
23.25 «Международная пилорама». 16+

Якшәмбе

30 гыйнвар

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «Пар алма». Илназ Баһ һәм Гүзәл Идрисова. 6+
8.00 «Адымнар». 12+
8.30 «Хайкю». 12+
9.00 «Здоровая семья: мама, папа и я». 6+
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы». 12+
10.15 «Ачыктан - ачык». 12+
11.00 «Бәхетемне килә табасым». Айдар Рәкыйпов. 6+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество». 12+
13.00 «Үзгәреш җиле-2021». 6+
16.00, 0.35 «Ком сәгате». 12+
17.00 «Видеоспорт». 12+
17.30 «Татарлар». 12+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». 12+
20.00 «Профсоюз - союз сильных». 12+
20.15 «Батырлар». 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты. 6+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
23.00 «УЧИТЕЛЬ АНГЛИЙСКОГО». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05, 12.35, 23.20 «Халкым минем». 12+
5.30, 13.35 «Нәсыйхәт». 6+
6.00, 13.00, 0.40 «Татарлар». 12+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
7.00 «Ялантауга ай кунган». Рәвилә Шәйдуллинаның китабын тәкъдим итү кичәсе. 6+
9.00 «Аулак өйгә дәшкән егет». Айдар Фәйзрахманов турында телеочерк. 6+
10.00 «Юлчы». 6+
10.30, 14.05 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.45 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05 «Яшьләр тукталышы». 12+
14.30 «Татар сүзе». 6+
15.30 «Олы юл әйтте...» циклыннан «Ышаныч». 6+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате». 12+
20.00 «Семь дней». 12+
21.10 «Бер язмыш - ике моң». Фәридә-Алсу дуэтының 25 еллык юбилей концерты. 6+

«ЭФИР»
5.00 «Наукограды». 12+
5.30 «Опыты дилетанта». 12+
6.00 «Мировой рынок». 12+
7.00 «Лео и Тиг».
8.00 «Чужие в городе с Дмитрием Губерниевым». 12+
8.50, 15.10 «Начистоту». 12+
9.20 «СЕМЕЙНЫЙ БИЗНЕС». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ВОСПОМИНАНИЯ О БУДУЩЕМ». 16+
15.40 «ЦЕНА ПРОШЛОГО». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ВОЗДУШНЫЙ МАРШАЛ». 12+
23.00 «Шерлоки». 16+
23.50 «НЕ СТУЧИ ДВАЖДЫ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
4.45, 6.10 «ГАЛКА И ГАМАЮН». 16+
6.00, 10.00, 12.00 Новости.
6.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
7.40 «Часовой». 12+
8.10 «Здоровье». 16+
9.20 «Непутевые заметки». 12+
10.15 Жанна Бадоева в проекте-путешествии «Жизнь других». 12+
11.15, 12.15 «Видели видео?» 6+
14.00 «Страна Советов. Забытые вожди». 16+
17.15 «Две звезды. Отцы и дети». 12+
19.00 «Дело Романовых. Следствием установлено...» 16+
21.00 «Время».
22.00 «ХРУСТАЛЬНЫЙ». 18+

«РОССИЯ»
5.25 «ПОДРУГИ». 16+
7.15 «Устами младенца».
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00 Вести.
11.35 «Парад юмора». 16+
14.00 «ПОДАРИ МНЕ ВОСКРЕСЕНЬЕ». 16+
17.50 «Танцы со Звёздами». 12+
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Энциклопедия загадок».
7.05 «Приключения капитана Врунгеля».
8.15 «ДО СВИДАНИЯ, МАЛЬЧИКИ».
9.35 «Обыкновенный концерт с Эдуардом Эфировым».
10.05 «ЗАЙЧИК».
11.30 Письма из провинции.
12.00 «Тетеревиный театр».
12.40 Невский ковчег. Теория невозможного. Огнеслав Костович.
13.10 «Игра в бисер» «Михаил Булгаков. «Записки юного врача».
13.50 «Архи-важно».
14.20 «ОСЕННИЕ ЛИСТЬЯ».
16.05 «Пешком. Другое дело». Константин Паустовский.
16.35 «Невероятные приключения Луи де Фюнеса».
17.30 70 лет со дня рождения Валерия Халилова. Линия жизни.
18.25 «Песни разных лет». Иосиф Кобзон, Валерий Халилов и Симфонический оркестр Министерства обороны Российской Федерации.
19.30 Новости культуры.
20.10 «НАЧАЛЬНИК ЧУКОТКИ».
21.40 «Анна Франк. Параллельные истории».
23.15 Балет Л.Делиба «Коппелия».

«НТВ»
4.50 «БОБРЫ». 16+
6.35 «Центральное телевидение». 16+
8.00, 10.00, 16.00 Сегодня.
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
12.00 «Дачный ответ».
14.00 «НашПотребНадзор». 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации». 16+
19.00 Итоги недели.
20.10 «Звезды сошлись». 16+
21.40 «Основано на реальных событиях». 16+

Батыра торган «батырлык»

Көчле һәм батыр булырга омтылмаган малай-шалай юктыр. Ярый әле барысы да артыгын батыраеп законсыз гамәлләр кыларга керешми. Шулай да соңгы елларда җинаятьчелек яшәрү, зур шәһәрләрдә генә түгел, авыл җирләрендә дә яшүсмерләр кылган җинаятьләр арта бару күзәтелә.

Ютазы районы үзәгендә яшәүче Нина кредит картасындагы байлыкның шактый гына кимүен күрә. Саклык банкына мөрәҗәгать иткәч акчаның онлайн банк аша аңа билгеле булмаган затлар карталарына күчерелүе ачыклана. Полиция ошбу кешеләрне тиз эзләп таба, алар арасындагы 15-16 яшьләрендәге Руслан Әхмәтханов белән Илья Забродинга (балигъ булмаганнарның исемнәре үзгәртелә) шик төшә. Әлбәттә ки, малайлар мөстәкыйль рәвештә чит ханым хәзинәсендәге акчаны суыра алмыйлар, димәк, аларга кемнеңдер ярдәм итүе бәхәссез. Хатын-кыз кесәсенә керүченең 15 яшьлек улы Эмиль икәне дә ачыклана.

Мәсьәләгә нокта куелды дигәнне белдерми бу. Чөнки ни өчен дигән сорауга җавап табарга кирәк була. Тикшерү комитетының аеруча мөһим эшләр буенча тикшерүчесе Рөстәм Яруллин эшнең асылын ачыклый, ягъни Эмильне әнисенең кредит акчасын күчерергә алданрак телгә алынган көттә егетләр мәҗбүр итүе беленә. Ә бу исә сүзнең бала-чага шуклыгы-бурлыгы гына түгел, РФ Җинаять кодексында «вымогательство» дип йөртелгән җитди җинаять турында баруын аңлата.

Тикшерү барышында 950 сумның Р.Әхмәтханов, 1000 тәңкә И.Забродин, 3500 сум соңгысының әнисе исемендәге, тагын 7500 һәм 2000 сумның аларның танышлары карталарына күчерелүе, боларга кулдан кулга тапшырылган 500 сумны да өстәгәч, матди зыянның 15450 сум тәшкил итүе мәгълүм була. Барысы да аермачык кебек булса да тикшерү эшләре шома гына бармый. Гаепләнүчеләрнең күрсәтмәләре чагышмагач, аларны кара-каршы утыртып сорау алулар үткәрергә туры килә, «үрнәк» малайларын аналары яклап чыга, Забродинның әнисе улын гаепле санамый, Нинаны алар хисабына кредит бурычларын капларга ниятләүдә гаепли, чөнки зарар күрүче акчаның кредит картасыннан урлануын һәм аны зур процентлар белән кайтарырга кирәк булачагын әйтеп, матди зыянны күбрәк күрсәтә. Ләкин үзләрен башкалардан өстенрәк, бу очракта Эмильдән көчлерәк санаучы яшүсмерләрнең заманча усал белән акча талавы дәлилләнә.

Җәйге челләдә Эмиль Рамил атлы дусты һәм Р.Әхмәтханов белән соңгысының дачасына киләләр. Кунакларның әйтүенә караганда, су сибү, чүп утау кебек эшләрне күбрәк Эмиль башкара. Бусы бер хәл, көндез белән Рамил Эмиль телефонында «кызыклы» фото һәм видеоязма күреп ала. Анда Эмильнең ярымялангач йоклап яткан хатын-кызны капшавы сурәтләнә. Замана малае үзе төшергән әлеге язма күңелсезлекләр килеп чыгуга этәрә дә инде. Тегеләр мыскыллый, көлә башлагач, Эмиль өенә кайтып китә, ләкин кич белән аны Забродин белән Әхмәтханов ишегалдына дәшеп чыгаралар һәм һәркайсына унар мең сум акча таләп итәләр, юкса теге язманы бөтен бистәгә тарату белән өркетәләр һәм аны гаражлар артында икәүләп дөмбәсләп тә алалар. Шуннан соң малай алар күрсәткән карталарга аз-азлап акча күчерә башлый. Әхмәтханов әлеге керемне Забродин белән урталай бүлеп үз кирәкләренә тотуларын әйтеп тора.

Эмиль әнисенең полициягә барачагын әйткәч тә, Руслан аннан-моннан бурычка 3500 сум акча җыеп, Эмильгә бирә, зыянны акрынлап кайтарып бирергә ышандыра. Әмма ошбу акча да Нинага барып җитми, әлеге алыш-биреш вакытында шунда булган тагын бер яшь юньсез букмекер оешмасына биреп арттырабыз дигән булып алып китә. Гомумән, әлеге җинаять Урыссуда үзен «кәттә» хис итә башлаган яшүсмерләрнең шактый булуын күрсәтә. Шаһит булып чыгыш ясаучы малайлар да Әхмәтханов белән Забродинның акча талауларына икеләнмәүләрен белдерәләр, димәк, бу аларның беренче очрагы гына булмаган.

Җинаять эшендә Эмильдән акча сыгу очраклары күп булуы да күренә. Ике юньсез юк-бар сәбәпләр табып, әйтик, чакырган урынга килмәгән яисә берәр ялгыш сүз ычкындырган өчен дә түләп килә. Ләкин ошбу вактәякләр төшереп калдырыла. Ә ике-өч ай элегрәк булган бер очрак җинаять эшендә эпизод буларак урын ала.

Бу юлы «текә» малайлар Эмильнең гаражларында бензин пары иснәп кәефләнүе турында белеп алалар. Эмиль үзе токсикомания дип йөртелгән әлеге гамәлне Әхмәтханов белән бергәләп эшләдек дип бара. Ләкин ике дус, рисвай итү белән куркытып, аннан 4 мең сум акча каералар. Шулай итеп бистә малайлары төркем белән көч кулланып кылынган ике җинаятьтә гаепләнә.

Гаебен танып торган Әхмәтхановтан аермалы буларак, Забродин әлеге эшләргә катнашы булуын кире кага, акчаны Русланга биреп бардым, акча таләп итмәдем, Әхмәтханов 20 мең дигәч, бәяне төшерергә куштым дип барысын да дустына сылтый. Әйтүенә караганда, Эмильгә талау ниятеннән түгел, ә бензин иснәү, ярамаган эшләр кылу, видеога төшерү кебек начарлыклары өчен, үзе әйтмешли, тәрбия максатыннан гына суккан икән. Күрәсең, «текә» малай үзен башкаларны акылга утыртырга лаеклы һәм хокуклы кеше итеп хис итә башлаган. Тора-бара зарар күрүче үзе дә аның кубызына бии, ягъни яклап сөйләргә керешә. Ләкин ярдәме тими. Ютазы район суды аларны шартлы рәвештә икешәр елга ирекләреннән мәхрүм итә.

Чүпрәле районының Иске Дуван авылына Ульяновск каласыннан килгән ике малай бер төн эчендә ике җинаять кылып өлгерә. 2021 елның 16 август кичендә шул төбәктә туып-үскән Ульяновскида яшәүче 40 яшендәге Вадим Горбунов туган авылына, шунда торучы никахсыз хатыны, аның әнисе һәм энесе янына кайтып килергә була. Ошбу сәфәрне 17 яшьлек кайнене шәһәргә алып килергә кирәк булу белән аңлата ул. Чынлыкта, 45 яшьлек авылдашы А.Туманин белән «разборка»га кайта ул. Чөнки ошбу ир-атның хатынының әнисен кочләргә маташуы турында хәбәр алган була. Күрәсең, ошбу ир-ат энесе белән яшәгәнгә күрә, ялгызы гына сөйләшү үтемле булмаячагын уйлап тулай торакта күрше бүлмәләрдә торган 14 әр яшьлек ике малайны иярткә һәм, ышаныч күрсәтеп, Грязный һәм Тайсон кушаматлары йөрткән яшүсмерләрдә горурлык хисләре уятмый калмый.

Алар узгынчы машина белән барып һәм шактый гына җәяү тәпиләп Иске Дуванга җиткәндә, төн уртасы якынлаша. Кайнана йортыннан тагын бер яшүсмерне алып чыккач, дүрт кешелек төркем Туманиннар йорты янына килә. Авылдашлар ишегалдында чуашча сөйләшкәнгә күрә, кала малайлары аңламый, ләкин сүзнең ни хакында икәнен чамалыйлар, әлбәттә. Һәм очрашуның тыныч тәмамлануы белән килешмиләр, хуҗаларны җәзасыз калдырырга теләмиләр. Нәтиҗәдә, ике Ульяновск малае өйгә кереп Андрейның телефонын һәм өч банк картасын алып чыгалар. Ноутбукны да эләктергән булалар, ләкин аның ватык икәнен белгәч, веранда идәненә куеп калдыралар. Хуҗаның телефонны калдырыгыз, дип кычкыруына игътибар бирми кәттә егетләр.

Алар китеп баргач та, Туманиннарның яшьрәге Сергей куртка кесәсендәге банк картасы юкка чыгуын белә. Абыйсы үзенең телефоны, аның чехолы астындагы 2000 тәңкә акчасын һәм банк картасын тегеләр алып китүен әйткәч тә, Сергей хәзинәсендәге 29 мең сумны күршесе картасына күчерә. Ләкин 783 сум акчаны сарыф итеп өлгерә караклар. Соңрак мәгълүм булганча, юл уңаендагы кибет, ашханәләрдән тамак ялгарлык ашамлыклар алалар. 20 чакрым чамасы җәяүләп, ахыр чиктә, бер «Жигули»га утырып иртәнге сәгать 8 ләрдә генә кайтып җитә төркем Ульянга.

Көндез белән Горбунов телефонына Чүпрәле оперативнигы шалтырата. Вадим Туманиннар өенә кермәдем, күрмәдем, белмим, ишетмәдем, дип үзен күңелсезлекләрдән аралый. Икенче көнне теге малайлардан алган телефон, өч банк картасын полициягә тапшыра. Яшь угрылар Туманиннарның берсенә чехолда булган 2 меңне, икенчесенә картадан чигерелгән 800 сумны кайтарып бирә.

Шулай итеп мәсьәлә хәл ителгән кебек була. Әмма тикшерү комитетының аеруча мөһим эшләр буенча тикшерүчесе Айрат Мөхәммәдуллин 4606 сум дип бәяләнгән телефоны, андагы 2000 тәңкәне алуны төркем белән талау, ә банк счетындагы акчаны сарыф итүне урлау дип бәяли һәм 14 яшьлек малайларга карата ике эпизодлы җинаять эше кузгата. Аларның берсе гаебен таный. Ә Грязный кушаматлысы юкка чыга. А.Ф.Мөхәммәдуллин аңа карата кузгатылган эше тикшерүне вакытлыча туктатып торырга дигән карар чыгара. Әлбәттә, аның озак качып йөри алмаячагы шик уятмый.

Балтач районында яшәүче Нурислам июль аенда ике караклыгы өчен 150 сәгатьлек мәҗбүри эшләргә хөкем ителде, ләкин 15 яшендә генә булганга, әлеге җәзаны үтәүдән азат ителеп, аңа 2 еллык тәрбия чаралары, төгәлрәге, ирекне чикләүче кагыйдәләр билгеләнде. Әлеге карар кабул ителгәндә полициядә аның июнь аенда кылынган тагын ике җинаятен тикшерү бара.

10 июнь иртәсендә Нурисламның авылдашы Р.Шәрипов иртә белән машинасының юкка чыгуын күрә. Шөкер, «Лада Гранта» йортның икенче ягында булып чыга. Бу хәбәр килгәч тә полиция хезмәткәрләре иң алдан Нурислам белән әңгәмә коралар. Соңрак машинада малайның кул-бармак эзләре калуы да ачыклана. Хәер, ул үзе дә тел яшереп тормый. Кыскача гына әйткәндә, ачкычы урынында калган машинаны кабызып артка чигерә башлый, 50-60 метр чамасы киткәч, аны юл чите ташы – бордюрга «утырта», этеп-төртеп караса да кузгата алмыйча ташлап китә. Машинага зыян китерелми, ләкин ошбу гамәл законда урлау нияте булмыйча машина куу (угон) дип атала һәм җинаять эше кузгатыла.

Ике атнадан Балтач полициясенә Р.Нурмөхәммәтов телефонын югалту турында гариза язып кертә. Үткән кичтә Балтачта сыйлануларын, төнлә белән Кара күл буенда кәеф-сафа коруларын сөйләп бирә ул. Гаҗәп, ләкин 1973-78 елларда туган өч ир арасында, үзләре әйтмешли, яшь егет, ягъни 15 яшьлек Нурислам да була. Иртәнге сәгать 4 тә өенә кайткан Нурмөхәммәтов кесәсендәге телефоныннан җилләр исүен күрә. Әлбәттә, эчә, тарта торган тупас вә тәртипсез малайга шик төшә, өендә тентү үткәргәч тә, югалган телефон табыла. Нурислам аны күл буена баргында кесәсеннән төшеп калгач алдым, дип гаебен шомартырга тырыша кебек. Чөнки су коенучыларның яр буендагы чалбарыннан чәлдерүе дә ихтимал бит. Ничек кенә булмасын, Нурисламга карата «Урлау» дигән маддә буенча тагын бер эш кузгатыла. Табылган телефонны кайтарып бирмәү дә караклык санала. Ул сим-картаны алыштырып, телефоннан ике-өч көн файдаланган да әле. Телефон хуҗасы дәгъвам юк дигәч, судта әлеге эш туктатыла, ә машина куган өчен, малайның 1 елга ирекен чикләргә карар бирелә.

Хөкем чыгарганда яшьлеккә ташлама ясала, билгеле. Ләкин күбесе сабак алмый аларның, «батырлык»лар кылуын дәвам иттереп, җинаятьчелек сазлыгына гомерлеккә баталар.

Наил ВАХИТОВ.

Кадаклы шәмаилләр

Татарларыбыз арасында Ридуан кебек гыйлемле, динле, оста куллы, әдәпле ир-егетләр күп булу никадәр куаныч!

Ридуан Әлморатов Мәскәү янындагы Мытищи шәһәренең җәмигъ мәчете мәдрәсәсендә балаларга дини белем бирә. Үзе ул – Казаннан. 1991 елда Казахстанда туган, 2000 елларда Әлморатовлар гаиләсе Казанда төпләнгәч, Ридуан урта мәктәптә генә укып калмыйча, VII сыйныфтан мәдрәсәдә дин гыйлеменә дә төшенә башлаган. Аннары өч ел Мәскәү ислам университетында белем ала, шуннан күчеп, укуын Казандагы Россия ислам институтында дәвам итә һәм, 2016 елда аны уңышлы тәмамлап, теолог белгечлеге алып чыга. Коръәнне тагы да тулырак итеп өйрәнү өчен, Төркиягә юл тота. Чөнки «Бишектән алып ләхеткә кадәр белем ал» дигән хәдисне күпләребез белә, әмма аңа бик азларыбыз гына колак сала. Р.Әлморатов – бу яктан һәркем өчен үрнәк!

«Ридуан, филографити сәнгате юнәлешен сайлап алгансың. Андый әсәрләрне беренче тапкыр кайда күрдең һәм аңа кайда өйрәндең?» – дип кызыксынам әңгәмәдәшемнән. Аның Мәскәү ягында торса да, саф татарча сөйләшүе үк күңелгә якын...

Билгеле, бу төр сәнгать Россиядә популяр түгел. Шуңа күрә Ридуанның җавабы көтелгәнчә килеп чыкты: «Филографитины беренче тапкыр Төркиядә күрдем һәм шунда өйрәндем. Истанбулда укыган чакта, мондый әсәрләрне күреп сокландым. Төркиядә аның белән күбесенчә хатын-кызлар шөгыльләнә. Әлбәттә, ир-атлар да бар. Шулардан берничә дәрес алдым, калганы – үз тәҗрибәм нәтиҗәсе».

Ике ел белем туплап, Казанга кайтканда ул филографити өчен бар кирәк-яракны, эш коралларын да үзе белән ала. Чөнки алар Төркиядә генә бар дияргә мөмкин. Бу сәнгать төрекләрдә Госман империясе вакытыннан бирле үк сакланып килә. «Дин белгече булгач, догалар язылган әсәрләр иҗат итәсем килде, – ди Ридуан. – Аларның кайберсен үзем язам, кайберләрен интернет аша барлыйм. Язма контуры килеп чыгарлык итеп махсус кадаклар беркетәм, моның өчен махсус аппарат кулланам. Кадаклар – төсле, озынлыклары – 2 см». «Әсез аларны һәрчак бер дәрәҗәдәге биеклектә генә какмыйсыздыр бит инде? – дип белешәм остадан. – Сурәт, язма ясаганда кадаклар төрле биеклектә дә була ала бит!» «Әйе, алай да мөмкин, – ди ул. – Әмма мин кадакларны күп очракта бер биеклектә булырлык итеп кагам. Араларында йөртеп үрелгән җепләр – төсле металлдан, бары шундыйларны гына кулланам. Кадакларны да Төркиядән заказ биреп кайтартам, бездә андыйлар юк. Кадакларым дүрт төстә. Эшләнмәләремнең нигезе – фанера. Чөнки ул берничә катламлы, тотрыклы. Агач такта бу сәнгать өчен туры килми, ул ярылып китә. Өстәмәләрдән тукымалар кулланыла. Аеруча төсле бәрхетне үз итәм. Кайчак чын күн дә яхшы. Эш коралларым да күп түгел: кадак кагу өчен махсус аппарат, без, пластик чүкеч, кечкенә каргаборын, кечкенә шөреп боргыч».

Р. Әлморатов үз иҗатын Инстаграм сәхифәсенә куеп бара. Алар арасында аның «Әниемә» дигән эшләнмәсе дә бар. «Аны ясау белән үк, газиз әниемә бүләк иттем! Бәйрәм уңаеннан түгел. Болай гына! – ди оста. – Заказлар кабул итәм, алар бәйрәмнәр уңаеннан арта төшә. Бу – минем хобби. Төп шөгылем –инде өч ел балаларга дини белем бирәм. Буш вакытым калса, иҗат итәм. Эшләрем төрле. Шәмаилләр дә күп. Филографити сәнгате – матурлыкка илтүче сәнгать. Әмма аны стринг-арт юнәлеше белән бутарга ярамый, аермалар бар. Иҗатым белән Бөтенроссия татар дин әһелләре форумы кысасындагы күргәзмәм аша таныштырган идем. 2019 елда, Болгардагы күргәзмәм барышында да кул эшләнмәләремне игътибар белән карадылар, аеруча балалар күңеленә хуш килде, шушы сәнгать белән бик кызыксындылар. «Печән базары»нда да катнаштым. Әсәрләремне Диния нәзарәте вәкилләре дә ошата. Үзенчәлекле бүләкләр, шәмаилләр кирәк булганда, миңа мөрәҗәгать итәләр.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.



ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип Илгизәр ЗӘКИЕВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;

222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;

222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;

222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кульязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:

ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк,
г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2

E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта:

www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга. Бу санның чыгу көне 21.01.2022

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2800 данә

Заказ 2736

16+